# Ильдар Юзеев

## ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

2

**ТОМ**

Стихи для детей,
воспоминания

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Илдар Юзеев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

2

**ТОМ**

Балалар өчен шигырьләр,
истәлекләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ю25

Редколлегия:

*З. Р. Вәлиева, Р. М. Миңнуллин, Ф. Г. Галимуллин, Ш.Г. Галиев, Д. С. Шакиров, Х. Г. Әюпов, Р. Х. Корбанов*

**Юзеев Илдар**

Ю25 Сайланма әсәрләр. 5 томда, 2 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 304 б.

ISBN 5-298-01215-9 ©Татарстан китап нәшрияты, 2002





*Салават күпере сыман*
*Балачак хыяллары.*
*Балачагым хыяллары*
*Канатлар куяр әле...*

# Балалык

«Хуш, балачак, бездән калдың...» — диеп,
Шигырьләр дә язып карадык.
Юк,
Арттан калмый чаба балалык.
Синең белән исәп-хисапларны
Өздек бугай инде. Карар нык!
Юк...
Арттан калмый гына түгел,
Алдан чабып бара балалык.
Саф хыяллар сүнмәгәннәр икән.
Синең белән, димәк, ара нык.
Синең арттан мин дә чабам, тукта,
Мине дә ал, зинһар, балалык!

*1991*

## *Малай белән бабай*

Малайны бабай тоткан,
Бабайны малай тоткан.
Ул бабай бик карт инде,
Малай чагын оныткан.
Бабай малай булырмы?
Мин әйтәм: «Алай булмас,
Малай ул бабай булыр,
Ә бабай малай булмас».

*1995*

## Сакаллы маэмай

Кәҗә түгел, маэмай ул,
Эре генә атлай ул...
Эре атламас иде дә,
Дәрәҗәсен саклай ул.
Хуҗага кагылсалар,
Өреп кенә ятмай ул,
Куркып качмай, яклай ул,
Дәрәҗәсен генә түгел,
Хуҗасын да саклай ул.
Сакаллы да, акыллы да,
Менә шундый маэмай ул.

*1995*

## Гөлшат гөмбәгә барган

Гөлшат гөмбәгә барган.
Дәү әнисен дә алган.
Ята гөмбәгә охшап:
«Дәү әни, бу мин — Гөлшат!
Тырыска сала күрмә,
Көлкегә кала күрмә!
Гөмбә дә качып ятсын,
Үзе эзләсен, тапсын!»

*1994*

## Каз бәбкәсе

Каз — әнкәсе.
Аз бәбкәсе.
Саклана күр,
Каз бәбкәсе!

*1994*

## Мөгезе булса да...

Юкка гына Газиз, куркып,
Табанын ялтырата.
Үгез түгел ич, сыер ул,
Сиңа сөт алып кайта!

*1994*

## Мияубикә нигә боек?

Мияубикә ник уйнамый?
Күзләре боек аның...
Тәрәзәдән карап тора:
Үз әнисе юк аның.
Дәү әнием, дәү әтием
Аны да үз итәдер.
Мин генә аңлыйм: сагынып,
Ул әнисен көтәдер...

*1995*

## Кар өстендә дөяләр

Шыгыр-шыгыр баса алар
Салкын кар өсләренә.
Эссе чүлләр, кайнар комнар
Керәдер төшләренә.
Казан урамыннан уза
Башын иеп дөяләр.
«Сезнең туган җирегез бар,
Сез бәхетле...» ди алар.

*1995*

# Бәби Ай

Әнә күктә — әни Ай.
Әнә йолдыз — бәби Ай.
Әни Ай бәби Айны
Бәү-бәү итә, йоклата.
Тик бәби Ай йокламый,
Әкият тыңлап ята.
Әни Ай туктап кала
Иң кызыклы төшендә:
«Әкиятнең дәвамын
Күрерсең син төшеңдә...»

*1995*

# Самат киреләнә

Киреләнә башласа,
Аңлап булмый Саматны.
Үзе «мәм-мәм» сорады,
Биргәч, тотты да атты.
Күгәрченнәр килделәр,
Ак күмәчне күрделәр,
Бик тәмләп ашый-ашый,
«Гөр-гөр» гөрләп йөрделәр.
Самат шул якка чапты,
Әнисен аптыратты:
«Ник ашый алар, әннәм?
Ул минем... минем мәм-мәм!»

*1995*

## Әбием әкиятенең дәвамы

Энәсенә күз иярми,
Әбием кызып киткән,
Әкиятләр сөйли миңа,
Иллә дә кызык икән:
«Ул киткән,
Ай киткән, ел киткән,
Энә буе җир киткән...»
Сизмәдем дә, кай арада
Йомгак сүтелеп беткән.

...Кеше сәфәргә киткән,
Оек бәйләп бетергәнче,
Айга ук барып җиткән.

*1972*

## Самат хат яза

Исәнме, Капчык бабай?
Сиңа хат яза Самат исемле малай.
Хәзер ул көйсезләнә, акыра.
Әти: «Алып китсен!» — дип, сине чакыра.
Капчык бабай,
Мин инде елап туйдым бит,
Синең капчыгыңа сыймыйм бит.
Мин хәзер чиста да, тәти дә,
Шулай ди әни дә, әти дә.
Мин озак түзәлмәм,
Тагын елармын, акырырмын,
«Алып кит!» дип, сине үзем чакырырмын.
Хуш, Капчык бабай!
Язды Самат —
Әлегә тәти малай.

*1995*

## Самат белән җил

— Дәү әни, кайткан эттә,
Ишекне дөбердәтә.
— Тыңлап кара, кил, Самат,
Эттәң түгел, җил, Самат.
— Ул безнең өйгә керсен,
Керсен дә уйнап йөрсен.
— Керәлми, тәпие юк.
— Ә нигә тәпие юк?
— Әние, этие юк...
Урап йөри дөньяны,
Беркем җылытмый аны.
Үпкәләсә — көйләми,
Әкиятләр сөйләми.
Ул усал да, суык та,
Керсә — өйне суыта,
Ачуланса — борыннан
Чыгарала куык та.
— Мин курыкмыйм, мин чыдам,
Хәзер, җил, үзем чыгам.
Кочаклап йоклатырмын,
Еласаң — юатырмын,
Өшесәң — җылытырмын,
Иркәләп уятырмын.
Үз чанама утырып,
Төшәрбез таудан шуып,
Йөгереп уйный-уйный,
Китәрбез бергә куып,
Шуннан үзе җылыныр
Сине өшеткән суык...

*1995*

## Тук-тук бабай

— Кем ул анда тук-тук итә?
Тукранмы?
Тук-тук итеп тукылдатып
Утырамы?
— Тук-тук бабай кадак кага
Тук та тук...
Эшли һаман, булмый аны
Туктатып.
— Син аңа әйт, Тук-тук бабай
Туктасын...
Әкиятләр сөйлә аңа,
Йокласын.
— Яшәгән, ди, матур өйдә
Торган, ди,
Бар һөнәре тук-тук итү
Булган, ди.
Кулларында балта белән
Чүкече,
Бик күпләрне сөендергән
Бу кеше.
Тук-тук итеп, бик күп өйләр
Корган, ди,
Ул үзе дә шушы йортта
Торган, ди.
Берзаманны Тук-тук бабай
Арган, ди,
Чүкеч тотып, бәү-бәү итеп
Алган, ди,
Төшендә дә һаман тук-тук
Итә, ди,
Саматны да үз янына
Көтә, ди.

*1995*

## Уяныгыз!

Көне буе уйный-уйный,
Мин бик арган икәнмен.
Уенчыклар арасында
Үзем йоклап киткәнмен.
Уянсам — мин нәрсә күрәм:
Беркем эшкә чыкмаган:
Әтәчләр дә йоклаган ич,
Сәгатьләр дә йоклаган.
Сәгатьләр, тиз кузгалыгыз,
Йокламагыз күп-күп-күп...
Әтәчләр, ник уянмыйсыз?
Кәк-күк, кәк-күк! Кикрикүк!
Эшкә соңга калдыгыз, дип,
Әрләрмен, оялтырмын,
Болай бик ялкау булсагыз,
Мин үзем уятырмын:
Кәк-күк! Кәк-күк! Кикрикүк!

*1995*

## Гөл нигә шиңгән?

Бик эссе көннәрдә
Барсы су сорыйлар.
Сипмәсәң, шиңәләр,
Кибәләр, корыйлар.
Бакчада гөлләргә
Самат та сибә шул.
Сипсә дә, гөлләре
Шиңәләр нигә соң?
Самат бик әлсерәп,
Шул суны эчкән, ди,
Беркөнне, авырып,
Тамагы шешкән, ди.
Аңлаган Самат та,
Терелеп көч кергәч.
Үсми гөл, беркем дә —
Салкын су эчергәч...

*1995*

## Конфет нигә качкан?

Самат конфет яраткан.
Конфет әйткән Саматка:
«Зыяны булыр үзеңә,
Алай бик нык яратма».
Малай аны тыңламаган,
Ашаган да ашаган.
Конфет белеп әйткән икән:
Теше сызлый башлаган.
«Әйдә, Самат, синең белән
Икебез бергә уйлыйк,
Башта мин качам, аннан — син,
Икәү качышлы уйныйк!»
Самат үзе яшеренгән,
Конфет аны эзләгән.
«Менә ич мин! Менә ич!» — дип,
Самат чыккан, түзмәгән.
«Хәзер мин сине ашыйм,
Кәгазьне ачам!» — дигән.
Конфет әйткән: «Без уйныйбыз,
Хәзер мин качам!» — дигән.
Әй эзләгән Самат мескен,
Эзләп тә табалмаган,
Качкан урыныннан табып,
Авызга кабалмаган.
Төштә, өнендә дә эзли:
Әллә саташты микән,
Самат белән дус иде ич,
Конфет ник качты икән?
Конфет ашамыйча Самат
Күпмегә чыдар икән?
«Менә ич мин! Менә ич!» — дип,
Конфет бер чыгар микән?

*1995*

## Карбыз малай

Казанда нәни генә
Бер малай яшәгән, ди,
Ул бик карбыз яраткан,
Гел карбыз ашаган, ди.
Әтисе-әнисеннән
Гел-гел карбыз таптырган:
Алар гел ташып торган,
Малай гел ашап торган.
Әнә шулай ашый-ашый,
Әнә шулай яши-яши,
Корсак тулып киткән, ди.
Баш та юк, аяк та юк,
Карбыз булып киткән, ди.
Килә, ди, урам буйлап,
Кычкыра бала-чага:
«Карагыз, Карбыз малай
Тәгәри безгә таба!»
Бик тә түгәрәк булгач,
Туп итеп типкәннәр, ди,
«Гол! Гол!» — диеп кычкырып,
Капкага керткәннәр, ди.
Дөп тә дөп тибә торгач,
Икегә ярылган, ди.
«Ашамагыз, мин малай»,— дип
Елаган, ялынган, ди.
Мескен малайны барсы да
Карбызга санаган, ди,
Доктор Айболитка илткәч,
Теккән, ди, ямаган, ди.
Чак-чак кына терелткән,
Чарасын белеп кенә.
Хәзер малай ашый, ди,
Чамасын белеп кенә.
«Карбыз малай» исеме
Ябышкан да калган, ди.
Казандагы бер малай
Шундый сабак алган, ди.

*1995*

## Балык малай каптыра

Мин балык. Яр буенда
Малайларны каптырам:
Тфү! Тфү! Малай, кап!
Аптырап карап торам.
Тфү! Тфү! Малай, кап!
Берсе дә эләкмиләр.
Юри генә каптырам!
Берсе дә кирәкмиләр!
Ятьмә тотып, аларны
Бик тә сөзәсе килә,
Ярга атып, һәммәсен
Җепкә тезәсе килә!
Мин балык. Яр буенда
Малайларны каптырам.
Юк, каптырмыйм, аларга
Кызыгып карап торам.
Үзегезнең кармакка
Ялгыш килеп капмагыз,
Ябышыгыз колгага, —
Су бик тирән, батмагыз!
Тфү! Тфү! Капмагыз!

*1992*

# Их, малайлар!*

Калкавычка карый-карый,
Ике күзем ялыкты.
Тотмый калмам,
Их, малайлар,
Менә мондый балыкны!
    Тизрәк балык кап!
    Кармагымны кабып тарт!
    Малайларны көнләштереп,
    Яр башында ялтырап ят!
Калкавычым су төбенә
Бер батты, бер калыкты,
Ычкындырдым,
Их, малайлар,
Менә мондый балыкны!
    Тизрәк балык кап!
    Кармагымны кабып тарт!
    Малайларны көнләштереп,
    Яр башында ялтырап ят!
Колганы тартып чыгардым —
Шаккатырдым халыкны.
Ычкындырдым,
Их, малайлар,
Үземнән зур балыкны!
    Тизрәк балык кап!
    Кармагымны кабып тарт!
    Малайларны көнләштереп,
    Яр башында ялтырап ят!

*1993*

* Т.Вәлиев музыкасы.

## Туп йоткан бегемот

Еракта түгел, якында,
Нәкъ Кабанның артында,
Бер бегемот яшәгән, ди,
Казан зоопаркында.
Балаларга бу бичара
Тамаша, кызык кына,
«Сәлам, бегемот!» — дигәннәр,
Кулларын сузып кына.
Барсы да аның алдында
Көлгәннәр, уйнаганнар,
Бегемот та читлегендә
Уйнар дип уйлаганнар.
Борылып та карамаган
Шаяннарга бегемот,
Көннәр яткан, айлар яткан
Ямансулап, боегып.
Беркөнне Шукбай да килгән,
Уйнарга дип туп тоткан.
Шул тубын ул читлек аша
Бегемотка ыргыткан.
Ә бегемот нишләгән соң?
Тупны капкан да йоткан.
Шукбай өйгә кайтып киткән,
Бегемотны оныткан.
Сөйли олысы, кечесе:
«Бегемот үлгән... диләр,
Бер малайның туп атуын
Барсы да күргән, диләр».
Нинди хәл бу? Кем гаепле?
Кичә исән, бүген — юк.
«Тупны алма диеп йоткан, —
Ач булган, ди, бегемот».
...Шукбай буш читлек алдында.
Башы түбән иелгән.
«Уеннан уймак чыгар, дип,
Кем уйлаган, кем белгән?
Юкка гына читлегеңдә
Ятмагансың боегып.
Үзең юксың. Соң булса да,
Кичер мине, бегемот...»

Гаепне, бу югалтуны
Тагын кемнәрдер тойган:
Берәү, килеп, буш читлеккә
Шигырь беркетеп куйган:
«Бала чакта шаяр һәм көл,
Авыр уйлар уйлама.
Әмма шуны син яхшы бел:
Уйламыйча уйнама...»

*1995*

## Самат белән саескан

Ап-ак нәни Саескан
Пычракка кереп яткан.
«Бигрәк кызык булды!» —дип,
Өенә йөгереп кайткан.
Әни әйткән: «Танымыйм,
Малаймы син, кызмы син?
Аунагансың пычракта,
Әллә соң дуңгызмы син?
Аппагым дип әйтмәмен,
Инде сине яратмам.
Сабын белән юына,
Өйрән әнә Саматтан!»
Саескан болай иткән:
Саматны эзләп киткән.
Ул тәти сабын белән
Юынып тора икән.
Кулын да юа үзе,
Битен дә юа үзе,
Күзенә сабын кергәч,
Елап та куя үзе.
Самат ап-ак чактагы
Нәни Саескан кебек,
«Аппагым, тәтием!» — дип,
Әнисе кочкан кебек.
Саескан бик кызыккан,
Берни уйлап тормаган,—
Самат күрми дә калган,—
Ул сабынны... урлаган.
Сөенеп өйгә кайткан:
«Әни, әти, күр әле!
Менә Самат сабыны!
Ул берни дә күрмәде!
Әни, әйдә, ю мине
Самат кебек булганчы,
Күзгә сабын кергәнче,
Күп юынып туйганчы!»
Әнисе сөенмәгән,
Әнисе бик хурланган.
«Юмыйм бу сабын белән.
Ул бит... ул бит... урланган!»

...Самат гаҗәпкә калган:
Сабын кайда югалган?
Кулны юарга кирәк —
Сабынымны кем алган?
Юмаган күзләрен дә,
Юмаган борынын да.
Икенче көнне торса, —
Сабын үз урынында...
...Саесканның әнисе
Нәрсәдер эзләп киткән,
Кычыткан өзеп алып,
Мунчада чап-чап иткән.
«Әллә-лә-лә, әллә-лә!»
Әнисен елап кочкан.
Кеше әйберенә бүтән
Тимәс инде Саескан.
Юган аны әнисе
Самат кебек булганчы,
Күзгә сабын кергәнче,
Күп юынып туйганчы!..

*1995*

## Бәбкә үлән

Сукмактан атлап киләм.
Исәнме, яшел чирәм?
Чыктыңмы, терелдеңме?
Кояшка үрелдеңме?
Үләннәр тере кебек,
Йөгереп йөри кебек.
Атлап киләм сак кына,
Басмый калдым чак кына...
Ул бит каз бәбкәләре...
Әнә ич әнкәләре.
Сыйпыйсы килгән иде дә...
Бик усал эткәләре.

*1994*

## Язны озатучы акчарлак

Җырлый-җырлый агып барам,
Там-трарам-трарам.
Соңгы бозына утырып,
Язны озата барам.
Бара-бара, бара-бара
Нәни боз эреп бетәр,
Елга суына кушылып,
Ул җәйгә кереп китәр.
Карасагыз, боз өстендә
Кар йомгагы бар кебек.
Ялгышасыз, мин — акчарлак,
Тик эремәм кар кебек.
Өстән җылы нурлар тама,
Там-трарам-трарам.
Матур җәйне без уйныйсы
Күкләр көтеп торалар,
Күпләр көтеп торалар!

*1996*

# Иң кызыгы...

Дәү әнием, ялкауланма,
Әйдә, сикереп тор да,
Икәү футбол тубы тибеп,
Уйныйбыз коридорда!
Син алай итенгән бул,
Син болай итенгән бул...
Тупны тота алмадың ич!
Гол! Исәп: икегә ноль!
«Җитәр инде, ардым» димә,
Бик тә кирәк хәрәкәт,
Үзең әйтмешли, дәү әни,
«Хәрәкәттә — бәрәкәт».
Мин уйнап алам гармунда,
Биеп алсаң да ярый,
Китер кызыл яулыгыңны:
Мин — үгез, син — тореодор!
Үзең әйтмешли, дәү әни,
Бераз кирәк тырышлык,
Әйдә, сугышлы уйныйбыз,
Мә, кулыңа кылыч тот!
«Каты сукма!» дигән булып,
Күзләреңне кыскан бул,
Юри генә егылган бул,
Мин атам, син — дошман бул!
Нишлисең син, дәү әнием,
Үпкәләп китмә алай!
Үзең әйтмешли, тыңламый —
Үзәккә үтмә алай!
Дәү әни, нигә елыйсың?
Әллә авыртты кулың?
Ял итик, мин кәнфит ашыйм!
Син суыр валидолың.
Безнең өйдә һәркөн шулай
Күңелле ыгы-зыгы.
Мультфильм да кирәк түгел,
Дәү әни — иң кызыгы!

*1996*

## Агылый белән Тагылый

Агылый белән Тагылый
Гел-гел бергә йөриләр.
Чананы бергә сөйриләр,
Карны бергә көриләр.
Беркемнән дә курыкмаган
Болар икәү булганда,
Агылый белән Тагылый
Китқәннәр, ди, урманга.
Карурманның әчләрендә
Җиләкләр эре-эре.
Чиләкләр тулды дигәндә...
Килеп чыккан... зур Бүре!
Агылый, агачка менеп,
Үз дустын ташлап киткән.
Бүре Тагылый мескенне
Тоткан да ашап киткән.
Болытка болыт тагылган.
Агылган да агылган.
Ялгызы калган Агылый
Тагылыйны сагынган.
Гомере буе тынгылык
Бирмәгән бер үкенеч:
Бүре аның куркаклыгын
Көтеп йөргән икән ич!
Бүре аның кыюлыгын
Ашап киткән икән ич...

*1992*

## Кем җүләр?

Ишәй белән Кушай берчак
Уйнарга уйлаганнар,
Төн буе икәү кәрт сугып,
«Дурак»лы уйнаганнар.
Кем акыллы? Кем җүләр?
Кемнең акылы артыр?
Маңгайларына чирткәннәр
Йөз дә алтмыш биш тапкыр.
Ишәй әйткән: «Син — дурак!»
Кушай әйткән: «Син — дурак!»

Бүлмәдәге бер тутый кош
Булган акыллы, тапкыр,
«Икегез дә дурак!» диеп,
Кычкырган ике тапкыр.

*1992*

# Кем карт?

Көне буе футбол уйнап
Урамда йөргән Мокыт.
Юри генә аксый-аксый,
Трамвайга кергән Мокыт.
Олы башын кече итеп,
Бер бабай урын биргән.
Мокыт, бик канәгать булып:
«Молодец, яшьтәш!» — дигән...

*1992*

# Мокыт барган кунакка

Корсакка өя-өя
Тутырган гөбәдия,
Ярты тавык, ярты каз...
Мокыт әйткән: «Бу бик аз!»
Төягән ул мең борчак,
Сиксән ике бавырсак,
Кырык фасоль, йөз ногыт
Капкан да йоткан Мокыт.
«Ой, бигрәк тәмле дә соң!»
Ялаган тәлинкәсен.
Ашаган ул шул чаклы —
Кибән иткән корсакны!
Рәхмәт әйтәсе урынга
«Тагын бир!» дип кычкырган.
Төчкергәндә, пошкырганда,
Нәрсәседер ычкынган.
Һәммәсе дә Мокыт өчен
Кызарып утырганнар.
Күтәргеч кран чакыртып,
Чак кына котылганнар.
Утыртсаң — яткырып булмый,
Тора алмый — яткырсак,
Безнеке ул — вак корсак,
Мокытныкы — вот корсак!
Үз исеме онытылды,
Мокыт хәзер «Капкорсак!»

*1992*

## Шукбайның Йабкуш белән очрашуы

Әйткәннәр: «Бардыр ич синең
Үз туганнарың...
Без дә белергә телибез,
Әйт булганнарын?»
«Берсен дә белмим,— ди Шукбай,—
Исем китми дә...
Их, туганың булса иде
Ерак чит илдә!
Бардыр, мөгаен, ул миңа
Килергә тиеш,
Мине эзләп табарга һәм
Күрергә тиеш!»
Башкалар да аның белән
Бергә көтәләр.
Чыннан да, килеп Шукбайга
Хәбәр итәләр:
«Сорый берәү: Шукбай туган
Сездә яшиме?
Теле — безнең нәкъ киресе,
Йабкуш — исеме».
Шукбай атлап кына бармый,
Бара гел чабып.
Малайлар каршы алалар
Аны кул чабып.
«Күрсәтегез, кайда Йабкуш —
Якын туганым?
Чакырсын, минем ул илдә
Юк бит булганым...»
Сөенечле минутларны
Тора ул көтеп.
«Менә ул!»
Берсе Шукбайны
Күрсәтә төртеп:
«Тагын бер Шукбай барлыгын
Күрдең ич инде,
Үзең белән очрашырга
Килдең ич инде!

Үзеңне һәм нәселеңне,
Бәлки, белерсең...
«Йабкуш» сүзен иплəп кенə
Укы киресен:
Шукбай!»

*1999*

## Оныкка сөйләгән әкият

Борын-борын заманда,
Син әле тумаганда,
Әниең булмаганда,
Бабаң әбиеңне белмәгәндә,
Аны төштә дә күрмәгәндә,
Булмаган, ди, чаңгы да, чана да,
Бабаң шуган, ди, табада:
Теләгән әбиеңне табарга!
Әбиең тиз йөгергән, тоттырмаган,
Ул бит табага утырмаган.
И чапкан әбиең, и чапкан,
Ычкынмак булып кочактан.
Бабаң атланган бер атка,
Чапкан ике-өч көн, бер атна.
Беркөнне куып җиткән сөйгәнен,
Көткән «мин дә сөям!» дигәнен.
И чапканнар болар, и чапканнар,
Бәхетләрен бергә тапканнар.
Әтиеңне эзләп киткәннәр,
Әниеңне эзләп киткәннәр.
Тракторга утырып,
Самолетка утырып,
Сине эзләп киткәннәр
һәм, табып,
Дөньяга сине бүләк иткәннәр.
Синеке — бу замана,
Утырма чанага.
Эзләп торма таба.
Ракетага утыр да
Оч киләчәккә таба.
«Эзләгәнне таптым» диярсең.
Оныгыңны сөярсең...
«Борын-борын заманда» дип,
Әкиятләр сөйләрсең...

*1998*

## Куянны кем аткан?

Куян урманда яткан.
Кипкән бер яфрак тапкан.
Әз-мәз генә йомшарткан да
Авызына капкан, —
Тәмәке итеп тарткан.
Көн-төн тарткан, еш тарткан,
Болай да кыска гомерен
Тарткан саен кыскарткан.
Тарткан-тарткан, тарткан да
Урман буйлап кайтканда,
Сазлыкка кереп баткан,
Чыгалмый озак яткан.
Яткан-яткан, яткан да,
Саф һавага баккан да
Яшәүдән колак каккан.
Кем аткан икән куянны?
Әллә бер аучы аткан?
Юк, аучы түгел,
Тәмәке аткан.
Ун ел буе үпкәсеннән
Төтене чыгып яткан...

*1997*

## Карга күмелгән аю

Киселгән агач төбеннән
Бер шешә тапкан Аю.
Адәмнән калган хәмерне
Кызыгып капкан Аю.
Салкын көз көне булса да,
Сизмәгән кар-суыкны.
Имәнгә бәйләнә икән:
«Яратасыңмы, юкмы?»
«Нишләп юлымда торасың?!»
Бүрене болгап аткан.
«Сине уважаю!» диеп,
Керпене кочып яткан.
Тиенне тотып ашыйм дип,
Нараттан егылып төшкән,
Тиеннәр көлгән тәгәрәп,
Ә Аю... башын тишкән.
Айнырга да өлгермәгән,
Кыш килеп җиткән, диләр.
Беркем уята алмаган,
Кар күмеп киткән, диләр...

*1997*

# *Тутый кош*

Ул басып тора
Такта янында,
Ә колаклары
Парта ягында.
Нәрсә әйтсәң дә,
Ишетеп ала,
Ялгыш аңлый да
Көлкегә кала.
Тутый кош диеп,
Таралды даны,
Читтән дә килеп
Сорыйлар аны.
Моны ишетеп,
Бер абый килде:
«Шул тутый кошны
Бирегез!» — диде.
Ә без Маратны
Уратып алдык.
«Ул Марат бит!» дип,
Чак алып калдык.
Нишлик, һаман да
Төзәлми Марат.
Әйтүне көтә
Гел безгә карап.
Ахры, Мараттан
Бик нык туярбыз.
Чынлап та аны
Зоопаркка
Илтеп куярбыз...

*1970*

## Жираф

Жирафны укырга биргәннәр.
Уйнап бик күп йөрдең,
Инде укып кеше бул дигәннәр.
Жираф килеп керә класска:
Озын буйлы, кыска муенлы.
Боргалана башлый, һич кенә дә
Оныта алмый икән уенны.
Иптәшеннән күчерергә уйлап,
Муенын сузып алга үреләп.
Их, муенның озын булса иде,
Озын булса, бар да күренә.
Алга таба үрелеп карый-карый,
Муены аның бик нык сузылган.
Нишләргә дә
Белми йөргән Жираф соңыннан.
Башкаларның муены да кыска,
Дәресне дә яхшы беләләр.
Ә Жирафтан
Озын муен, диеп көләләр.
Әй үкенгән Жираф, әй үкенгән,
Нишләргә соң хәзер, нишләргә?
Оялудан ул урманга качкан,
Күренмичә йөргән кешеләргә.
Дәрестә дә тыныч булыр иде,
Онытыр иде бөтен уенны,
Соң шул инде,
Кыскармас шул аның муены...

*1970*

## Макай белән Акбай

Макай — чанада яткан.
Акбай — чананы тарткан.
Макай — мәктәптән качкан —
Акбай — букчасын капкан.
Макай — төнен йоклаган.
Акбай — аны саклаган.
Макай — батмый чак калган.
Акбай — аны коткарган.
Акбай — чирли башлаган.
Макай — аны ташлаган.
Акбай — салкында туңа.
Макай — җылыда куна.
Кочакладым Акбайны:
«Оныт! — дидем,— Макайны!»

*1990*

# Карбыз белән Фарваз

Фарваз карбыз ашаган.
Карбыз бик тә ошаган.
Берне, өчне ашаган,
Берчак арта башлаган.
Кайсы карбыз, кайсы Фарваз?
Ни әйтсәң дә ышанам.
Карбыз кемгә охшаган?
Ул Фарвазга охшаган.
Әйт, кемне кем ашаган?

*1999*

## Тукта, ник качасың?

Әллә төштә, әллә өндә,
Әллә кичен, әллә төнлә —
Бара Сәгыйть урам буйлап,
Бик куркыныч уйлар уйлап:
«Килеп чыкса бер юлбасар
Йә хулиган — кая качар?»
Ишетә ул ят бер тавыш:
«Сәгыйть, кая китеп барыш?»
Аяклары тими җиргә,
Тотына ул йөгерергә.
Шүрләмәгән икән юкка:
Арттан тавыш: «Сәгыйть, тукта!»
Ә монысы — тимәс кебек,
Салмак тавыш — киңәш кебек:
«Бездән куркып калгансыңдыр,
Хәл җый туктап, аргансыңдыр».
Һаман чаба, чаба Сәгыйть,
Хәлдән таеп ава Сәгыйть.
Куучылар ала урап,
Сәгыйть мескен ята елап:
«Ник кудыгыз? Ник тоттыгыз?
Сез кемнәр? Ник куркыттыгыз?»
— Сорау биргәч, ник дәшмәдең?
— Хәл җый дигәч, сөйләшмәдең.
— Туктамадың «Тукта!» дигәч.
— Егылдың — мин — Нокта килгәч.
— Безне артык дип уйлыйсың
Язган чакта ник куймыйсың
Сорау, Өндәү, Нокта, Өтер?
Яле дәфтәреңне китер!
Сәгыйть торып утырган, ди,
Сүз биреп чак котылган, ди:
«Онытмамын һәр җөмләдә,
Көндезен дә һәм төнлә дә.
Яшәү рәхәт хата юкта.
Ялгышларга куям Нокта».

*2000*

## Экрандагы Әкрам

Америка киноларын
Бик ярата Әкрам да.
Үзен бик күрәсе килә
Әнә шундый экранда.
Безнең мәктәп — «телевизор»,
Тамашачы булыгыз!
Килегез дә тәнәфестә
Читтән карап торыгыз.
Зур залга да сыялмыйча,
Килеп чыгар «экран»нан.
Алдында торсаң, һәммәсе
Куркып кача Әкрамнан.
Кем соң ул Әкрам дисезме?
Сезгә әллә кем түгел...
Америка фильмындагы
Ковбойлардан ким түгел.
Карагыз әнә: ул нишли?
Уртага ялгыз чыга,
Уйламый да, уйнамый да, —
Бишәүне сугып ега!
Әнә ничек басып тора:
«О кей!» дип тор син аңа.
Кесәсеннән ут чыгара,
Авызында — сигара.
Күрдек инде, тия алмый
Үзеннән көчлеләргә,
Әкрам супербатыр икән
Үзеннән кечеләргә.
Сиздермичә, камерага
Төшереп алдым мин аны.
Күрсәтербез үзенә дә
Үзебезнең киноны!

*2000*

## Ике хыял

Карагыз әле Ләйсәнгә:
Ул кем булырга тели?
Кулына таяк тоткан да
Дәү әни кебек йөри.
«Дәү әни булыр идем дә
Эшләми арыр идем,
«Пенсиямне бирегез!» дип,
Кассага барыр идем,
Кассага барыр идем дә
Күп акча алыр идем,
Кырык бер чупа-чупсны
Кесәгә салыр идем,
Калган акчама Ләйсәнгә
Торт сатып алыр идем,
Иртән торгач та, мәктәпкә
Бармыйча калыр идем,
Өчпочмак, бәлеш ашарга
Кунакка барыр идем...»
Алай шаярма ла, Ләйсән,
Таягыңны куй әле.
Инде үзең тыңлап кара
Дәү әнием хыялын:
«Их, балалар, могҗизалы
Дару табасы иде,
Балачакка кайтасы да
Торып чабасы иде!
Ләйсән яшенә кайтсаммы?
Ардым, дип ятмас идем,
«Әби буласы иде!» дип,
Хыялга батмас идем,
Ләйсән кебек кенә булсам,
Мин анда кайтмас идем».

*2000*

## *Шайтан котырта...*

Шайтан котырта Камилне:
— Алдыңда ич кампитр.
Дәресеңне әзерләмә,
Көн буе өйдә утыр!

Шайтан котырта Шамилне:
— Алдыңда — телевизор.
Кулга китап алмасаң да,
Рәхәттә гомер узар.

Әйт син, Камил дә, Шамил дә:
— Шайтан, безне котыртма!
Көн буе өйдә яткырып,
Төп башына утыртма!

*2000*

## Татар аюыннан хат

Аю күргәнегез бармы?
Мөгаен, юктыр.
Сез күргән аюлы урын —
Зоопарктыр.
Ә мин урманның үзендә
Күрдем чыннан да,
Күрше удмурт якларында,
Кара урманда.
Шул аю белән бик озак
Сөйләшеп яттым.
Ул ялваргач, сезгә шундый
Хат алып кайттым:
«Сәлам сездә туган татар
Аюларыннан,
Сәлам Кояшның бик моңсу
Баюларыннан.
Сәлам безнең белән киткән
Кошлар санынча,
Илен сагынып саргайган
Дуслар санынча.
Әгәр белсәгез иде сез
Качкыннар хәлен,
Күрмибез тыныч шаулаган
Урманның ямен.
Кош сайравын туган якта
Тыңлыйсы килә,
Сагынганда бүре булып
Улыйсы килә.
Җәен — өем булыр иде
Куе урманым,
Кышын — ябынып ятар идем
Ап-ак юрганын.
Кайтсам, бу чит урманнарны
Сагынмас идем,
Сорамыйча умартага
Кагылмас идем.
Кайтсам, сез дусларым белән
Кавышыр идем,
Иң-иң эре җиләкләрне
Табышыр идем.

Язам моны ап-ак ташка
Башымны куеп,
Кардай кәгазь битләренә
Яшемне коеп.
Беләсездер безне су да,
Ут та куганны,
Су астында калдырдылар
Күпме урманны.
Анда малайлар кабызган
Учак дөрләде,
Урманның янып киткәнен
Алар күрмәде.
Тирләдек, пештек утларда,
Таныйрлык түгел,
Үзебез туган урманда
Калырлык түгел.
Куркыттылар, без болай да
Аз була торып,
Урманны мичкә яктылар,
Газ була торып.
Чигенә-чигенә килеп җиттек
Иң соңгы чиккә.
Без әйләндек качкыннарга
Ят җирдә — читтә.
Шулай каңгырып, тилмереп
Ятыйммы инде?
Анда урманнар исәнме?
Кайтыйммы инде?
Җавап булса, юл чыгармын
Хатны алгач та,
Туган ягым — Әгерҗегә
Яки Балтачка.
Язам моны ап-ак ташка
Башымны куеп,
Кардай кәгазь битләренә
Яшемне коеп

*1999*

## Шомбай белән шоколад

Карыйлар тиргәп тә,
Мактап та...
«Юк, бармыйм,— ди,—
Мәктәпкә.
Барам,— ди,— шоколад
Бирсәгез,
Мин ансыз торалмыйм,
Белсәгез...»
Шомбайның күңелен
Күрәләр:
Таякка шоколад
Эләләр.
Бармыйлар тарткалап,
Суккалап,
Алдарак бара бит
Шоколад.
Шомбайдан ул качып
Котылган,
Дәрескә кергән дә
Утырган.
Укыган саен зур
Үскән ул,
Класстан класска
Күчкән ул.
Акылы бик алга
Киткән, ди,
Кәнфитләр патшасы
Икән, ди.
Ә Шомбай нишләгән?
Кем булган?
Шоколад патшага
Кол булган.

*1999*

## Мактанчыклар

Шомбай әйткән: «Минем эти —
Иң көчлесе дөньяда!
Йөз кило күтәрә ала,
Тиң булырлык юк аңа!»
Шукбай әйткән: «Минем эти...
Ничек торасың чыдап?
Мең килоны «әһ!» тә итми
Күтәреп тора озак».
Шомбай әйткән: «Минем эти,
Тукта, сөйләмичә тор...
Иң озын кеше дөньяда:
Буе — нәкъ ике метр!»
Шукбай әйткән: «Минем эти...
Акылың-исең китәр,
Илле метрлы, карасаң —
Бүрегең төшеп китәр».
Шомбай әйткән: «Ис тә китми,
Бер дә бүрегем төшми.
Мин мактанмыйм, минем эти
Тренер булып эшли!»
Шукбай әйткән: «Әтиемнең
Эш урыны — урамда.
Мин дә мактанмыйм, әтием —
Төзелештә — кранда...»

*2000*

# Кунакка йөрүче мәчеләр

Ерак-ерак җирдән,
Мыр-мырстан дигән илдән
Мияустанга
Мыр-мыр әфәнде
Кунакка килгән.
«Сәлам сезгә мыр-мырлар иленнән,
Тутый кошлар, былбыллар иленнән,
Сездән килгән кошлардан,
Бабагыз Арысланнан!»
Сөт, каймак белән сыйлагач,
Мияулар: «Мыр-мыр,— дигәннәр,—
Син безгә җырла
Үзегезчә бер җыр»,— дигәннәр.
Мыр-мыр ялындырып тормаган,
Менә шулай җырлаган:
«Сорадыгыз миннән сез бер көй,
Җырлыйм сезгә бик тә моңлы көй:
Мурмурки назек, мурмурки,
Мурмурки назек, мурмурки...»
Мыр-мырга мияулар да кушылган,
Кунакның күңеле хуш булган.
Мияустанда шундый ошаган,
Туйганчы җырлаган, ашаган.
Мыр-мыр чакырган кунакка
Үзе яшәгән якка.
Мияулар да чакыруны көткәннәр,
Кочаклашып җырлый-җырлый,
Мыр-мырстанга киткәннәр;
«Безнең дә бар мәчебез,
Сезнең дә бар мәчегез,
Безнең мәче сезгә килсә,
Зинһар, ишек ачыгыз!
Бездә дә бар шундый моңлы көй:
Мурмурки назек, мурмурки!»

*1998*

# Плюс белән Минус

Плюс белән Минус берчак
Дәресне ташлаганнар,
Коридорга чыкканнар да
Талаша башлаганнар.
Минус әйткән: «Син — бик комсыз,
Хәйләгә бик остасың,
Миңа тиеш булганны да
Гел үзеңә кушасың».
Плюс әйткән: «Ә син миннән —
Кушканны да аласың,
Ала-ала, ала-ала
Өстен булып каласың».
Минус әйткән: «Җитте! — дигән.—
Плюс буласым килә,
Гел үземә куша-куша,
Тормыш корасым килә!»
Шулай дигән дә бар көчкә
Плюска сылаган, ди,
Ике чаты сынган Плюс
Үкереп елаган, ди.
Дәрестә калган балалар
Кушканнар да алганнар.
Ә тегеләр икесе дә
Минус булып калганнар.

*2000*

## Көмеш балык тоттым

Көмеш күлгә кармак салдым:
Эләкте көмеш балык.
«Мондый хәл күргән юк!» — диеп,
Шаккатты бөтен халык.
Чыннан да, гап-гади балык
Эләгү тиеш иде.
Эләкмәде... Кармак — алтын,
Таяк та — көмеш иде.
Балык та юк, күле дә юк —
Сөйләдем сезгә ялган.
Бу тик хыял... мондый күлнең
Исеме генә калган.

*1998*

## Шомбай Сөмбелгә хат яза

Кайда туры килә — шунда
Язып куя гел-гел,
Өстәлдә дә, диварда да:
«Шомбай + Сөмбел»,
«Шомбай + Сөмбел».
Сөмбел дә язган кәгазьгә:
«Алгебраңны син бел.
Минем җавабым бик кыска:
«Шомбай минус Сөмбел»,
«Шомбай минус Сөмбел».

*2000*

## Шомбай эшләп арган

Иртән торгач әнисе
Йомыш кушкан Шомбайга.
Шомбай әйткән: — Юк, булмый,
Мин бик ардым болай да...
— Әле генә уяндың,
Шомбай, син ничек ардың?
— Һай, бик ардым, бик ардым:
Иртүк кибеткә бардым,
Утын кистем дә ярдым,
Боз тишеп кармак салдым,
Зур чуртан тартып алдым...
Һай, бик ардым, бик ардым...
— Алдыйсың ич, боларны,
Мөгаен, төштә күрдең?
— Әйе шул, төштә күрдем.
Мин бит гел эштә йөрдем...

*2000*

# Шомбай шәп шигырь язган!

Шомбай шәп шигырь язган!
Озак уйлап тормаган.
«Үзем уйлап чыгардым!» дип,
«Сабантуй»га юллаган.
«Шагыйрь булдым!» дип, борынын
Чөйгән ул югарыга:
«Минем кебек талантлылар
Дөньяда юк әлегә!
Менә күрерсез, бер капчык
Акча да килеп төшәр,
«Сникерс» белән тулыр,
Сай булмас минем кесәм.
«Бөек шагыйрь Шомбай» диеп,
Һәйкәлемә уярсыз.
«Монда Шомбай укыды!» дип,
Такта элеп куярсыз.
Калтырана-калтырана,
Имтиханга керерсез.
«Шомбай фәлән елда туган»
Диеп җавап бирерсез».
Бик шәп шигырь язган Шомбай.
Белмәсләр дип уйлаган.
Үз исемен генә язган,
Чын авторын куймаган.
Шукбай язган җавап хатны
Яшергән ераккарак:
«Шагыйрьдән күчереп язган,
Авторы моның — карак!»

## Аждаһа килгән циркка

Әкият илендә
Яшәгән идем мин.
Каф тавы артыннан
Күченеп килдем мин.
Анда юк тынычлык,
Тауларым — ишелде.
Күпме кан коелды,
Гомерләр киселде.
Сез куркып калмагыз —
Аждаһа дигәч тә...
Циркка алдылар,
Казанга килгәч тә.
Циркта дус булып
Яшиләр гел бергә:
Мәче дә, эте дә,
Куян да, бүре дә...
Кайчакта боега
Арыслан, филләрем:
Сагына алар да
Үз туган илләрен.
Сездә дә бар икән
Елмаймый торганнар:
Ятимнәр, тормышын
Бик авыр корганнар.
Мин дә үз җиремдә
Күп күрдем кыенны,
Оныткан идем бит
Шаяру-уенны.
Циркка килсәгез,
Кызыклар күрерсез,
Сез минем белән дә
Дус булып йөрерсез.
Гел бергә булыйк без
Шушы ел үткәнче.
Каф тавы артына
Мин кайтып киткәнче...

*1999*

# Түбәтәй

Кызлар, малайлар бер читтә
Юкка көлешеп тора,
Башымдагы түбәтәем
Бигрәк килешеп тора.
        Түбәтәй, түбәтәй,
        Бигрәк килешеп тора.

Нәни генә кояш кебек
Башыңны нурлый бит ул,
Астында акыл да булса,
Түбәтәй җырлый бит ул.
        Түбәтәй, түбәтәй,
        Башыңны нурлый бит ул.

Бик тиз үсәм, минем башым
Күкләргә тиеп китә,
Сөенечтән түбәтәем
Шушылай биеп китә.
        Түбәтәем, түбәтәем,
        Шушылай биеп китә.

Түбәтәй кигән малайны
Кызлар күрми узармы?
Хәзер күзлим үземә тиң
Калфак кигән кызларны.
        Түбәтәй, түбәтәй,
        Кызлар күрми узармы?

*1997*

## Кәбестә белән Кишер

Кышын көнделле инде ул —
Урамда җылы булса,
Кәбестәнеке шикелле
Җиде кат туның булса.
Бүген бигрәк тә суык шул:
Утыз ике градус.
Тәрәзәдән бик кызыгып
Карап тора ике дус:
Озын аяклы Кишер һәм
Олы башлы Кәбестә.
Малайлар ничек туңмыйлар,
Туннары да юк өстә.
Һич кенә дә тик тормыйлар:
Берсе күрсәтә фокус,
Ике малай уйный бокс,
Өченчесендә — кукиш!
Берсе куллана каратэ,
Берсе йөри кар атып,
Берсе карны өеп китә,
Икенчесе — таратып.
Кишер әйткән: «Өйдә ятып
Туйдым, чыгабыз!» — дигән.
Кәбестә: «Анда, салкында
Ничек чыдарбыз?» — дигән.
«Хәрәкәттә — бәрәкәт!» — дип,
Бабайлар белеп әйткән!»
Кишер олы башлы дустын
Урамга тәгәрәткән.
Кишер тышка чыгу белән
Йөгерергә тотынган.
Ә Кәбестә: «Туңам!» — диеп
Утырган да утырган.
«Җылы өйгә кертегез!» — дип,
Яткан да яткан икән,
Кузгата да алмаганнар,
Боз булып каткан икән.
Килгән Кишер: тәне алсу,
Битләре дә алланган.

Кәбестәне тәгәрәтеп
Өйгә кертә алмаган.
Кайткач тиргәгәннәр аны:
«Бераз уйларга иде,
Ник ташладың, дустың белән
Бергә уйнарга иде...»

*1998*

## Сәгыйть бара мактаныш...

Безнең-сезнең заманда
Булган, ди, велосипед.
Аңа менеп утырып,
Муенын борып-борып,
«Карагыз!» дип кычкырып,
Бара, ди, бала-Сәгыйть.
Сәгыйть килә мактанып:
«Әй, калмагыз тапталып!»
Кыйный велосипедны,
Тыңламый, ди, Сәгыйтьне.
Бара муенын сузып,
«КамАЗ»ны китә узып.
Җигүле ат та кала,
«Жигули» артта кала.
Күрми алда ни барын, —
Ычкындыра кулларын.
Бара торгач мактанып,
Килеп төшкән капланып.
Эзлиләр, ди, сәпидне,
Тапмыйлар, ди, Сәгыйтьне.
Сәпид сул якта ята,
Сәгыйть уң якта ята.
Һаман мактанып ята,
Үзе чак-чак кыймылдый:
«Беркемдә юк минекедәй
Кәкерәйгән муен!» — ди.

*1999*

## Актүбә уенчыгы

Актүбә балалары АКШ президенты Билл Клинтонга уенчык ясап җибәргәннәр.

Билл әфәнде, без әйтәбез
Кушып уенын-чынын.
Самолетта җибәрәбез
Актүбә уенчыгын.
Бу — безнең татар бабае
(Сугыш күргән берничә),
Яраткан карчыгы белән
Чөкердәшеп чәй эчә.
Ишетәбез, Сезнең хакта
Сөйлиләр әллә ниләр:
Ерак илгә, бомба төяп,
Очкыч җибәрә, диләр.
Яшәсен иде балалар
Уенчык кына ясап.
Сез бомбалар очырганда,
Куркып куябыз кайчак.
Бабай белән әбиебез
Чикне тыныч үтәрме?
Актүбәбездән Ак йортка
Исән барып җитәрме?
Түбәләр ак, аяз булса,
Башлар күккә тияләр,
Очрашсыннар Ак йорт белән
Актүбә, Күктүбәләр.
Безнең кебек уйлаучылар
Миллионлап бардыр әле:
Бергә уйнасын дөньяның
Айгөле, Барбилары.
Очмасын шомлы очкычлар
Баш өстендә — түбәдә.
Барби курчагын да алып,
Килегез Актүбәгә.
Уенчык ясау серләрен
Ачарбыз яшермичә,
Шушы әби, бабай белән
Тәмләп чәй эчә-эчә...

*1999*

# Моңнар тулды йөрәгемә

Бер кыз бик тә ошый миңа,
Әйтергә дә оялам.
Төшемдә дә, өнемдә дә
Гармун уйнап моңланам.
Җырлар тулды йөрәгемә,
Мин инде бала түгел,
Гармунга ачсам серемне,
Сафланып кала күңел.
Үзем уйныйм, үзем җырлыйм:
«Яна минем йөрәгем...»
Моңа кадәр йөрәгемнең
Ни икәнен белмәдем.
«Яна минем йөрәгем» дип,
Гармун уйныйм өздереп,
Уйна, гармун, моңлан, йөрәк,
Үзенә дә сиздереп.

*1996*

# Табылдык

— Ишеттегезме, мәктәпкә
Нәрсә алып кайтканнар?
— Фәнис, Данис тау буеннан
Мамонт тешен тапканнар!
— Нигә соң ул бик бәләкәй?
— Авызыңны ябып тор!
— Аның бит баласы да була,
Бәлки, нәни мамонттыр.
— Ничек соң ул черемичә
Шулай озак сакланган?
— Бозлы җир астында яткан
Бик борынгы чаклардан.
— Безне миллион еллар көткән
Кыйммәтле табышны без,
Бер тиен акча алмыйча,
Мәктәпкә багышлыйбыз!
— Күрсәтегез урамдагы
Һәрбер кызга, малайга!
— Табылдыкны күрергә дип,
Килгән Мәмәт бабай да!
— Бик зур рәхмәт, аны эзләп,
Кайда гына йөрмәдем...
Ясалма тешләрем өчен
Бик күп акча түләдем.
«Кыйммәтле табылдык» дигәч,
Тиз генә монда чаптым.
Сез мамонт тешен тапкансыз,
Мин Мәмәт тешен таптым!

*2000*

# Күзләрең нигә моңлы?

Менәбез дә атланабыз,
Көләбез, шатланабыз,
«Дөядә йөрдем әле!» дип,
Дусларга мактанабыз.
Ә син үзең, дөя, нигә
Бер кызык та тапмыйсың?
Бигүк теләмичә генә
Кар өстеннән атлыйсың.
Башың югары булса да,
Күрдем: күзләрең — моңлы.
Сагындыңмы әллә туган
Ягыңны — эссе комны?
Хәлләреңне аңлыйм да соң...
Ничекләр ярдәм итим,
Күз яшеңне киптерергә
Чүлләргә алып китим?..

*2002*

## Мине кем аңлар?

Нинди күңелле
Яшәгән идек.
Бергә җырладык,
Уйнадык-көлдек.
Онытты бергә
Җырлаган көйне,
Кайтмый әтием
Сагынып өйне.
Ике канатым
Ник каерылды?
Әти һәм әни
Ник аерылды?
Бер-берсен сөеп
Ник карамыйлар?
Бер-берсен алар
Ник аңламыйлар?
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Ике йөрәкнең
Бер ярасында.
Йоклый алмыйча
Сызыла таңнар.
Нишләргә инде,
Мине кем аңлар?
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Өзелеп калган
Көй арасында...

*2002*

## Унбер малай... бер бал корты

Тәрәзәне ачкан идек
Классны җилләтергә,
Бал корты да килеп кергән
Саф һава белән бергә.
«Уйныйбыз-быз!» дигән кебек,
Башта ул «быз»лап йөрде,
Әллә инде бал җыям дип,
Бер чәчәк эзләп йөрде.
Гөлчәчәкнең бантигына
Килде-кунды бал корты.
Ә ул: «Чага! Чага!» — диеп
Акырырга тотынды.
Барчасы да өерелеп
Ары да бире чапты.
«Тотыгыз!», «Тизрәк тотыгыз!
Гөлчәчәкне корт чакты!»
Әйттем: «Тотыйк та озатыйк
Болынына — иркенгә!»
Ишетергә теләмәде
Унбер малай — беркем дә.
«Юк! Юк!»
«Тотыйк та юк итик!»
«Ике канатын кисик!»
Унбер малайга берүзең
Каршы торасың ничек?
Нишләттегез нәни җанны,
Унбер яшь бала-чага?!
Кайвакытта корт чакмый шул,
Бал кортын бала чага.
Их, нәнием, ялгыштың шул
Безне чәчәк, бал диеп,
Үзең кебек уйнаучылар,
Уйлаучылар бар диеп...

*2001*

# Елады...

Еламый Айнур беркайчан:
Бәрелсә, сугылса да,
Кыйналса да, йөгергәндә
Абынып егылса да.
Дәрестә шаян булуын,
Ахры, истә тоттылар:
Дусты Булаттан аерып,
Кыз белән утырттылар.
Бар сыйныф алдында Айнур
Елады яшь тамызып.
Айнур елый, барсы көлә,
Табалардыр ни кызык?
Мин эчтән генә еладым,
Көләлмәдем кушылып.
Янда Камилә булмагач,
Нидер калды буш булып...

*2001*

## Соңга калган...

Һәрбер бала килеп
Үз урынын алган.
Бары Мидхәт кенә
Никтер соңга калган.
Укытучы сорый:
«Синме соң бу, Мидхәт?
Җәяү килдең мәллә?
Соңга калдың нишләп?»
Әйтте Мидхәт: «Сез ... нәрсә?!
Җәяү йөримме соң?!
Әти машинасы
Килде бүген бик соң...»

*2001*

# Хатасыз ничек язарга?

Дәрестә — диктант. Хатасыз
Язарга ничек кенә?
Артта утырган Фәритнең
Тавышы ишетелә:
«Алло! Алло! Әни! Синме?
Үзең белмәсәң, эзлә!
Әйт тиз генә:
«И»ме, «Е»ме
«Телефон» дигән сүздә?

*2001*

## Кемнәр нигә шатланган?

Рәсим нигә шатланган?
Ул ишәккә атланган.
Нәсим нигә шатланган?
Ул понига атланган.
Вәсим нигә шатланган?
Ул дөягә атланган.
Ясир нигә шатланган?
Ул чаптарга атланган.
Касыйм да менеп атланган...
Кара син аны, кара:
Әтисенең җилкәсендә
Үкереп елап бара.

*2001*

## Рәсемнәр күргәзмәсендә

Күргәзмәдә иң күп мактау
Эләккәндер Рәсимгә.
Дусты Нәсим башсыз килеш
Чыккан фоторәсемдә.
Барсы да хуплый Рәсимне:
«Төшергәнсең бик дөрес,
Нәсим математикадан
«Икеле» алган көн ич!»

*2001*

# Ни булган Вахитка?

Булмый ич танып та,
Ни булган Вахитка?
Шулкадәр үзгәрде
Ул соңгы вакытта.
Киләләр өенә:
«Уйнарга, Вахит, чык!»
«Йөрмәгез буталып,
Эшем күп! Вакыт юк!»
Башына кияргә
Алдырган эшләпә.
Өй эшен күршесе
Хәмиттән эшләтә.
Коллектив бәдрәфкә
Вакланып йөрми дә.
Башкалар көлгәндә,
Елмаймый-көлми дә.
Классның ишеген
Яба ул шап итеп,
«Волга»ның ишеген
Япкандай шәп итеп.
«Сез нәрсә? Макарон
Мин ашап тораммы?
Бирегез әфлисун!
Табыгыз икраны!»
Бер чегән хатыны
Юраган, имештер:
«Үскәч тә син, энем,
Буласың министр!»
Хыялда бул, әйдә,
Кылан һәм килештер,
Чынында, булырсың
Микән син министр?..

*2001*

## Яз шикелле җылы абый

Ерак әле җылы язга,
Ерак, ерак...
Өчилесе тәнгә җылы
Бирер сымак.
Кайта Тукай, күренмичә
Авырып ята,
Бизгәк тота, мич башында
Калтырата.
Карый тышка тәрәзәдән:
Ай-һай суык!
Бозлы жирдә чабаталар
Китә шуып.
Хәллерәкләр киез итек,
Толып-туннан.
Күлмәк кигән малай килә
Карлы юлдан.
Нәни генә китап тотып
Сабагына
Өтеп алган салкын кардан
Чаба гына.
«Теләк зур да, калмас микән
Туңып-арып,
Итек-тунсыз җитәлерме
Язга барып?»
Чыга шагыйрь, йөзгә усал
Җил бәрсә дә,
Нәни эзләр алып бара
Мәдрәсәгә.
«Җылынырсың, мә, ал, шәкерт,
Киез итек.
Ки син аны абыеңның
Төсе итеп.
Бәхетеңә җиткәнгәчә
Йөгер инде.
Озак көткән язга ерак
Түгел инде.
Йөгергәндә калдырма тик
Китабыңны.
Сау бул, энем, син каласың...
Китәм инде».

Яз шикелле җылы абый
Сыйпый баштан.
Ал тәпинең сөенече
Күктән ашкан.
Яз шикелле җылы абый
Кышта калды.
Кермәде ул мәдрәсәгә.
Тышта калды.
...Язга чапты җылы итек
Кигән малай,
Куанычтан башы күккә
Тигән малай.
Юлда ташлап калдырмады
Китабын да.
Бәхетенә тизрәк чапты
Ул тагын да.
Еллар узды...
Берәү Тукай һәйкәленә
Карап тора,
Кышкы җилләр сирәк чәчен
Тарап тора.
Һәйкәлдә дә үзгәрмәгән,
Ул бит таный:
Яз шикелле җылы абый,
Олы абый!
Әйе, таный:
Җан сулышы белән эретеп
Боз һәм карны,
Үзе кышта калган бөек
Фидакарьне.
Шагыйрь абый үзе моны
Онытканул.
Миллионнарның күңелләрен
Җылыткан ул.

*1987*

## Упкын өстендә

*(Баллада)*

Кыргый кәҗәләр
Борын-борыннан
Һәлакәт көткән
Шушы урыннан.

Тауның иң текә,
Иң тар төшендә —
Очрашкан алар
Упкын өстендә.

Ике ят нәсел,
Биреп җан көчен,
Сугышкан, җиңеп,
Баш калу өчен.

Юл бирми алга
Үтәргә кирәк,
Кемдә — көч-гайрәт,
Шул уза, димәк.

Күпмеләр һәлак
Булган шушында,
Очып төшкәннәр
Төпсез упкынга,

Мөгез — мөгезне
Бушлыкка сөйрәп...
Җиңеп узучы —
Исәннәр сирәк.

Биек-биектә
Козгыннар очкан,
Тау кәҗәләре
Упкынга очкан.

Гел тартып торган
Әҗәл упкыны.
Гел кими барган
Кәҗә токымы.

...Әнә тау буйлап,
Берәмләп кенә,
Ике яктан да
Исәннәр килә.

Каһкаһә белән
Козгыннар көлә:
Җирдә иң соңгы
Кәҗәләр килә!

Козгыннар гына
Күреп калырлар:
«Кызыл китап»ка
Кереп калырлар...

Очрашу урыны —
Туктады яклар.
Иң соңгы сугыш...
Кем кемне яклар?

Мәңге җыйналган
Нәфрәтләр, үчләр...
Бертигез — саннар,
Бертигез — көчләр...

Тик козгын шаһит:
Ни булыр хәзер?
Эләгешергә
Мөгезләр әзер!

Аксакал тора
Токым башында.
Тик шәүлә калыр
Таулар ташында.

Нәсел юк булыр —
Бер мизгел тагын...
Атларлар алар
Иң соңгы адым.

Иң соңгы сугыш,
Иң соңгы алыш,
Ике якны да
Упкынга салыш.

Киеренкелек.
Тәкәләр көтә.
Күзләрдә — нәфрәт,
Мөгезләр — текә.

Ике як бергә
Төпкә очарлык:
Яшь тәкәдә — дәрт,
Гайрәт, усаллык.

Аксакалда — көч,
Тәҗрибә, акыл...
Ике як та нык —
Һәлакәт якын.

Яшь тәкә, ярсып,
Мөгез уйната,
Тоякларыннан
Чаткылар ата.

Аксакал — сабыр,
Хәсрәтле, уйчан:
Ике як та бит
Упкынга очар!

Ул, җиңеп, исән
Калса ни булыр?
Барыбер алар
Нәселе корыр...

Инде ташландым
Гына дигәндә...
Бу ни? Аксакал
Башын игән дә

Кире борыла
Килгән юлыннан,
Йотарга торган
Соңгы урыннан.

Китте башкалар
Аның артыннан.
Мөгез — иелгән,
Һәммәсе — тынган.

Яшь тәкә озак
Аптырап торды,
Торды, торды да
Кирегә борды...

Упкын өстендә
Козгыннар тынды.
Гамьсез тын җилләр
Кудылар шомны.

Сакаллар уйный
Таңнар җилендә.
Соңгы кәҗәләр
Таулар илендә...

*1983*

## Бәхәс

Бала-чага, карты-яше
Һәммәсе күккә карый:
— Менә кызык!
— Тамаша бу!
— Бәла булмаса ярый...
— Зыянлы ул, карагыз тик
Кара пыяла аша...
— Тикмәгә түгел, дөньяның
Ахыры якынлаша.
— Куркытып йөрмә халыкны,
Сезнең заман — онытылган...
Гап-гади хәл, тик... бары тик
Кояш кына тотылган.
Кояш шулай мәңге йөзәр,
Җир булыр гел яктырак...
Таралыгыз өегезгә,
Тормагыз һич аптырап.
Уртага чыкты бер бабай,
Кушаматы — Ак бабай:
— Туктале син, Фәнис балам,
Бик өзеп әйтмә алай...
— Бабай, исемең Ак булса да,
Әйтер сүзең хак түгел.
Хәзер безнең фән заманы,
Сине тыңлар чак түгел.
— Әйе, чыннан да, җәмәгать,
Сүзләрем фәнни булмас...
— Фәнни булмаган юк-барны
Берәү дә тыңлап тормас!
— Юк, тыңлыйбыз аксакалны!
— Сөйлә, сөйлә, Ак бабай!
— Без Кояшны күзәтәбез,
Фәлсәфәңне сат, давай!
— Сез Кояшка карадыгыз
Тәмам онтылгач кына,
Һәммәбезне дә яшәткән
Кояш... тотылгач кына.
Сугышка кадәр — сәгать юк...
Аңа карамый идек,

Булмаса да вакытны без
Бик шәп чамалый идек.
Ата-бабалардан калган
Борынгы изге гадәт:
Бар җиһандагы адәмгә
Күренгән Кояш-сәгать!
Кояш белән уянабыз,
Бердәм китәбез эшкә,
Баш күтәрми эшлибез дә
Күккә карыйбыз — төшкә!
Җир дә, халык та, Кояш та,
Үзебез дә канәгать.
Һәркем Кояштан оялды
Ул вакытта, җәмәгать...
Хәзер еллар башкачарак,
Күз тимәсен — заман нык!
Машиналар, әллә ниләр...
Хәйран калып карарлык!
Анысы әйбәт... яше-карты
Өр-яңа гадәт тапты:
Бала-чагасына кадәр
Кулына сәгать такты.
Вакыт ягына килгәндә...
Оланнар, хәйран эшләр...
Ничегерәк икән безнең
Күк белән бәйләнешләр?
— Ак бабай, син —иске кеше,
Яшьләргә ни сөйлисең?
Ышандыра алмасаң да,
Искелеккә сөйрисең...
— Без үзебез искерсәк тә,
Кояш гел яңа бит ул,
Безләргә кадәр дә янган,
Бездән дә кала бит ул.
Теләсә нәрсә әйтегез:
Кояшка табынам мин,
Халыкның аңа табынган
Чакларын сагынам мин.
Кояш белән бергә ятам,
Кояш белән — уянам,
Шул гадәтне ташлаганнар
Өчен янам, оялам.

Көпә-көндез анда-монда
Җилкуар — урам тулы...
Күпләр илаһи Сәгатьне —
Кояшны оныттылар.
— Сәгать хәзер — гадәти хәл,
Ак бабай, ул шуңадыр...
— Кояш барын онытканнар
Җирдән дә суынадыр.
— Шуны истә тот, Ак бабай,
Замана алга китте,
Кешене авыр хезмәттән
Техника азат итте.
— Анысы хак, бер сүзем юк.
Әнә шул форсат белән
Кайберәүләр көн күрәләр
Бары тик корсак белән.
Маймыл Кешегә әйләнгән,
Кояшка карый-карый,
Күпләр яңадан маймылга
Әверелмәсә ярый...
— Борчылма юкка, Ак бабай,
Тик бердәнбер юл булыр:
Киләчәктә машина һәм
Фән ни әйтсә — шул булыр!
Бүген Кояш тотыласын
Алдан әйтеп куйганнар...
— Ник Кояш тотылды дисез?
Әйтеп бирим, оланнар!
Ул әле безнең бик сабыр,
Ул әле безнең — юаш,
Вакыт кадерен белмисез дип,
Искәртә безне Кояш.
Әйткәч шунысын да өстим,
Килгәч бер җае белән,
Жир сезгә кала, оланнар,
Кояшы, Ае белән.
Ата-бабалар гадәте
Шулай укмы югалыр?..
Галәмебезнең сәгате
Бездән, сездән дә калыр...
Вакыт билгеләүче — Кояш,
Хет санашма, хет санаш...

Ата-бабалардан калган
Бу минем шәхси караш.
— Ак бабайның сүзләрендә
Нидер бар...
— Хакны әйтә!
— Без оныткан бабайларның
Уена якынайта.
— Бәхәсне ник дәвам итми,
Ник дәшми Фәнис балам?
— Мин... ни... берни әйтә алмыйм...
Мин... үз сүземдә калам.
— Киттем, туганнар, Кояшны
Бераз озата барам.
Чыгар Кояш, сибәр нурын —
Шул булыр бездән сәлам...

Кояш баешы ягына
Китте ул, бәхәс тынды.
Кояшны югалткан авыл
Караңгылыкка чумды.
Илаһи сәгать югында
Кемнәр ниләр уйланыр,
Галәм сәгате туктаса,
Фәнис ничек уяныр?

*1986*

# Песи тотучы тычкан турында чын әкият

Анысы мин куркаклыкның
Ни икәнен дә белмим.
Өйдә ялгыз калган чакта,
Тычканнан гына шүрлим.
Әни китә, без калабыз
Икебез Мияу белән.
Көннәребез үтә безнең
Шаяру-уйнау белән.
Соңгы вакытта Мияуга
Күз тиде: әллә нишли,
Уйнамый, йоклый да йоклый,
Караватыннан төшми.
Бүлмә шаулатып, пыр тузып,
Тупны да кумый инде,
Ташлады әйбәт гадәтен:
Битен дә юмый инде.
Кайчак мин дә битне юмыйм,
Өлгереп булмый һич тә,
Әни эштән бик соң кайта,
Өлгереп булмый һич тә,
Мияу бит минем өстә!
Ә Мияу өйне сакларга
Һич тә уйламый инде,
Качып, тычкан тоткан булып,
Хәзер уйнамый инде.
Нишләтергә инде аны,
Иренә мырларга да,
Чак-чак уяттым Мияуны
Әкият тыңларга да...
Әкияткә мырлавыңны
Әзер бул син өстәргә,
Тәмле сөтең, каймагың да
Көтеп тора өстәлдә.
...Без яшәгән заманнарда
Бәләкәй генә Тычкан,
Мияуны күрәсе килеп,

Идән астыннан чыккан.
Сөттән дә авыз иткән ул,
Каймакка да тотынган,
Телевизордан мультфильм,
Кино карап утырган.
Йоклап яткан Мияуны да
Уятырга өлгергән.
«Тот мине! Тот!» — дигән дә
Өй буенча йөгергән.
Бу ни хәл бу? Бу ни хәл?
Әллә инде курчакмы?
Тычкан батыр ул «курчак»ны
Куып киткән шул чакны!
Әй куа, ди, әй куа...
Мияу урамга чаба,
Чаба-чаба, чаба-чаба
Качарга урын таба:
Менеп китә агачка —
Мырламый ул, дерелди:
«Синең белән уйнарга
Вакытым юк минем»,— ди.
Тычкан көлгән, дисезме?
Юк шул, бер дә көлмәгән,
Еларга да белмәгән ул,
Көләргә дә белмәгән.
Никадәре ялынса да,
Мияу барыбер төшмәгән.
Тычкан тирән уйга калган:
«Бу мияулар нишләгән?
Элек песиләр бик уяу
Иде, дигән булалар...
Элек шулай булгандыр да,
Күрәм: хәзер юк алар!»
Мактанып та куйган әле:
«Мең мияуны куркытам!
Элек песи безне тоткан,
Хәзер мин — песи тотам!»
. . . . . . . . . . . . . . . . .
Мин әкият сөйләгәндә,
Бәләкәй генә Тычкан,
Безне бик күрәсе килеп,
Идән астыннан чыккан.

Әкиятне тыңлый-тыңлый,
Өстәлдән йөгереп төшкән.
Шул арада каймактан да,
Сөттән дә җилләр искән...

*1982*

# Бүреләр оясында

*Экият*

Без яшәгән заманнарда Карт белән Карчык булган.
Байлыклары — пенсия һәм тишек бер капчык булган.
Үз авызларыннан өзеп, терлекне ашатканнар.
Кәҗә белән Сарыкны гел рәхәттә яшәткәннәр.
Берләнбер төн кәҗәләргә һөҗүм иткән ач Бүре.
Аучы, мылтыкка тотынгач, Карчык әйткән: «Кач, Бүре!»
Бүре үлемнән котылгач, мактанган Кәҗә, Сарык:
«Җибәрдек Бүре явызны сөзеп, корсагын ярып!»
Карт белән Карчык ябыккан, ә болар симергәннәр,
Хуҗалар исә бер кисәк ипигә тилмергәннәр.
Хәл калмагач Кәҗә белән Сарыкны ашатырлык,
Көчләре беткәч аларны рәхәттә яшәтерлек,
Сарык әйткән: «Нишләтәбез бу Карт белән Карчыкны?»
Кәҗә әйткән: «Ычкынсыннар алсыннар да капчыкны!»
Кемгә барып баш орсыннар, картларның эше харап...
Базарга да кагылганнар, йөргәннәр ризык карап.
Кая барырга белмичә, бик озак торгач уйлап,
Киткән болар карурманга илтүче бер юл буйлап.
«Хәерле юлга чыкмадык, муены аска килгере!»
Урман буенда каршылый ачыккан өч-дүрт бүре.
Мәхлукларның баш очында шомлы болыт куера.
Ата Бүре сөенечтән: «Казан ас!» — дип боера.
Берсе әйтә: «Пешермичә шул килеш кенә йотыйк!»
Икенчесе: «Ашаганчы, заложник итеп тотыйк!»
Карт ялвара: «Коткарыгыз һич югы карчыгымны,
Минем иң зур байлыгымны — алыгыз капчыгымны!»
Юк, ерткычлар беркемне дә ишетер хәлдә түгел,
Ач күзләргә ике фәкыйрь кызганыч, жәл дә түгел.
Әйтә Ак бүре: «Наданнар, тыелыгыз шашудан!
Бу ике карт йолып калды Әнкәгезне аучыдан!
Изге гамәлләре өчен аларга рәхмәт әйтик,
Читкә тибелгән җаннарга кадер-хөрмәт күрсәтик!»
Яшь бүреләр чигенәләр, Әнкәсенә баш орып,
Белә алар: аш биргәнгә һич ярамый таш орып.
Бирәләр бу мескеннәргә урманда куыш корып,
Башка ерткычлардан саклап, каравыллап, яшереп.
Хурлык-түбәнлеккә төшеп адәмнәр дөньясында,
Рәхәт гомер кичерәләр бүреләр оясында.

Ихтирам һәм хөрмәт күреп бүре дигән халыктан,
Сөйли картлар куылганын Кәҗә белән Сарыктан.
Ак бүре үз балаларын җырлап-көйләп йоклата,
Бәхетле картлар куышта сүзләрен тыңлап ята:
«Адәмнәр күптән онытты кемнән, ничек туганын,
Ак бүренең берзаманны ыру башы булганын.
Ия булгач адәмнәргә рәхимсезлек, катылык,
Бетте безнең арабызда туганлык һәм татулык.
Кешеләрнең һөҗүменнән сакланырга мәҗбүрбез,
Үзебез дә ерткычларга әверелдек хәзер без».
Берзаман төн уртасында, колак ялгыш ишетәме?
Кәҗә һәм Сарык тавышы: өндәме бу, төштәме?
Бу нинди хәл: Карт һәм Карчык гаҗәпкә калып тора,
Муенына бау салынган Кәҗә һәм Сарык тора.
«Зинһар, безне коткарыгыз... Ялвара ике «мескен»,—
Урыннары түрдә булыр, хуҗалар гафу итсен!
Без түгелбез көчсезләрне кимсеткән ишеләрдән,
Ошбу яман гадәтләрне алдык без кешеләрдән...
Заманасы шундый хәзер: ни көтәсең яшьләрдән...»
«Тимәгез!» диеп, Ак бүре туктата бу мәхшәрдән.
Яшь бүреләр йомшый төшә, сүзләргә колак салып,
Тегеләрнең муенына тагылган бауны алып.
Әйтә Ак бүре: «Хайваннар болардан гыйбрәт алсын:
Сарык дигәне — койрыксыз, Кәҗә — сакалсыз калсын!
Хуҗаларга рәхмәт укып, «Яшә!» дип кычкырыгыз,
Сакал, койрык — бездә калсын, үзегез — ычкыныгыз!
Әгәр шушы мәхлукларга бармак белән чиртсәгез,
Тиз генә килеп җитәрбез,— ул чак шәфкать көтмәгез!»
Кем бу? Ни бу? Түгел инде Кәҗә диеп атарлык:
Рәхмәт укый, әмма ләкин селкетергә сакал юк!
Исән калу шатлыгыннан бер атласын өч атлап,
Кәҗә белән Сарык китә хуҗаларын кочаклап.
Ашарсыз дип ит урнына иң авыр мөшкел көндә,
Ак бүре салган капчыкка бүре башыдай гөмбә.
Базарга җиттек дигәндә, ул гөмбә калган төшеп,
Ничек төшеп калмасын ди, капчыгы булган тишек...

* * *

Бу тормышта Ак бүрене күрмәдеме берегез?
Кайларда торып калдың син, шәфкатьле Ак бүребез?

*1999*

## Пони малае нәни Жирәнкәй

Юк, әкият сөйләмим,
Алдарга да теләмим.
Борын заманда түгел,
Мин яшәгән заманда
Ерак-ерак яклардан
Мине эзләп, Казанга,
Беләсезме, кем килде?
Сөйләсәм, шаккатарсыз.
Ат дисәң, бик кечкенә,
Кәҗә дисәң, сакалсыз.
Сез әйтерсез: «Бу ни бу?»
Мин әйтермен: «Пони бу».
Ә нигә миңа килгән?
Аны мин генә беләм.
Мактанмыймын. Дуслык бар
Зоология белән.
Ярый, килде дә Пони
Әйтте: «Исәнме, Гани?»
Бәй, мине белә, таный!
Күзләрен мөлдерәтеп,
Мескенкәй миңа карый.
Сыйпыймын ялларыннан:
«Ни кирәк сиңа, җаный?»
«Мин килдем сиңа, Гани дус,
Ерак Шотландиядән.
Сәлам сиңа юлда күргән
Кош-кортлардан, дөядән.
Безнең телләрне аңлаучы
Малай бар дип ишеттем.
Сахра, диңгез, таулар кичеп,
Казанга килеп җиттем».
— Дөрес, Пони, чит телләрне
Әлегә начар беләм.
Әмма яхшы аңлашамын
Хайваннар, кошлар белән.
Нинди ярдәм кирәк, Пони,
Яшьләрең тама нигә?
— Бәхетемне эзләп, Гани,
Мин килдем сезнең илгә.

Шахтада күмер ташыдым,
Күрдем анда нужалар!
Кыйнадылар, имгәттеләр,
Усал иде хуҗалар.
Картайгач, эштән чыгаргач,
Типкәләп озаттылар.
Ә баламны, колынымны
Чит илләргә саттылар.
Кайларда тилмерә икән
Бәгырем, Җирәнкәем?
Ялларын җилдә таратып,
Көтәдер үз әнкәен...
— Мин аны эзләп табармын,
Пони дускай, кайгырма.
Син калып тор энекәштә,
Мин хәзер чыгам юлга!

Әй, барам, малай, барам мин,
Уйда — нәни ат кына.
Ә кулымда тик бер әйбер:
Фотоаппарат кына.
Урманнар, таулар үттем,
Энә буе җир киттем.
(Юк, әкият сөйләмим,
Алдарга да теләмим.)
Шул арада Европадан
Азиягә дә җиттем.
Ни генә юк: лимон, шикәр,
Чәй, мандарин, әфлисун...
Карыйлар миңа: «Гани дус,
Авыз итми китмә син».
Алдымдагы әфлисунга
Үрелгән генә идем,
Өзеп алып, иренемә
Тидергән генә идем,—
Ой! Камышлар арасыннан
Туп-туры миңа табан,
Боргалана-боргалана,
Туктамый, килә һаман...
Ул, беләм, буар елан,
Бетте баш диеп торам,
Котым ботыма җитсә дә,

Фотоаппарат корам.
Кинәт бер апа килде дә
Еланны тотып алды.
Ун метрлы аждаһаның,
Валлаһи, котын алды.
Орышты апа еланны:
— Йә, кемгә ташландың син?
Әллә дусларны дошманнан
Аермый башладың син?
Көч керде хәзер абзаңа,
Кизәнәм, гайрәт чәчәм,
Яп-якын килеп еланга
Батыраеп эндәшәм:
— Бәхетең, кеше килеп чыкты,
Кирәгең бирә идем.
Мин бу килбәтсез гәүдәңне
Миллионга бүлә идем,
Кәтлит ясап, юлбарыска
Ашарга бирә идем.
Бик ашыгам. Вакытым юк.
Тыңла, әй! Сорау бирәм:
Бу яклардан узмадымы
Пони малае Җирән?
«Мин күрдем! Т-с-с-с! — диде Елан,—
Кил, колагыңа әйтәм...»
Мин саңгырау түгел, мәйтәм,
Моннан да шәп ишетәм.
— Җирәнне Филгә утыртып,
Алып киттеләр күптән.
Син аны Филдән сора,
Ул фәлән җирдә тора,
Бер сүз дә әйтмим бүтән.
Киттем мин Филне эзләп,
Үттем саванналарны.
Җирәнкәйне, чибәркәйне
Белмим, таба аламмы?
Бөркетләр, ерткыч җанварлар
Тезелгән як-ягыма.
Берзаман яңгыр тотынды...
Чиләкләп коя гына!
Уйламаганмын, ичмасам,
Их, зонтик алган булсам.
Яки бөтенләй чыкмасам,
Өемдә калган булсам?..

Тукта, кем килә?
Меңтөрле төсләр
Җем-җем-җем килә.
Нәкъ менә охшаган инде
Салават күперенә.
Салават күпере дисәң,
Ул бик якын күренә.
Килде дә миңа эндәште
Ягымлы тавыш белән:
— Салават күпере түгел,
Мин, Гани, Тавис булам.
Җирәнкәйне эзләвеңне
Кошлар хәбәр иттеләр.
Мин дә күрдем: аны шушы
Якка алып киттеләр.
Ярый зонтик алмагансың,
Мин үзем зонтик булам.
(Каурыйларын кабартты бу,
Хәйраннар калып торам.)
Киттем мин зонтик астында
Бик эре атлап кына.
Озата бара Тавис кошы,
Яңгырдан саклап кына.
Шулай бардык-бардык та
Туктадык без сазлыкта.
Каршы алды безне анда
Дәү бер «Сорау билгесе»:
— Син кем? Каян? Кемгә? Нигә?
Кайсы илнең кешесе? —
Таныштырды мине Тавис
«Сорау билгесе» белән.
— Сорау билгесе түгел ич,
Бу, Гани, соры Челән.
Ачуланса, муенын ул
Өндәү дә итә ала.
Мин калам, Гани, сазлыктан
Ул гына үтә ала.
Менәм дә мин озын-кара
Канатларга тотынам.
«Ямайка» дигән көйләргә
Җырлый-җырлый утырам.
Җавап биреп өлгермәдем
Кошның сорауларына,

«Ә» дигәнче чыгып җиттем
Сазның теге ягына.
— Алда — урман,— диде Челән,—
Африка урманнары,
Джунглиның син дә, мин дә
Үтәлми торганнары.
Балта да юк, пычак та юк,
Әмма миндә кул бар ич.
Әллә каян шул чагында
Килде-чыкты Юлбарыс!
Азау тешләрен күрсәтеп,
Үкерә генә инде,
Тырнаклары белән өскә
Сикерә генә инде!
Әллә нәрсә генә шулчак,
Күтәргеч кран кебек,
Эләктерде дә якамнан,
Агачка куйды элеп.
Озын муенлы дустымны
Күрми дә торам икән.
Мине коткарып калучы...
Әнә кем... Жираф икән.
Бу ни гаҗәп? Һәммәсе дә
Гел уңай килеп тора.
Кулларын сузып, ботакта
Бер маймыл көлеп тора:
— Таныш булыйк, мин — Горилла —
Борынгы бабаң булам.
Сыйлармын сине, туганым,
Иң тәмле банан белән.
— Бабамның исеме — Ярулла,
Бәхәсләшмим. Вакыт тар.
Менә нәрсә, син, Горилла,
Мине Филгә алып бар.
— Бер секунд,— диде Горилла,—
Булырсың Фил янында.
Бер йөреп кал рәхәтләнеп
Бабаңнар урманында.
Җитәкләде дә кулымнан
Китте бу мине алып.
Абагалар, лианалар
Калдылар дулкынланып.

Урманны узгач,
Күрдем мин Филне.
Аның аягы
Богаулы иде.
— Ярты дөньяны
Әйләнеп чыктым,
Җирәнкәй кайда,
Әйтче, Фил дустым?
— Эзләп килгәнсең
Бик ерак җиргә.
Әйе, циркта
Эшләдек бергә.
Хуҗабыз аны
Бигрәк кимсетте.
Чыбыркы белән
Кыйнап биетте.
Җирәнкәй, мескен,
Гел елый иде:
«Әнкәем кайда?» —
Дип сорый иде.
Цирк хуҗасы
Йоклаган чакта,
Ул качты карап
Көнчыгыш якка.
Каян китәргә
Өйрәтеп калдым:
«Аю дуска бар!» —
Дип әйтеп калдым.
Их, бу чылбырлар
Булмаса әгәр,
Озатыр идем
Аюга кадәр...»

Җирәнкәйне эзли-эзли,
Кайда гына булмадым...
Эссе чүлдә тирләмәдем,
Котыпта да туңмадым.
Узып киттем Крокодилның
Күзенә карап кына.
Ә кулымда тик бер корал —
Фотоаппарат кына.
Үзләре куркып торалар,
Миңа бер дә тимиләр.

Арысланнар минем алда
Койрык болгап йөриләр.
Аю бал белән сыйлады,
Озатып куйды Пошига...
...Хәзер, дуслар, хыяллардан
Чынга күчәм шушында.
Юри әйтәм, кайтмадым мин
Пошиның мөгезендә.
Кайда йөрүемне онытып
Җибәргәнмен үзем дә...
Бер сызгырдым — килде Пони
Нәни арбасы белән,
Нәни арбага төялгән,
Бала-чагасы белән.
Җирәнкәйне кайдан таптым?
Беләсегез киләме?
Минем кебек бар дөньяны
Күрәсегез киләме?
Ракетада очмадым,
Пароходта бармадым,
Поездга утырмадым —
Җәяү йөрдем, армадым.
«Бер сәгатьтә урадым, —
Дисәм әгәр,— Җир шарын»,—
«Һи, алдаша!» — диярсез,
Ышанмассыз, дусларым!
Юк, әкият сөйләмим,
Алдарга да теләмим.
Сорарсыз: «Ничек, Барслар,
Крокодиллар, Юлбарыслар
Сиңа тимәделәр?» — дип.
Әйтәм! Соң, алар барсы да
Читлектә иделәр бит.
Бер сәгатьтә бар дөньяның
Хайванын-кошын күрдем,
Океан, тавын, диңгезен,
Җәен һәм кышын күрдем.
Кайда күрдем? Соң... Казанда...
Зоопаркта йөрдем.

Әкият тә сөйләмим,
Алдарга да теләмим.

*1966*

# Карга баласы Каркылдык

Кояшлы бер май көнендә,
Хыялый уйлар уйлап,
Мәктәбеннән кайта Макай
Ямь-яшел бакча буйлап.
Башындагы фәлсәфәсе —
Үзе ачкан, өр-яңа:
«Әле ярый, карга булып
Тумаганмын дөньяга...
Ике йөз ел яшәгәнче,
Бакчалар ямен бозып,
Уйнап-көлеп, «ике» алып
Яшәве иллә кызык!»
Шулвакыт, гауга ишетеп,
Макай тукталып кала:
«Кар... Кар... Кар... Каравыл!» — диеп
Каргалар сөрән сала.
Аларның телен төшенеп,
Каен төбен караса:
Кечкенә карга баласы
Килеп төшкән ләбаса.
Кызык көткән Макай өчен
Бу — көтмәгән табылдык.
«Фамилияң булыр Каргалин,
Ә исемең — Каркылдык.
Хәзер инде синең язмыш
Макай абзаңа күчкән...»
Каркылдашып, елый-елый,
Каргалар бара өстән:
«И син, кадерле балабыз,
Канатларың каерылып,
Кайларга китеп барасың
Әнкәеңнән аерылып?»
«Нинди файда бар,— ди Макай, —
Һи... Карга... Харап икән...
Карга булып яшәгәнче,
Мин аны Адәм итәм!
Кеше иткәнчегә кадәр,
Назлыйм, сөям, ашатам.
Ул нәсел озын гомерле:
Ике йөз ел яшәтәм!»

Ялына карга көтүе:
«Кар! Кар! Кар! Әрәм итмә!
Карга булу — зур бәхет ул,
Сорыйбыз, Адәм итмә!»
«Сездәй аңгыралар белән
Бәхәсләшеп тормыйм мин,
Портфельгә салам да куям,
Балагызны урлыйм мин!»
Ята Каркылдык портфельдә,
Чарылдый ул «Чар!» да «Чар!»
«Оныт,— ди Макай,— кошларны,
Абзыеңда тылсым бар!»
Ботын югары күтәреп,
Чума татлы хыялга:
Кешелек аны тудырган
Фәнни рекорд куярга!
Дөнья фәненең серләре
Макайда яшеренгән:
Яңа сорт Адәм чыгарыр
Каргалар нәселеннән.
Ник аңа биология,
Нигә математика?
Берсенең дә кирәге юк,
Дәресне ташлап китә.
Урам тулы малай-шалай —
Алар әле күрерләр:
«Академик Макай!» — диеп,
Арттан калмый йөрерләр.
Нобель бүләген алгач та,
Морожныйга да тотмас,
Матай сатып алыр Макай,
Берәүне дә утыртмас!
«Кар! Кар!» — дип куя Каркылдык.
Бу — аның дәресләве.
Башлана Макай өендә
Тәрбия дәресләре.
«Ят! — дип боера хуҗасы, —
Йокларга урын әзер.
Мин ни эшлим — шуны эшлә,
Син — минем улым хәзер!»
Тегесе, ычкынмак булып,
Талпынды әллә ничә...

Очмасын дип, Макай аның
Канат очларын кисә.
Каркылдык «үги әти»нең
Артыннан калмый йөри.
Ни кыланса да, Макайдан
Күзләрен алмый йөри.
Макайның һәр хәрәкәтен
Каркылдык отып ала:
Көтмәгәндә күгәрченнең
Каурыен йолкып ала.
Акбайның өзә колагын:
«Уйнадым гына...— ди ул,—
Мин бары тик шаярырга
Уйладым гына»,— ди ул.
Туздыра кошлар оясын:
Макайлар ояласын!
Туп тибеп вата күршенең
Тәрәзә пыяласын.
Хуҗалар чыккач йөгереп,
Табанын ялтырата...
Мәктәп янына бара да
Кыңгырау шалтырата.
Машинага ябышкан да
«Кар! Кар!» — кычкырып бара:
«Макай улы Каркылдыктан,
Яле, ычкынып кара!»
Тыя алмый аны хәзер
Нинди усал ГАИ да:
«Шайба!» — ди дә бер малайның
Тондыра маңгаена.
Китә Макай мәктәбенә:
«Хәлләремне белегез,
Туйдым тәмам бу малайдан,
Тәрбияләп бирегез!»
Керә Каргалин класска,
Нәкъ Макайга охшаган,
Портфелендә — рогаткасы,
Дәфтәрләрдән бушаган.
Кайткач мактана: «Минем күк
Укый алмый беркем дә!»
Авызы колагына җиткән:
«Өч берле,— ди,— бер көндә!»

Макайның үзен уздырган,
Тагын һөнәре арткан:
Мичкәдән сыра чөмергән,
Унбиш сигарет тарткан.
Үзенә — йөз тәрбияче,
Ялкауланмый, иренми.
Үгетлиләр, тик Каркылдык
Бернигә дә бирелми.
Җайлап кереп утырган да
Макай алган арбага,
Ат иткән «үги ата»сын:
«Чап! Тизрәк чап! На! На! На!»
Бөкрәйде Макай гәүдәсе,
Инде шаярмый, көлми...
Аннан ничек котылырга,
Кая куярга белми.
Берчак урманга баргачтын
Аны... онытып кайткан,
Ә ул «ата»сын тапкан да
Бөкересен зурайткан.
Тәмам чыдар хәл калмагач,
Кул селтәп барчасына,
Каркылдыкны тартып килгән
Каргалар бакчасына.
«Хөрмәтле карга иптәшләр,
Моннан унбиш ел элек
Бик зур хата эшләдем мин,
Сезнең ояга килеп...
Бу — нәни карга баласы
Килеп төшкән оядан...
Әгәр дә рөхсәт итсәгез,
Аны кире куялам».
Әйтәләр: «Безнең нәселдә
Мондый бала тумас та...
Бездә мондый хәчтерүшнең
Булганы юк, булмас та!»
Ялына Макай: «Дускайлар,
Кап-кара бит, карагыз,
Валлаһи-билләһи менә —
Лично сезнең балагыз!
Ах, нигә соң, нигә генә
Үземә бәйләндердем,

Табигатькә каршы килеп,
Адәмгә әйләндердем?
Кешеләрнең үз тормышы,
Кошларның — үз язмышы.
Үз башыма төште хәзер
Сез — каргалар каргышы...»
Шулчак Әнкә танып ала:
«Аллам... төшме, өнме бу?!
Балакаем, нишләттеләр?
Ялгышаммы? Синме бу?»
Кузгала, баса Каркылдык.
Күзләрен ялтырата...
Рогаткасын чыгара да
Әнкә каргага ата.
Әйләнеп төшә Әнкәсе,
Канатыннан кан тама...
«Ник терәлдең, Макай-матай,
Тарт арбаңны! На! На! На!»
Китә Макай, башын иеп,
Авыр арбасын тартып:
«Адәм булып яшәгәнче,
Карга булу — мең артык!»
Төшми Каркылдык арбадан:
Юанайган, көрәйгән.
Макай мескен генә сорау
Билгеседәй бөкрәйгән.
Һич кенә дә бу бәладән
Юк котылу әмәле.
Каркылдыкның ике йөз ел
Газаплыйсы бар әле...

*1990*

# Аю сатам — кем ала?

— Бир бишне!
— Мә!
— Ун булсын!
— Тиеннәрдән сум булсын!
— Эшләребез уң булсын!

Саттар сата, без алабыз,
Бик күңелле уйныйбыз.
Үз әйберен мактамаса,
Акчабызны куймыйбыз.
«Чит илләрдән килгән түгел,
Үзебезнең малыбыз.
Нәрсә кирәк — барсы да бар,
Сайлагыз да алыгыз!
Сабит, сиңа ни кирәген
Күреп торам — сабын ал,
Бер югач та чистармасаң,
Миндә күп ул, тагын ал!
Хәйдәр, син бигрәк хәйләкәр,
Сиңа килешә төлке.
Башка вакыттагы кебек,
Акчасыз килмә түлке.
Миндә атның иң җитезе —
Сабантуйда чапканы!
«Шифалы су»ның татлысы —
Чишмәләрдән акканы!
Кесәләре бик сай иде,
Саттар ничек бай булды?
Африкаларга барып,
Алып кайтты Маймылны.
Песнәк синең баш очыңда
Торыр әкият сөйләп:
Казансудан Крокодилны
Чак-чак чыгардым сөйрәп.
Башка кибеттә тапмагач,
Беләм, миңа киләсең.
Көпә-көндез шәм кабызып
Таптым урман гөмбәсен.
Үзем кебек дәү гөмбә!
Бирәм — бары бер меңгә!

Мә сиңа, Кави, каеш.
Күрмисеңмени — кара!
Билеңне буып куймагач,
Ыштаның төшеп бара.
Гел-гел чикләвек кимерә
Озын койрык — бер Тиен.
Кыйммәт түгел — бик тиген,
Өч Тиенем — биш тиен!
Бу пистолет — борчак салып
Күзгә атмый торганы.
Саесканның яңа сорты:
Гайбәт сатмый торганы!
Бүреләрнең эреләре
Кем алыр дип көтәләр,
«Бас, кызым Әпипә!» диеп,
Куянны биетәләр.
Кошлар да бии агачта,
Кул чаба бер-берсенә.
Аю мескенкәй үкерә —
Баскан дус Керпесенә.
Сиңа булса — үкермәс,
Сатып алган — үкенмәс.
Алдыгызга Каз куям,
Бәясен дә аз куям.
Бәбкәләрен күтәрсең,
Үзеңнеке итәрсең.
Очып барган чакта Казны
Эләктердем ботыннан.
Ә Күбәләк бу сыерның
Койрыгына утырган.
Тукран җәйге ялга чыккан,
Гармунын уйнап ята,
«Керергә мөмкинме?» диеп,
Наратны тукылдата.
Гөлчәчәкне үстердем мин
Үзебезнең бакчада.
Гөлчәчәккә бүләк итәм,
Кирәк түгел акча да.
Менә Кәҗә, әнә Сарык,
Тагын биш тәңкә өстә.
Бүре башы юк капчыкта, —
Унике баш кәбестә.

Карбызымның кызарганын
Көн-төн саклап утырдым.
Яңгыр көнне кулчатырдан
Үзем су сибеп тордым.
Болары — минем бакчамда
Үскән чая чияләр:
«Авызыгыз бик бәләкәй,
Сыярбызмы?» дияләр.
Бу уенчык: Куян кылый —
Чәлдергәндә тотылды,
Кишереннән колак кагып,
Чак-чак ташлап котылды.
Кемгә кирәк Глобус?
Бирәм шушы Җир шарын,
Җир әйләнеп йөрерсең,
Бик арзан: даром-шаром!
Сәяхәткә чыгам дисәң,
Пароход бар, кораб бар.
Үзеңнең акчаң булмаса,
Алганнарны карап кал!
«Минем корабым юк» димә,
Җирдә дә «йөзеп» була.
Велосипедка утырып,
Дөньяны гизеп була.
Анысын да алалмасаң,
Җил уйнаса кесәңдә,
Тагын да тизрәк үсәрсең,
Тәпи-тәпи йөрсәң дә.
Кәнфитем дә бар иде бит:
Әллә инде җуйганмын,
Тешлим генә дигән идем,
Ялгыш йотып куйганмын.
«Мине сат!» та «мине сат!» дип,
Барсы миңа бәйләнде.
Шулай итеп, бу мактаулар
Рекламага әйләнде.
Әйбәт әйбернең бәясен
Арттырмыйм, киметмим дә.
Затлы, сыйфатлы әйберләр
Тик Саттар кибетендә!
Алучыны да алдамыйм,
Үземне дә алдатмыйм!

Унга кадәр саный беләм,
Шуннан кыйммәткә сатмыйм!
Кибет уены уйнадык.
Кем отылды? Кем отты?
Уенның иң ахырында
Уеннан уймак чыкты.

— Бир бишне!
— Мә!
— Ун булсын!
— Тиеннәрдән сум булсын!
— Эшләребез уң булсын!

*1999*

# Тукай теле

Җиде бабамнар көйләгән
шигырь һәм дога теле,
Мөхәммәтгариф мулла һәм
Бибимәмдүдә теле.
Юк, түгел бу — читтән килгән
килмешәк — нәнкә теле,
Бу — татарның җаны иңгән
әткә һәм әнкә теле.
Безне олуг милләт иткән
гадәт һәм йола теле,
«Әнкәй» дигән сүзне көткән
Бибимәмдүдә теле.
Бу сүзем — шагыйрь әткәсе —
изге бер мулла теле,
Бибимәмдүдә баласы —
Апуш — Абдулла теле.
Җиһанда аз яшәп киткән
Мөхәммәтгариф теле,
Гасырларны иңләп үткән
шигърият, тарих теле.
Күзге җилләрне елаткан
Мөхәммәтгариф теле,
Мәктәп баласын җырлаткан
фән һәм мәгариф теле.
Туган тел аша ачылды
читтәге дөнья теле,
Анда дуслар бик аз иде,
инде бар дөнья тулы.
Милләтнең теле яшәсә,
сау булыр дәүләт, иле.
Һәр бала сөйсә Тукайча
үз телен, туган телен, —
Тукай теле, татар теле
булыр гел исән, тере!

*2000*

# Истәлеккә калган еллар



# ШАГЫЙРЬЛӘР НИНДИ БУЛА?

## *Бездән соң кемнәр килер?..*

Үзебезнең китапларны нәшер итү сөенеченнән яки бөтенләй чыгара алмау көенеченнән без үзебездән алда яшәгән остазларыбызның иҗатын да, васыятьләрен дә оныта барабыз. Илленче еллар поэзиясен читләтеп үткән, салкын кул белән язылган мәкаләләр күбәйде. Ул чорның бөеклеген билгеләгән Туфан: «Кайсыгызның кулы җылы?» дип карап тора сыман. Үзенә сиксән яшь тулган көннәрдә ул яшь шагыйрьләрне өенә чакырып васыять сүзләрен әйтте: «Таркалмагыз, бердәм булыгыз!»

Оешмабызның «берлек» дип аталуы күңелгә берекмәде. Без хәзер икелек булып киттек, аерылдык. Бабаларыбыз «аерылганны аю, бүленгәнне бүре ашар» дип, безне кисәтеп куйганнар. Юк, безне аю ашамас, татар аюлары, яшәргә мөмкинлек калмагач, удмурт урманнарына качып киттеләр. Бүре дә ашамас — мондый хәл дәвам итсә, Алла сакласын, бер-беребезне ашап бетерүебез ихтимал. Мин Берлек тә, ПЕН клуб та кирәк дип саныйм, анда да, монда да минем дусларым күп. Әмма аерылсак та, безгә кочаклашып яшәргә кирәк. ПЕН Гәрәй шигырендәге эт белән мәче кебек кенә булса да...

Әдәбиятыбыз болай да, халкыбыз кебек үк, телгәләнгән, кискәләнгән. Саф татар телендә иҗат итеп Башкортстанда яшәүче балачак дустым Әнгам Атнабайлар гаскәре бездән аерылган, бүленгән. Без Әнкәбез Шигърият каргаган Сак-Соклар түгел ич! Нигә без аерым? Остаханәнең Марат Кәримов һәм Рафаэль Сафин катнашкан утырышында без шул хакта да уйлаштык.

Кайбер мәкаләләрнең авторлары татар әдәбиятының вaклануы өчен борчылалар, аны Европа әдәбияты дәрәҗәсендә күрергә телиләр. Дөрес, безнең шагыйрьләребез югарыдан караганда, бик вак күренәдер. Бүгенге шагыйрьләребез — дәүләте белән җир астында калган, балалыкта ятим булып кулдан-кулга йөргән, башы киселгән, утта яндырылган, суга батырылган, сөргенгә сөрелгәннәрнең исән калган очкыннары, кыйпылчыклары.

Аның көче дә, көчсезлеге дә шуннан... Алып бабаларыбыз белән чагыштырганда, татар шагыйренең гәүдәсе дә бәләкәйләнгәндер, инде Арсланга да тиң түгелдер, затлы киемнәр алалмаганга, зыялылык та җитмидер. Күпме гасырлар кисүләрдән соң... Хәзер аның китабын кисәләр. Мәйданга чыгып Рәшит Әхмәтҗанов кебек ачлык игълан итәсе дә юк. Ул болай да шуңа дучар ителгән.

Әмма татар шигъриятенең хәлен, көчен, җегәрлеген тоеп, аның эчендә яшәүчеләр мактанып түгел, горурланып әйтә алалар: «Европада башка мондый поэзия юк! Бүгенге шигъриятебез — дөньяның теләсә нинди телендә яңгырарлык!» Казанда китап чыгаруга караганда, бәлки, кайберәүләргә читтә нәшер ителү җиңелрәктер. Шигъриятебез илчесе Равил Бохарай Лондонда татар поэзиясе антологиясен әзерли бит. ПЕН клуб та бу юнәлештә эшен дәвам итәр дип уйлыйбыз.

Шагыйрьләрнең хәле беркайчан да җиңел булмады. Егерме җиде яшьлек Тукайның гомерен өзгән капитализмда да, миллионер Дәрдемәнд ярлылыкта һәлак булган социализмда да. Һәм без, Тукайлар каргаган җәмгыятькә кире кайтып барганда, хәл җиңеләер дигән иллюзия белән яшәмибез. Яңа Дәрдемәндләр туып, талантларга кул сузарлар дигән өмет булса да... Шуңа кадәр хөкүмәтебез чаралар күрмәсә, кешеләр рухын хәерчелек көтә.

Нинди генә чорда да, тынычта да, сугышта да, ачлыкта да, туклыкта да татар шагыйре сынатмады, динсез-мәчетсез елларда шигырьләр дога урынына йөрде. Хәзер шигъriяттә язмый яши алмый торган чын талантлар, фанатиклар, халкыбызны рухи инкыйраздан саклап калырга теләүче фидакарьләр генә торып калачак. Бәләкәй буйлы шагыйрьләребез рухи Алыпларга тиң булып кала алдылар. Зөлфәт иҗатына олы бәя бирелгән утырышта мин менә шулар турында да уйладым.

Заман җырының хәле ничек соң?

Без биш-алты матур тавышлы җырчының каруселеннән ычкына алмыйча, тиен кебек шунда әйләнеп, музыкаль мокытка әйләнә барабыз. Балет карарга баргач, Шәриф Хөсәенов гаҗәпләнеп: «Татар язучысын монда беренче тапкыр күрәм!» — диде. Музыкаль тәрбиябез шулай дәвам итсә, соңгы тапкыр күрүе дә мөмкин. «Татарлар операны аңламый!» дип, күпме гүзәл әсәрләрне алып аттылар. Җәлил башлаган театрда татар операсының ба-

шын кистеләр сыман. Мин моны беренче һәм соңгы тапкыр либретто язган автор буларак та әйтәм.

Хәйдәр Бигичев, Фасил Әхмәт кебек бөекләребез дә катнашкан утырышта ямаулык та сала алмаслык, контроль аша узмаган «җыртык» җырлар турында да борчылып сөйләштек.

Эзләнүләр һәм табышлар традицион шигырь нигезендә бара. 60 нчы елларда ташып чыккан ирекле шигырь тынычланды, элекке ярларына кайтты. Шигырь төзелешендә, эчтәлек-формада киләсе гасыр үзенең новаторларын көтә.

Акыл һәм хис көрәшендәге бәхәстә икесенең бердәмлеге җиңде. Фән докторы Рифат Җамал һәм кампитрны татарча сөйләшергә өйрәтүче Җәүдәт Сөләйман иҗатларын тикшергәндә шулар турында да сөйләштек.

Осталыкка ирешкәннәр остаханәгә мохтаҗ түгелләр. Ул яшь талантларны шигърият тавына тизрәк мендерү өчен кирәк. Хәзер Мөхәммәт тауга килми, тау Мөхәммәткә бара. Яшьләрнең барысы да Зөлфәт Хәким түгел. Аларны эзләп табу максатыннан, тәгәрмәчләр куеп, остаханәне күчмәгә әйләндердек. Шигъриятькә килү юлында Луиза Янсуар кебек талантларны күреп алдык.

Казан ханлыгы шагыйре Мөхәммәдьяр:

> Бер гаҗиб бу кем шәһренең эче тулуг,
> Шагыйрь улмушлар барча кечек һәм олуг,—

дип язган. Милли мәктәпләр бетерелгән совет чорында шәһәрдән бер генә шагыйрьнең дә чыкмавын үкенеч белән әйтәбез. Шөкер, хәлләр үзгәрә: татар мәктәпләрендә укучы Казан балалары Тукай телендә шигырь язалар, шигъриятебезне киләсе гасырга алып китүчеләр — бүген парта арасында утыручылар.

Фәннәр академиясендә үткән утырышта: «Мирасыбыз кемгә кала?» дигән сорауны без юкка гына куймадык.

Мәктәптә укучы яшь сәләтләргә ярдәм итү остаханәнең иң зур эше булды. Редколлегия әгъзасы буларак, «Сабантуй» газетасы аша мин шигырь язучы талантлы балалар белән, аларны берләштергән иҗат түгәрәкләре белән даими бәйләнештә торам, язмаларын матбугатка тәкъдим итәм. Балалар иҗатыннан «Үзебез язган китап» чыгардык. Шушы көннәрдә унбер яшьлек Мамадыш кызы Ләйсән Мөгътәсимованың шигырьләр китабы басылачак.

Сибгат ага Хәким «сугыштан соң поэзиягә беркем дә килмәс дип уйлаган идем... килделәр» дип сөенгән иде. Бездән соң куркучылар, борчылмагыз, сездән соң да килергә әзер торучы, хәзер үк профессиональ дәрәҗәдә иҗат итүче яшь талантлар бар. Аларны югалтмаска, осталыкларын күтәрүдә ярдәм итәргә генә кирәк. Бәлки, берничә остаханә оештырыргадыр: мәктәп яшендәге авторлар өчен, юмор сатира, җыр, поэма остаханәләре...

Чәчләрең коелып таз булып картайганчы, остаз булып өлкәнәюең үзеңә дә, яшьләргә дә шатлык.

Мең еллык шигъриятебезнең яшәүчәнлеген раслап, үстереп, авырлыкларга бирешмичә, XXI гасырга илтеп җиткерүче шагыйрьләребез яшәсен!

*Татарстан язучыларының 13 нче съездында шигърият остаханәсе җитәкчесе буларак чыгыш. 28 май, 1999*

## Гүзәл гамьгә борылыш...

Егерменче гасырның илаһи талантлы ике шагыйре үзеннән алдагы традицион шигырьне инкарь итеп, юкны табарга дип аваз сала. Үзенең Тукай шигыреннән килеп чыгуын оныткан яшь Такташ шулай. Туфан да, бунтарьларча,йөрәкне инкарь итеп килә. Кушаматында ук — өермә, давыл, җимерү... Ике бунтарь: Туфан һәм Такташ, искене җимереп, яңа пролетар поэзиясе тудыру өчен көрәш башлыйлар. Егерме алты яшьлек Туфан, табигый лирик җанына ирек бирмичә, бунтарь Хабулны иҗат итә. Шагыйрь өчен шигырьдә иң элек — акыл, образ-сурәт. Чор шундый геройларны таләп итә. Ритм — ватык, иректе, авыр, Хабулның үзе шикелле дуамал. Аннан соң эшче Минап, Чапый, Гыймай... Шагыйрь-рәссам кулы белән сурәтләнгән типлар, образ-сурәтләр шул килеш тә поэзиядә кабатланмас бер чор булып калалар. 30 нчы елларда Туфанда — борылыш. 1933 елда язылган «Аккаен» шигыреннән башлап ул «йөрәк кебек җылы уй»га күчә башлый. Ритм төзекләнә, фикер хистән, эмоциядән туа. Белмим, бәлки, аны якын дусты Такташның үлеме тетрәткәндер. Ә бәлки Такташтагы ирекле шигырьнең, новаторлыкның миллионнар күңеленә барып тоташканын үзе тоеп торган Туфан йөрәгенең табигый агышына ирек биргән-



Хәсән Туфан белән. 1966

дер. Бәлки, Такташның аның турында: «Соңгы вакытта Туфан үзенең шигырьләре эчендәге сирәк, ләкин яшь, яңа хисләре, күп вакытта гакыллы тирән хисләре белән җанга җылылык кертә башлады»,— дип язып калдырган сүзләре уйга калдыргандыр... Кем белә, бәлки, аны Сәйдәш музыкаль ритмнарының халык күңеленә нәкъ Такташча табигый агышы тарткандыр... Ничек кенә булмасын, Туфан үзенең эволюциясендә иҗатының иң олы биеклегенә — Гүзәл Гамьгә бара һәм 50 нче елларда «Агыла да болыт агыла», «Киек казлар», «Кайсыгызның кулы җылы» кебек шедеврларны тудыра.

Шулай итеп, Туфан Гамьне, уйны-фикерне гүзәл итеп бирүнең югары дәрәҗәсенә ирештe һәм поэзиябезне Гүзәл Гамь дигән яңа үргә күтәрде.

*2000*

## Шагыйрьләр нинди була?

«Әнкәй безне Сөннән алып кайткан...»

Җырга әйләнгән шушы шигырьгә Робертның бөтен тормыш юлы сыйган: бер үк телдә сөйләшүче милләтне аерып торучы Сөн буенда туган биш бала иркә кочакта үсмәгәннәр, хәзер инде алар олы җанлы Әнкәләре янына

кунак булып кына кайталар. Гап-гади биографик фактлар, шагыйрь һәм композитор таланты кушылгач, күңелләрне әсир итәрлек йөрәк җырына әйләнгән.

Туктале, нишләп бу китапка кереш сүзне мин язам? Бүгенге көндә Роберт Миңнуллинны белмәгән, шигырен укымаган, җырын җырламаган-ишетмәгән, телевизордан күрмәгән милли җанлы татар сирәктер. Исемә төште: егерме алты яшьлек яшь авторга фатиха бирүчеләрнең берсе мин идем бит — 1970 еллар башында яшьләр газетасында тәүге шигырьләрен укучыларга тәкъдим иткәнмен. Татарстан язучылар берлеге үткәргән семинарда бер вакыйганы сөйләгәнем хәтердә. Сугыштан соңгы авыр елларда Яңавыл якларында хәерчеләр күбәйде. Безнең Ямады авылында аларны Илеш хәерчеләре дип йөртәләр иде. Шул яктан килеп хәер сорашып йөргән Кәлимулла авылыбызда төпләнеп, соңыннан югары уңыш алучы комбайнчыга әйләнде. Искиткеч эш яратучан, кече күңелле, рухы белән бай кеше иде. Хәзер Илеш Башкортстанда иң бай төбәкләрнең берсе. Әмма адәм күңеле ачлыкта да, туклыкта да җыр сорый.

Әлеге дә баягы шул ачлык елларында авылга халык сәсәне Фәррах килеп төшә. Үзе сукыр, үзе иске шинельдән, үзе ач... Клубтан клубка шигырь сөйләп йөри, гонорар урынына ачтан үлмәслек әз-мәз он да бирәләр икән. Бу — мин беренче күргән шагыйрем. Сәгатьләр буе халыкны авызына каратып тотты, хәлсез адәмнәрнең башы югары күтәрелде, хәлләләр, оялып, башларын түбән иделәр.

Юк, яши алмый халык Шагыйрьсез... Нинди генә авыр чорлар булмасын, күңелләрне юатырлык сәсәннәре туып тора. Милләтебез ярлы булган дәверләрдә дә бай безнең шигъриятебез, Аллага шөкер! Көйсез күңелләрне көйләргә яратылган сәсән-шагыйрьләребезнең изге сүзләре дога кебек кирәк. Динсез-имансыз елларда халкыбызны берләштереп, телебезне саклап торучы тылсымлы көч, бәлки, шагыйрь сүзе булгандыр.

Бездә көйле шигырь традициясе бигрәк тә көчле, яшәүчән. Көйле-хисле шигырьдән баш тарткан, акылфикергә генә корылган, бик аз гына укучысы калган бүгенге Көнбатыш поэзиясе миңа ят. Хисне инкарь иткән салкын шигырь новаторлыгын татар укучысы кабул итмәде. Көйле шигырь бетәргә тиеш, дигән декларация белән чыккан бөек новатор Такташның кайнар шигы-

рендә мөлдерәмә тулы моң-хис. Әлегәчә безнең поэзиядәге ачышлар — көйле шигырь нигезендә. Бәлки, киләчәк гасырда берәр даһи туар һәм яңа юлга борып җибәрер. Анысына да өметне өзмик һәм эзләнүләрне туктатмыйк.

Татар күңеленә көйле шигырь Коръән догалары белән Күктән иңгәндер. Шунлыктандыр, ул — Адәм балаларына нык тәэсир итүче иң борынгы жанр.

Кырыс ла тормыш юллары,
Авыр ла дөньялары!
Хәлләремне җиңеләйтә
Әнкәмнең догалары,—

дигән җырның Уфа— Казан юлларында тууы бик табигый.

Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәкимнәрнең шигъри догалары калган юлдан баручы Роберт үзен көчле тоя. Иң авыр чакларда, яңа юлларга кереп-кереп чыкканда, мөгаен, иреннәре шул догаларны да кабатлыйлардыр.

Мин дә йөрдем «Илешнең бер баласы өзгәләнгән» ул юлда. Шундый да гүзәл табигатьле бу төбәкләрдә, Роберт урынында булсам, мин дә:

Кирәк булса, уйламый да
Күпер булып ятырмын.
Туган җиргә соңгы тапкыр
Шушы юлдан кайтырмын,—

дип җырламыйча түзмәс идем.

Чаллы юлын халык телендә «һәлакәт юлы» дип тә йөртәләр. Иң куркыныч аварияләр — шушында. Тормышның үзе сыман: кызыклы да, куркыныч та... Роберт та, мин дә күпме дуслар таптык бу юлда, кайберләрен югалттык. Фәез Зөлкарнәйнең аяныч һәлакәте һаман йөрәктә әрни. Әмма нинди генә хәтәр булса да, шагыйрьнең узар юлы — шундый...

Нигә тарта соң аны Уфа яклары?

Уфада яшәүче өлкән туганнары-остазлары Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗми, Әнгам Атнабайлар, рухи туганнары Бикбайлар, Әлибайлар, Әсанбайлар, Игебайлар янына ашыга ул. Дуслар белән күрешеп, моң бүлешеп яшәүләргә ни җитә! Моңның бер канатын Башкортстан шигъриятеннән, табигатеннән, кешеләреннән алып, үзе дә баеганны онытмый шагыйрь. Башкортстанда аны беләләр, үз итәләр, китапларын чыгаралар, җырларын җырлыйлар, үз шагыйре итеп саныйлар. Бу бәхеткә ия булганнар әлләни күп түгел.

Артка борылып караса — илле ел узган да киткән: «Гомерләр уза икән шул, гомерләр уза икән...» Шулай да югалтуларга караганда, сөенечләр күбрәк, узган юлда үз җырларың озатып бара.

Юлга яңа чыккандагы Роберт белән бүгенге Робертны чагыштырып карыйм. Әлләни үзгәрмәгән дә кебек: балалык сафлыгын, ихласлыгын, шаянлыгын саклаган. Бу сыйфаты аны Халыкара Андерсен исемендәге диплом, яшьләрнең Муса Җәлил исемендәге бүләген алырлык балалар шагыйре иткән. Роберт «Дөньядагы иң зур алма» үстереп, бишкә генә түгел, йөзгә, меңнәргә бүлеп, балаларга өләште. Балачак хисләрен югалтмавы, аны акыл һәм тормыш тәҗрибәсе белән баетуы Робертның үзен дә, шигъриятебезне дә укучыга якынайтуда актив катнашты. Ул — олыларның да үз шагыйре.

«Олы Роберт»ның хәзер акыл ияләренең үзе белән дә, үзләре турында гына уйлаучы ялган милләтпәрвәрләр белән дә, икейөзле вә бер йөзе дә булмаган бәндәләр белән дә мәйдан уртасына басып бәхәсләшерлек көче-куәте бар.

Иҗтимагый-сәяси тормышның үзәгендә, тормыш каршылыклары эчендә яшәү, хаксызлыкларны күрү аның иҗатына усаллык дигән тагын бер кирәк сыйфат өстәде. Робертның шигъриятенә үзе яраткан шагыйре Такташның сүзләре бик килеп тора:

Үзе көлә, үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Беренче китабына фатиха бирүче буларак, яратуымны яшереп, купшы сүзләрдән качарга тырышсам да, үз сүзләрен үзгәртеп әйтәсе килә: «Усаллардан яклар өчен, дөнья ямьле булсын өчен» шагыйрь кирәк! Роберт Миңнуллин кебек шагыйрьләр кирәк!

Шагыйрьләрнең нинди икәнен беләсегез киләме?

Шагыйрьләр төрле була...
Аларны булмый аңлап —
Шагыйрьләр серле була...

Әнә шундый шагыйрь сезне үзе йөргән догалы юлга чакыра. Чыгасызмы?

Мин чыгам.

Хәерле юл безгә!

*1 февраль, 1998*

# *Көткәндә килгән кунак*

Зөлфәт поэзиябезгә көткәндә һәм көтмәгәндә җилдереп, дулаган ат шикелле килеп керде. Өлкәнрәк абзыйларның кайберләре бу тәвәккәл җайдактан куркыбрак та калдылар. «Чакырылмаган кунак татардан да яманрак» дигән мәкальгә каршы бунт күтәреп шигырь язып кара әле син 60 нчы елларда! Әмма ул чакта да Зөлфәтне аңлаучылар, яклаучылар да бар иде ич: яшь шагыйрь бу шигыре белән Казанны гына түгел, Мәскәүне дә яулады. Зөлфәт минем өчен шагыйрь буларак шул шигыре белән туды. Шуннан соң мин аны югалтмадым: һәрбер шигырен кызыксынып укыдым.

Зөлфәт китап чыгару белән мавыкмады. Җитмешенче елларда «Язмышлар ярында», «Утлы бозлар», 1990 елда «Адашкан болыт». Мөмкинлекләр булган елларда — барысы өч китап!

Һәм менә яшь шагыйрьнең... (ялгыштым: хәзер инде тәҗрибәле өлкән шагыйрьнең) «Ике урман арасында» исемле сайланма әсәрләре дөнья күрде. Бу елларда басылган теләсә нинди шигырь китабы гаҗәп булса, бу китапның чыгуы — бигрәк тә гаҗәп! Китапның тышында ук дәһшәтле кызыл төс: рәссам шагыйрьнең үзенчәлеген тойган.



Мәскәүнең Лихачев исемендәге заводында. Зөлфәт, И.Юзеев, Г.Ахунов

Моңа кадәр мин Зөлфәтнең аерым-аерым шигырьләрен укып белә идем. Монда аның утыз еллык иҗаты тупланган. Ике төн йокламыйча укыдым. Әмма көндезен дә ару-талу белмәдем, киресенчә, тәнемдә рухи көч артканын сиздем.

Зөлфәтебез үзе тоткан, өйрәткән, иярләгән аттан һаман төшмәгән: аның поэтик кыюлыгы арткан гына. Барыннан да бигрәк Зөлфәт — үз драмасын да, адашкан буын фаҗигасен дә язучы трагик шагыйрь.

Аңламый мине оныгым,
Ишетми мине бабам.

Ике урман арасында бәргәләнә шагыйрь, кыйнала. Әмма ул мескен түгел, аның романтик табигате күккә ашарга омтыла, әмма газап-кайгылар аны җирдән ычкындырмый: «Бәрелде баш биек йолдызга».

Зөлфәтнең кайбер шигырьләре бер укуда гына аңлашылмас та, бәлки... Мин аның «Пиросмани» турындагы шигырен кат-кат укыдым. Мондый шигырьләр әзерлекле, зыялы укучыны сорый. Болары да булсын: поэзия гади укучыдан алдарак барырга тиеш тә. Әнә шул миссиясен югалтуы сәбәпле җыр жанры үзешчән дәрәҗәдә бер урында таптана, алга китә алмый. Юк, Зөлфәт элитар шагыйрь түгел, нигездә, ул барлык укучылар аңларлык итеп яза белә.

Шигырьләренең югары дәрәҗәдәге халыкчанлыгын әкият, бәет, дастан, җырларга таяну, нигезләнү баета. Гади фактны әкияти югарылыкка күтәрү алымы баллада жанрына китерә. Поэзиябезнең бик сирәк кулланылган бу төрендә Зөлфәттән дә активрак, уңышлырак иҗат иткән башка шагыйрьне мин белмим.

Берәр прозаикка эләксә менә дигән хикәя язарлык тормыш материалын ала да, шигырьгә йә поэмага әйләндерә. Вакыйгага нигезләнгән сюжетлы шигырьне поэтик язу осталыгы тагын кемдә бар икән?

Зөлфәттә кайсы шагыйрьнең тәэсире көчлерәк? Туфанмы, Бабичмы, Есенинмы? Тегесе дә, монысы да бардыр, әмма аларны көчле яратудандыр. Зөлфәтнең үз тавышы да башкалар тәэсирендә югалып калырлык түгел. Әйтик, «1937 ел» шигырен Туфан стилендә язу табигый дә, аклана да.

Зөлфәт шагыйрь генә түгел, тылсымчы да. Шигырьне дога итеп күрә. Хәзерге кайбер ялган мулла догала-

рының күк катларына ирешүенә мин шикләнәм, әмма шагыйрь догасы кабул булыр!

Бер дә кимчелекләр юкмыни соң бу китапта? Гадәттә, зур шагыйрьнең кимчелекләре дә вак, кояштагы тап кебек кенә күренә, аларны әйтеп тә торасы килми. Сүз бу очракта утыз ел буена шигъриятебездә ат уйнаткан, үз тавышын бөтен көченә ишеттергән, балалар уку китапларында ятларлык гүзәл шигырьләр иҗат иткән шагыйрь турында бара. Бездә, Аллага шөкер, талантлы шагыйрьләребез шактый күп, әмма Зөлфәт кебек шигъриятебезне югары дәрәҗәдә тоткан, Тукай, Такташ, Туфан, Хәким традицияләрен лаеклы дәвам иткән шагыйрьләребез күп түгел. Кадерен белик аларның!

Бу китапның сезнең өйләргә дә чакырылган, көтелгән кунак булып керүенә ышанам.

*1995*

## *Кыллары өзелсә дә...*

Яшь шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның исемен беренче тапкыр «Ялкын» журналында эшләгәндә, моннан уналты-унҗиде еллар элек ишеттем. Әдәбият бүлеге мөдире Г.Сабитов ашыгып керде дә безгә бер шигырь укып күрсәтте:

Әй кыш килгән, кыш килгән,  
Морҗа ак бүрек кигән.  
Кисмәктәге су туңган,  
Ватып алырлык булган.

Шигырь безгә шунда ук ошады. Ләкин аның бер кимчелеге бар иде, автор нишләптер шигырен акка күчереп тормыйча, каралама хәлендә җибәргән. Шигырен журналга тәкъдим иттек, ә үзенә, шелтәләп, хат язып салдык. Редакциягә кульязмаларны ачык итеп кара белән язып җибәр, алай ярамый, янәсе. Ул егет шул ук вакытта рәсемнәрен дә җибәрде. Алар гаҗәп матур эшләнгәннәр иде.

Безнең үпкәбезгә аңардан җавап хаты килде. Кыска гына язылган юлларда «мин бит инвалид» диюдән башка сүзләр юк иде.

Берничә ел узгач, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, яшь язучы Рәшит Зәкиев сәләтле бу егетнең язмышын газета аша укучыларга хәбәр итте.

Үзе турында берни дә әйтмәгән Гакыйль урында хәрәкәтсез ята һәм каләмне тешләренә кабып иҗат итә икән. Аның иҗаты һәм тормышы белән укучылар ныграк кызыксына башладылар.

Яхшы шигырь безне дә ерак юлга чакырды. Шәүкәт Галиев белән бергәләп, ерактагы Куйбышев өлкәсе Кошкинск районы Иске Фәйзулла авылында яшәүче Гакыйль Сәгыйров янына киттек. Норлат районында безгә Рәшит Зәкиев кушылды.

Һәм менә без аның өендә. Ул да, без дә, әнисе Хәбибҗамал апа да башта каушап, сүз табалмыйча тордык. Китап киштәсендәге бер китап сүзне башларга ярдәм итте.

«Хөсәен Ямашев». Автор үзе бүләк иткәндер инде?

— Әйе, күптән түгел Норлатка килгәч, Расих абый, Гөлшат Зәйнашева һәм Роберт Әхмәтҗановлар кергәннәр иде.

Без алып килгән әманәтләрне, автограф язылган китапларны, хатларны тапшырабыз. Гакыйльдән шигырьләрен күрсәтүне сорыйбыз. Менә балалар өчен язылган бер шигырь:

Антеннада ике карга
Тирбәлә кунган көйгә.
Шуларны күрде дә Дилә
Йөгереп керде өйгә.
— Әнием, телевизорны
Тизрәк инде кабыз,— ди,—
Анда кунган каргаларны
Күрмичә калабыз,— ди.

Без рәхәтләнеп көләбез. Балаларча, яңача, үзенчә... Шул вакыт түр бүлмәдәге телевизорга күз төште. Аны Гакыйльгә Татарстан нефтьчеләре бүләк иткән икән. Лениногорск киностудиясеннән килеп аны кинога да төшергәннәр. Гакыйльне больницага алып китеп, Лениногорск врачлары дәвалаганнар да. Вертолет туп-туры Гакыйльләрнең ишегалдына төшкән.

Яшәве дә авыр, үлеме дә,
Тормыш өчен көчең салмагач.
Үзең үлсәң, сине күңелләрдә
Яшәтерлек эшең калмагач.

Бу юлларны укыганда кулына кулъяулык тоткан яшь егет килеп керде. Ул сүзсез генә шигырьне тыңлап торды. Бу юллар аңа тәэсир итте булса кирәк, кызлар бүләк иткән кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды.

— Сау булыгыз, Гакыйль абый, армиягә китәм.

Солдатка китүче егет кай ягы беләндер Әсгать Җиһаншинны искә төшерде. 49 тәүлек океанда йөреп, дөньяны шаулатып кайтканнан соң, мин Әсгать Җиһаншинның туган авылы Шенталага, герой янына килгән идем. Ә Шентала моннан әлләни ерак түгел. Гакыйль герой якташы турында элегрәк шигырь дә язган:

Күргәнем бар кебек,
Таныш йөзләре.
Туганнарым кебек
Якын үзләре.

Иң авыр минутларда, инде түзәр хәл калмаганда Гакыйль, мөгаен, якташы Әсгатьне күз алдына китергәндер.

Илебезне сакларга баручы егет ниләр уйлагандыр, белмим, әмма ул тирән уйга батып чыгып китте.

Гакыйльнең лирик шигырьләрен укыгач, без дә уйга калдык.

Килер бер көн — үкенүдән янып,
Газапланып, ятып үләрмен.
Әмма мәңге хәтеремдә калыр
Матурлыгы тормыш-гүзәлнең.

Әмма болар тормышның матурлыгын раслау өчен күңелдән тулып чыккан утлы сүзләр. Гакыйльнең шигырьләре моңландыра да, түбән иелгән башны югары да күтәрә.

Без җитәсе җирләр ерак әле,
Без барасы юллар киртәле.
Бир ышанып миңа кулларыңны,
Чын иптәшем булып күтәрел!

Гакыйльнең тәрәзәсеннән карга оялары белән чуарланган топольләр күренеп тора. Гакыйль аларны менә ничек күрә:

Аяз иртәләрдә
бәбкә казлар сыман
Топольләрем очыра мамыгын...

Морҗасыннан төтен чыгучы өйне күргән шагыйрь менә нинди нәтиҗә ясаган:

Аяк-кулын бәйләп куйган язмышының
Чылбырларын өзеп читкә атты микән? —
Морҗасыннан нинди кара төтен чыга,—
Әллә соң ул кайгыларын якты микән?

Гакыйль дөньяга художник күзе белән карый: аның сизгер йөрәге табигатьтәге, тормыштагы буяуларны, контрастларны, нечкәлекләрне тотып ала белә.

Тормыш агай алып кукрәгемнән
Бирсә бирде минем кирәкне.
Һаман саен һәрбер матурлыкка
Сизгеррәк итте йөрәкне.

Гакыйль шигырьдә — художник, рәсемдә — шагыйрь. Шигырь юлларына кергән теге топольләрне ул натурадан кәгазьгә дә төшергән. Әмма Гакыйль фотограф түгел. Ул топольләрне үз хыялы белән баета, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Шул ук вакытта ул топольләрне Гакыйльнең читкә киткән һәрбер авылдашы танып алыр һәм: «Аһ, шул топольләрне кайтып бер генә күрәсе иде!» дип әйтер...

Гакыйльнең үзен күргәч, яңа шигырьләрен тыңлагач, элек язылган хатыбыз өчен уңайсызланып киттем. Шигырьдәге һәрбер хәрефне язу яки рәсемдәге һәр ноктаны кәгазьгә төшерү өчен күпме чыдамлык, тырышлык кирәк. Шулай да аның язу матурлыгын күреп гаҗәпкә каласың. Шигырьдә дә Гакыйльнең үзе генә тапкан алымы бар. Шагыйрьнең үзенчәлеге кешенең, табигатьнең матурлыгын эзләүгә, укучыда оптимистик рух уятуга юнәлгән. Гакыйль поэзиянең төрле өлкәсендә үзенең көчен сыный: лирика, сатира-юмор, балалар өчен шигырьләр...

Бу сәяхәттән без үзебез өчен яңа шагыйрь ачып кайттык.

...Дошманнары, сәхнәгә чыгар алдыннан, тылсым иясе Поганининың скрипка кылларын өзеп, бер генә кылын калдыралар. Әмма бөек скрипач югалып калмый, бер кылда катлаулы көйләрне шулкадәр матур уйный, тыңлаучылар кылларның өзелүе турында уйламыйлар да.

Язмыш Гакыйль Сәгыйровның да тормыш кылларын өзәргә уйлаган. Ләкин берничек тә батыр егетнең күңел кылын өзә алмаган. Ул әнә шул өзелмәс нечкә кылда тагы да матуррак уйнар әле.

*1970*

# ШИГЪРИЯТ ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘЛӘР

## «Шигърият — үзе җыр юл»

*Әңгәмәдәш — Ким МИҢНУЛЛИН*

***Ким Миңнуллин.*** *Җәмгыятьтә барган кискен үзгәрешләр җыр сәнгатебезгә дә тәэсир итми калмады. Кыска гына вакыт эчендә татар сәхнәсен яңа стиль-юнәлешләрне якынрак күргән җырчылар яулап алды. Берәүләр бу борылышны: «Ниһаять, без дә баянга ияреп җитди җырлар җырлаудан арындык»,— дип, хуплап каршы алды. Икенчеләр исә моны җыр, сәхнә традицияләребездән читләшү дип кабул итте. Чыннан да, җыр дөньябызның бүгенге хәленә бәя бирү, аны аңлау-аңлату җиңел түгел. Шуңа күрә, җырларыбызга багышланган әлеге әңгәмәләр циклын башлап җибәрү урынлы булыр кебек. Беренче булып үз фикерләре белән уртаклашу өчен без Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевка мөрәҗәгать иттек.*

*— Илдар абый, Сезне әдәбиятка, халкыбыз күңеленә япь-яшь чагыгызда, яшен чагыгызда иҗат иткән «Таныш моңнар» поэмасы белән килеп керде, диләр. 50—60 нчы елларда Сезнең әсәр тәэсирендә яңа туган балаларга Зөфәр, бигрәк тә Резидә исемнәрен кушу ешаеп киткән, дип тә ишеткәнем булды. Инде еллар узгач, бу әсәрегезнең уңышы турында уйлаганыгыз бармы? Шуның серен ача алдыгызмы?*

**Илдар Юзеев.** Дөресен әйткәндә, мин бу поэма заман сынауларын үтә алмас, дип уйлаган идем. Әле берничә ел элек кенә шундый шик бар иде. Чөнки замана бик нык үзгәрде. Күп әйберләр, шул исәптән минем дә шигырьләр, кайбер җырлар төшеп калды. Ә «Таныш моңнар» һаман да яшәвен дәвам итә. Мәктәпләрдә дә, башка җирдә булган очрашуларда да бу әсәр белән кызыксыналар, ничек язылуын сорыйлар. Әлбәттә, монда «Резидәкәй» җырының таралуы да роль уйнагандыр. Аңа көйне иң сәләтле

композиторларыбызның берсе Шакир Мәҗитов язды һәм яңа гына консерватория тәмамлап йөргән Илһам Шакиров башлап җырлады. Поэманың тагын бер кызык ягы бар: халыкта әсәрнең теләсә кайсы өзеген алып, «Резидәкәй» җыры көенә башкаралар. Мәхәббәт турындагы өлешен, башка урыннарын. Әлегә кадәр яшәвенең бер хикмәте дә поэманың музыкальлегендәдер, дип уйлыйм.

***К.М.*** *Сез 70 тән артык җыр авторы. Аларның күбесе бүген дә яратып җырлана. Беренче җырларыгыз кайчан язылган иде? Аларның язмышы ничек булды?*

**И.Ю.** Минем иң беренче җырым 50 нче еллар башында Казанның педагогия институтында укыганда язылды. Без Ләбиб Айтуганов белән бер чорда укыдык. Ул Минзәлә педучилищесын тәмамлап, миннән ике елга соңрак килде. Бу училищедан килгәннәр музыкаль яктан бик белемлеләр иде: нотаны да беләләр, җырлыйлар да. Ләбиб мандолинада бик әйбәт уйный һәм көйләрне нотага төшерә иде. Аның белән язган иң беренче җырыбыз — «Карлыганым-бөрлегәнем». Мин моны махсус җыр итеп яздым. Аны студент Спартак Әхмәтов институт сәхнәсенә чыгып җырлады. Аннан соң без «Төнбоек» дигән җыр яздык. Күпмедер вакыт бу ике җыр студентлар арасында, халыкта болай гына җырланып йөрде. Нишләптер, артистлар да, радио да игътибар итмәде. Соңрак, Л.Айтуганов радионың музыкаль редакциясендә эшли башлагач, аларны җырчыларга тәкъдим иткән. Шуннан соң инде «Карлыганым-бөрлегәнем» Сөләйман Йосыпов, ә «Төнбоек» Әлфия Авзалова башкаруында бик популярлашып киттеләр. Болар, сирәк булса да, әле дә яңгырыйлар.

***К.М.*** *Күргәнебезчә, Сезнең шигырьләрегездән дә, поэмаларыгыздан да затлы-затлы җырлар туа. Сәхнә әсәрләрегездәге җырлар да театр бинасына гына сыеша алмый, халыкка тарала. Татар дөньясында Сезнең «Кайтам инде» (С.Садыйкова көе), «Мәтрүшкәләр» (А.Гыйләҗев), «Кыр казлары артыннан», «Туган ягым каеннары» (М.Имашев) һәм башка бик күп җырларыгызны белмәгән кеше юктыр. Җыр тексты сезнеңчә нинди булырга тиеш? Аны язуның берәр үзенчәлеге бармы?*

**И.Ю.** Мин, нигездә, шигырь язам, соңыннан алар җырга әйләнә. «Хуш инде» әсәре белән шулай булды. Ул минем 60 нчы елларда ук китапта басылып чыккан иде.

80 нче елларда гына җыр булып китте. Буа районына әдәби очрашуларга баргач, бер кыз шушы җырны җырлый. Мин әйтәм: «Кемнеке бу?» «Халыкныкы»,— ди. «Сүзләре кемнеке?» — дим. «Халыкныкы»,— ди бу тагын. Шигыремнең бер сүзе дә үзгәрмәгән иде. Берничә елдан соң гына көенең авторы килеп чыкты. Ул — Фирзәр Мортазин иде. «Мәтрүшкәләр», «Ике малай китә армиягә» җырлары белән дә шулай булды. Минем өчен җыр тексты язуның аерым үзенчәлекләре юк. Шигърият үзе җыр ул. Тукай бит юкка гына әйтми: «Җырлыйҗырлый үләрмен мин үлгәндә дә»,— дип. М.Җәлил дә: «Җырларым, сез шытып йөрәгемдә», ди. Димәк, безнең бөек остазларыбыз да шигырьне җыр итеп күргәннәр. Тагын шуны гына өстәргә була: шигырьне бөтен кеше дә укымый, җырны барысы да тыңлый. Күңелендә аз гына моңы булганы, хәтта моңы булмаганы да. Шунлыктан, шигырь үзе дә җыр кебек язылырга тиеш. Бу — шагыйрь өчен кеше күңеленә керүнең бер чарасы. Шул вакытта шигырь үтемлерәк була. Такташ юкка гына әйтмәгәндер: «Шагыйрь — композитор да булырга тиеш»,— дип. Ул туры мәгънәсендә әйтми, С.Сәйдәшев кебек композитор булырга тиеш дими. Юкка гына «Йосыф-Зөләйха»ларны, Тукай шигырьләрен дә көйгә салып укымаганнар. Кеше күңеленә керү өчен күпер ул җыр.

***К.М.*** *Шигырь җыр кебек язылырга тиеш, дидегез. Җыр тексты язганда шагыйрь аның көен тоемлый аламы? Яисә җырның көе менә шундыйрак булса иде, дигән теләк тумыймы?*

**И.Ю.** Мин яшьтән үк гармун уйнарга яратам. Хромкада уйныйм. Бервакыт баянда да булышып алдым. Ә менә бер генә көй дә язганым юк. Мин аны яза да алмыйм, хәтта тоемлый да алмыйм. Гомерем буе композиторларга сокланып яшим. Шулай да, шагыйрьнең музыкага якын булуы аның иҗатына бик нык ярдәм итә. «Өчәү чыктык ерак юлга» дип аталган музыкаль поэмам бар минем. Ул төрле ритмда язылган. Поэмага ритмны баян тартып утырганда үзем таптым. Шигырьдәге музыкальлекнең тагын бер кызык ягы бар. Фасил Әхмәтов белән без күптәнге дуслар. Берничә җырыбыз да бар. Бервакыт Фасил әйтә: «Дус булып йөрибез, ә бөтен халыкка яңгыратырлык җыр язганыбыз юк. Ни өчен икәнен әйтимме?» — ди. Әйтеп кара, мин әйтәм.

«Синең шигырьләреңнең музыкасы үзендә. Эзләнәсе юк анда. Башка берәүнең шигырьләрен алсам, музыкаль образын үзем табам»,— ди. Бик кызыклы фикер бу.

*К.М. Сездәге музыкальлек, ритмны тою, җыр-моңныярату каян килә?*

**И.Ю.** Бишектә тирбәткән чагында ук әни миңа мандолина уйнаган. Ә инде үзем белә белгән вакыттан әни безне Нил белән (Нил Юзиев фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты) мандолинада уйнарга өйрәтте. Иң беренче «Карабай»ны өйрәндем, башкорт көен. Аннан соң «Дим буенда»ны. Әтинең гармунда уйнавы да эзсез калмагандыр. Әнинең энесе Зөфәр абый да гармунчы иде безнең. Сугышка китеп, 1941 елда ук һәлак булды. «Таныш моңнар»га да исем шуннан алынды. Кечкенә вакытта менә шундый музыкаль тәэсир булды миңа.

*К.М. Сез иҗатыгызның беренче чорында ук җыр тексты музыкадан башка да яши алырга тиеш, дигән принципны яклап чыктыгыз. Соңгы вакытта җыр текстлары шигырьлекләрен югалтып баралар. Музыкага гына төренеп дөньяга килгәннәренең саны артканнан арта. Бу хәл Сезнең фикерегезне үзгәртмәдеме?*

**И.Ю.** Әйе, җырда бик тә йомшак, зәгыйфь текстлар күпкә артты. Танылган гына шагыйрьләр арасында да мондый текстлар белән үз бәясен төшерүчеләр бар. Кайбер шагыйрьләрнең шигырь китапларын, шигырьләрен укымыйлар һәм ул җыр тексты белән күренергә мәҗбүр була. Текст язуда да, көй язуда да үзешчәнлек массовый төс алды. Шуңа килеп бизнес өстәлде. Болар барысы да, ахыр чиктә, җыр сәнгатенә, телебезгә бик зур зыян китерәчәк. Шунысы да кызганыч, бик тә зәгыйфь текстлар матбугатта да басылып тора. Ә инде Сез искә алган сорауга килсәк. «Җыр тексты музыкасыз да яши алырга тиешме, түгелме?» Бу — шагыйрь өчен иң зур таләп. Мин аннан баш тартмыйм. Нигездә, бу таләп дөрес. Әмма бары тик шулай гына булырга тиеш, дип әйтмим. Шагыйрьләр күп була, күптөрле була. Аның шулай булуы хәерле дә. Махсус җыр текстлары гына язучы шагыйрьләребез дә бар безнең. Тик шунысы ачык: шагыйрьнең йөзләгән җырыннан берничәсе яшәп кала икән, шул таләпкә җавап биргәне генә калачак.

*К.М. Үзегезнең бу таләпне үтәмәүче җыр текстларыгыз бармы?*

**И.Ю.** Махсус җыр тексты итеп язганнар арасында бу таләпне үтәмәүче җырлар очрый. Мәсәлән, әзер көйгә җырлар тексты язган очраклар була. Яратмыйм мин аны. Композитор күңеле белән минем күңел туры килми икән, текст интегә-интегә языла. Һәм шул интегү текстта сизелә дә. Ш.Мәҗитовның «Шофер», М.Яруллинның «Яшьлек дустыма» көйләренә язылган текстлар белән шулай булды. Әмма әзер көйгә язып, уңышлы чыккан җырлар да була. Мәсәлән, «Серле чәчәк» (М.Яруллин), шул ук «Яшь наратлар». Әзер көйгә текст язылырга тиеш түгел, дип исәпләмим мин.

***К.М.*** *Җыр текстларыгызда сүзләр һәм тәгъбирләрнең уңышсыз кулланылган очраклары буламы?*

**И.Ю.** Халыкка таралып киткән җырларда аз гына фальшь бар икән, халык аны үзе алып ташлый, яисә төзәтә. Минем «Яшь наратлар» җырына халык бер зур булмаган гына үзгәреш кертте. Җырның өченче строфасында «Әле дә булса минем колагымда көмеш кыңгыраулар чыңлыйлар» дигән юллар бар. Халык «колагымда»ны «йөрәгемдә»гә алыштырган. «Күңелемдә» варианты да бар. Мәгънә ягыннан минем вариант дөресрәк, әмма җырдагы хис, тойгы «йөрәгемдә»не якынрак иткән.

«Мәтрүшкәләр» җырына карата да фикерләр ишетергә туры килде. Янәсе, мәтрүшкә файдалы дару үләне ул. Мәтрүшкә кипсә, әйбәт кенә була. Аны киптереп эчәләр. Мин әйтәм: «Сез мәтрүшкәне дару итеп кенә кабул итәсез». Саргаю, өзелү нәрсәгә караса да әйбәт түгел. Бу очракта, мәтрүшкәнең өзелүе — чәчәкнең өзелүе, саргаюы ул. Мондый фикерләрне ишеткәч, мин бик озак уйланып йөрим. Күңелгә тынычлык бирми. Чыннан да хаклык бармы монда, дип уйлыйм. Җавап эзлим.

***К.М.*** *Бүгенге көн җырлары турында сүз барганда, еш кына «халыкка ошый бит», «халык яратып тыңлый бит» кебек сүзләр ишетергә туры килә. Сәнгать кешесе халыкка хезмәт итәм, дип, аңа ошаган әсәрләр генә иҗат итеп, аңа ияреп кенә барса, дөрес булыр идеме?*

**И.Ю.** Әйе, сәнгать кешесе халыкка хезмәт итә. Әмма ничек хезмәт итәсең бит. Әйтик, Тукай яисә С.Сәйдәшев, халыкка хезмәт итәм дип, алар артыннан гына ияреп барсалар, шигъриятебез дә, музыкабыз да беркайчан да шушындый югарылыкка күтәрелә алмас иде. Югары сәнгать һәрвакыт халыктан алдарак барырга һәм халыкның рухын чагылдырырга тиеш.

# Җырым минем һич бетәрлек түгел...

*Әңгәмәдәш — Таңчулпан.*

— *«Җырым минем һич бетәрлек түгел,*
*Куларбамда гына бер капчык...»*

*Илдар абый, Сезнең беренче шигырегез 1943 елда язылган. Сез беркайчан да каләмегезне кулдан төшермәдегез, хәтта соңгы елларда лирикагызның көчәюен күрәбез. Хикмәт нидә?*

— Мин шигырьсез яши алмыйм. Урамда танышлар очраганда да, кайчак рифма белән әйтелә. Шигырьне ташлап ял итәргә уйласам, ул төшкә килеп керә. Әйе, минем төштә язган ике шигырем бар.

*«Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,*
*Кулларым каләмгә үрелә...»*

— *«Илһам килгәндә һәм киткәндә» Сез ниләр кичерәсез?*

— Үземнең шигырьдәгечә, «бу мәлдә кирәкми берсе дә: шашынам, тилерәм, очынам». Зуррак әсәр яза башласам, куркакка әйләнәм. Урамга чыккач, машина таптап китмәсен дип, бик сак йөрим, ул-бу булса, әсәрем языдып бетмичә кала бит. Хәзер нинди чагыммы? Урам аркылы кызыл утка да каршы йөгерәм. Әле генә яңа драма тәмамладым.

— *«Сөйгән ярым минем ике хәзер:*
*Берсе — Лира, берсе — Драма».*
*Кайсын ныграк яратасыз?*

— Лираны. Драма авырлык белән бирелә.

— *«Такташ җене, Такташ рухы синдә,*
*Ашкынулы, тиле романтик...»*

*Сибгат ага Хәкимнең үзегезгә багышланган бу юлларына карашыгыз ничек?*

— Белмим, хәзер мин романтик микән? Яшьлек елларымда булганмындыр. Уфа һәм Казан университетларында языдып яткан диссертацияләрдә, нишләптер, минем шул ягыма басым ясыйлар. Яшь галимнәр, бәлки, яңача аңлатырлар. Яшьлектә «Янар чәчәк» турында язсам, хәзер бер шигырем «Янган чәчәк» дип атала. Романтикага тормыш фаҗигасе килеп керә һәм аны күктән, хыялдан җиргә сөйрәп төшерә.

— *«Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп,*

*Алтын көзгә,*
*Ачык йөзгә,*
*Бөдрә тупылга...»*

*Шагыйрь абый, сез бу юлларны язган көннән алып утыз еллап вакыт узган. Сез һаман да шулаймы, дөньяга гаҗәпләнеп багасызмы?*

— «Багасызмы?» Такташ гап-гади ул мишәр сүзенә нинди матур шигъри аһәң бирде. Багам, бик багам, Таңчулпан. Шул сыйфатым бетсә, кулымнан каләм төшәчәк.

— *«Үлем эзләп йөрсәң, әҗәл алмый,*
*Ә авырсаң, килми үләсе...»*

*Бу нинди каршылык? Сездә, халык шагыйре исеме алган шагыйрьдә, андый уйлар туамы? Булмас...*

— Бүгенге көннең аяусыз шәфкатьсезлеге әллә мине читләтеп үтә дисезме? Шатлык, сөенечләре белән бергә җан газаплары миңа да ят түгел. Хәзер инде мондый уйлардан ваз кичтем. Ни өченме? Сабадагы бер очрашудан соң, минем яныма өлкән яшьтәге Тәскирә Бибарсова дигән ханым килде. «Зинһар өчен сез яши күрегез, мин авыр хәлдә сезнең шигырьләрегездән рух алып яшим. Әгәр дә сез дөньядан китсәгез, мин дә икенче көнне үк үләм»,— диде ул. Бу сүзләрдән соң әҗәл турында уйлау — оят. Бибарсова ханым, рәхмәт сезгә!

— *«Әйтегез, җан нидән яралган?»*

*Үзегез биргән бу сорауга җавап таптыгызмы?*

— Тапсам, мин аны укучыларымнан сорап та тормыйм.

— *«Нишләр идем, әгәр:*
*Толлар-ятимнәргә күзне йомып,*
*Үзем өчен Сарай салдырсам,*
*Үземнән соң якты рух калдырмый,*
*Җир йөзендә тик мал калдырсам?..»*

*Юк. Сезгә бу куркыныч янамый. Әмма яшәешебездә таш пулатлар салдырып, шуларга табынып яшәүчеләр саны күбәйгәннән-күбәя. Мал җыю шаукымы «Яңа татарлар» дигән аңлаешсыз төркемне тудырды. Алар бит шигырь укымый, Илдар абый. Бу афәттән котылу юлын күрәсезме?*

— Минем яңа драмам нәкъ шул хакта. Мондый хәл тормышка да, аларның үзләренә дә фаҗигага китерәчәк. Минемчә, мал шәфкатьлеләр, изге күңелләр кулында тупланганда гына, тормыш алга китәр.

— *«Шагыйрьләр нигә картаймый?»*

*Сез үзегез картаясызмы?*

— Мин көзгегә карамыйм. Фоторәсемнәрнең дә яшь чактагыларын гына карарга тырышам. Нинди картаю ди ул? Гүзәл кызлар узып киткән саен, муен артка борыла. Шигырьләрем минем — унҗидедә...

— *«Үрнәк түгел, миннән була*
*Бары гыйбрәт алып...»*
*Сез укучыларга үрнәк түгелмени, Илдар абый?*

— Юк. Дипломым булса да, мин педагог түгел. Үземдәге төрле халәтне: йомшак якларны, кимчелекләрне дә ачып салырга тырышам. Кайчак үз-үзем белән көрәшеп, җиңеп тә куйгалыйм.

— *«Хатлар язам. Көтәм, бу арада*
*Нигә килми, әнкәй, хәбәрең?!»*
*Әнкәй турындагы җырлар ташкынына соңгы елларда сезнеке дә өстәлде. Ни дә булса әйттем дип уйлыйсызмы?*

— Мин бу җырның ничек туганын белми дә калдым. Композитор Мәсгут Имашевка Академия театрында куелган бер спектакльгә җыр кирәк булган. Ул андый шигырьне минем 1959 елда чыккан «Әнкәй» поэмасыннан тапкан. Андый хәлләр булгалый. Сафьян Ибраһимовның «Сине уйлап янам» җырын минем 1954 елда язылган «Миләүшә» поэмасыннан алынганын күпләр белмиләр дә.

— *«Җырсыз-телсез калган сандугачлар*
*Туган илләренә кайтсыннар...»*
*Совет хакимияте елларында мондый кыю милли фикерне ничек үткәрделәр икән?*

Милли мәсьәләгә килгәндә, аңа бәйләнмәделәр дә. Фикер яшерелгән иде: сүз телсез сандугачлар турында бара ич.

— *«1985 ел.*
*Халкың инде күптән онытылган.*
*Тик патшалык итә хаким бер тел,*
*Туган телең исә йотылган».*
*Бу — Сезнең 1968 елда чыккан «Соңгы сынау» драматик поэмасыннан. Сез үз фикерегезне Мефистофель авызыннан әйттерәсез. Монда да шул ук алыммы?*

— Сез дөрес аңлагансыз. Ул елларда турыдан-туры әйтү мөмкин түгел иде.

— *«Син күптән халык шагыйре,*
*Ярамыйга карамый...»*

*«Кызыл таң» газетында басылган бу юлларыгыз Уфада яшәп иҗат итүче Әнгам Атнабаев турында.*

— Әйе, халык шагыйре исемен Атнабайга бик озак көттерептерeп, «соң булса да, уң булсын» дигән кебек бирелде. Без аны шундый олы исеме белән рәхәтләнеп, сөенеп котладык.

Авыл аралары унике чакрым гына булган ике татар шагыйре ике республикада яши. Әнгам миңа багышланган шигырендә язганча, «анда сине башкорт дигәннәрдер, монда мине татар диделәр». Без икебез дә Тукай телендә иҗат итүчеләр, Сак-Сок шикелле, бер-беребездән чикләр белән аерылганбыз. Хәзер «Башкортстанның татар телле язучылары» дигән берлек тә барлыкка килде. Әнгамга Указ белән зур исем бирелгәч, мин сөенү белән бергә, сәер бер хис кичердем; без чынында ике республика указы нигезендә, икебез дә бәләкәйләнеп калдык: Мин — Татарстанның гына, ул — Башкортстанның гына шагыйре...

— *«Яшь аралаш елмая ул,*
*Югарыда — баласы...»*

— Бу — «Бөркет турында баллада»дан. Бөркет елмаямы? Җырда бу сүзләр символга әйләнгән. Минем «Бөркетләр кыяга оялый» комедиясендәге герой — Баязитны сөйгән хатыны «Бөркетем» дип атый. Монда Баязит — бөркет елмая.

— *«Төнбоеклар, төнбоеклар*
*Күзләрен йомып йоклар».*
*Төнбоек турында бер-берсенә охшаш җырлар күбәйде. Сезнеке кайчан язылган?*

— «Төнбоек» — иң беренче җырыбыз, яшьлек җырыбыз. Мин аны педагогия институтында укыганда 1952 елда яздым.

— *«Нинди матур озын юлга чыктык,*
*Янар чәчәк иде юл башы...»*
*60 нчы елларда бу җырыгыз бик таралган булган. Җыр искерәме?*

— Мин дә элек язылган җырларым бүгенге яшьләргә күчми, искерә дигән уйда йөри идем. Кырык ел элек язылган «Таныш моңнар»дан «Резидәкәй»не мәктәп укучылары, студентлардан еш ишетәм.

— *«Тик очалмыйм, карап калам*
*Кыр казлары артыннан...»*

*Сезнең әсәр буенча куелган спектакльдәге бу җырны күп артистлар башкара. Кайсы кадерлерәк?*

— Һәркемнең үзенчә башкаруы белән кадерле. Спектакль белән таныш булганнар — Ясминәнең онытылмас образын тудырган Исламия Мәхмүтованы җаннарына якынрак кабул итәләр. Аның җыры үзе бер драманы сыйдыра. Зилә Сөнгатуллина җыр ахырында «Кайчан булса да очармын» дигән кечкенә якты өмет калдыра. Күпләр Флера Сөләймmanagованың башкаруын яраталар.

*— «Акчарлакның туган җире — диңгез...»*

*Ә шагыйрьнең? Казан Сезнең өчен туган җир төшенчәсен алыштырамы, әллә «торган җир» генәме?*

— Тукай, Такташ, Җәлилләр торган җир — күңелгә туган җир кебек якын. Казансыз тормышны күз алдына китерә алмыйм.

*— «Очрашырга язсын сезнең белән...»*

*Шагыйрьнең укучылар белән очрашуы китаплары аша гына түгелдер, күзгә-күз очрашулар да шактыйдыр. Соңгы берәр очрашу турында ишетәсе килә.*

— Казан мәктәпләренең берсенә Сибгат Хәкимгә багышланган кичәгә бардык. Шәүкәт Галиев белән без шигырьләр укыганнан соң, сәхнәгә күзлекле бер ханым чыкты һәм искиткеч тавыш белән җырлап җибәрде. Кичә беткәч, аның янына барып, соклануымны белдердем һәм кулын кысып: «Сез Зәйнәп Фәрхетдиновадан да матуррак җырлыйсыз!» — дидем. Ханым елмаеп, оялып рәхмәт әйтте. Өйгә кайтсам, радиодан соңгы хәбәр бирәләр: мәктәптә очрашу булды, кичәдә Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм җырчы Зәйнәп Фәрхетдинова чыгыш ясадылар.

Иллә дә зур бәя биргәнмен Зәйнәпкә!

*— «Таныш, үземнең җырымны*
*Ишеттем әллә каян...»*

*Үзегезнең җырларыгызны ишетү бик күңелләме, Илдар абый?*

— Үз җырыңны ишетү рәхәт инде... Әмма бер вакыйга мине тетрәндерде. Күптән түгел Бауман урамыннан узып бара идем. Үземнең җырымны — «Таныш моңнар»ны ишетеп, туктап калдым. Карасам: минем яшьләрдәге бер хатын гармун уйнап, хәер сорашып утыра. Үз җырыма үзем хәл кадәри акча биреп киттем. Нинди хәлгә

килеп җиттек: хәзер җырым, авыр хәлдә калып, хәер сорый...

— *Бу сорауны да шигырь белән бирергә уйлаган идем, соңгы еллардагы лирикагызны китап кибетләрендә тапмадым. Шагыйрьнең укучыларга яңа китабы килеп ирешерме? Кайчан?*

— Бу сорауны очрашуда укучылар да бирәләр. Күптән инде ун табаклы лирик шигырьләрем Татарстан китап нәшриятында ята. «Чыгарырга хөкүмәт акча бирми»,— диләр. Илле миллион акча бирсәм, басалар. Андый сумманы минем эштә дә, төштә дә күргәнем юк.

— *«Икеләнми киттек сезнең арттан,*
*Басып әзер эзгә...*
*Фатихагыз һаман күңелебездә,*
*Аксакаллар,*
*Рәхмәт инде сезгә!»*

*Бу юлларны Сез кайсы елда язгансыздыр, белмим. Әмма бүген күпләр өчен Сез — аксакал. Татарстан Язучылар берлегенең шигърият остаханәсе җитәкчесе буларак, хәзер яшь шагыйрьләргә үзегез фатиха бирәсез. Шигырьгә яшьләр киләме?*

— Егетләр китә, кызлар килә... Күп кенә яшь талантларыбыз остаханә фатихасын алалар. Килгәннәр арасында да шигъриятгә иң көчлеләре, шигырьгә фанатикларча бирелгәннәре генә калачак. Бөтен өметем — мәктәп балаларында. «Сабантуй» газетында һәрбер сәләтле баланы, бигрәк тә малайларны, дәртләндереп, шигырьләрен чыгарып торабыз. Татар шигърияте яшәр, тагын да көчәер дигән өметтәмен!

— *«Шигъриятнең хәле җиңел түгел,*
*Шигъриятнең җаны яралы...»*
*Шигъриятнең хәле бүгенге көндә ничек, шагыйрь абый?*

— Бу сорауга җавап бирү өчен миңа шул шигырьне дәвам итәргә генә кала:

Шигъриятнең хәле беркайчан да
Булмаган шул рәхәт, җиңел дә...
Ул һәрвакыт Җәлил җыры сыман,
Яшәү белән үлем чигендә.
Шигъриятнең хәле шундый әле:
Кул күтәрсәң — үлем чигендә.
Башлар, җаннар биреп алган үрдән,
Шигырь бәгърем, чигенмә!

*— «Указлы шагыйрь булганчы,*
*Указлы мулла булсам,*
*Бәлки, деннән язмас идем.*
*Гел изге юлда булсам...»*
*Илдар абый, шигырьләрегездә — үкенечләр. Нидән бу?*

— Без бит динсез җәмгыятьтә туган, яшәгән буын. Иҗатта, холыкта бу сизелмичә калмагандыр... Көннәрдән бер көнне мин нәфис сүз остасы Илдус Сафин алып барган кичәдә катнаштым. Кичәдән соң бергәләп сөйләшеп утырганда, мәрхүм болай диде: «Илдар абый, нигә сез борчыласыз? Без бит сезнең әсәрләрегезне җанга сеңдереп үскән яшьләр. Динсез, имансыз елларда сезнең буын шагыйрьләренең шигырьләре безгә мәчетне алыштырды...»

Безнең хакта укучылардан башкалар дәшмәгән бер вакытта мәңге онытылмаслык сүзләр әйтеп, онытылмаслык бәя биреп китте Илдус. Авыр туфрагы җиңел булсын.

*— «Аерым да, бергә дә*
*Булыйк гел үрләрдә,*
*Булыйк гел Гашыйклар тавында!..»*
*Сезнең күпчелек әсәрләрегез мәхәббәт турында. Студентлар сезгә юкка гына «Гашыйк шагыйрь» дигән исем бирмәгәннәр. Сез ул гүзәл тауга күпме укучыларны күтәрдегез. Һаман шулай тауда калыгыз, Илдар абый... Бүген кәефегез ничек?*

— Кәеф — бик күтәренке... бәяләр кебек!

*1997*

## Шагыйрь бәхетле буламы?

*Әңгәмәдәш — Асия Юнысова*

***Асия Юнысова.*** *Илдар ага, алтмыш яшегез тулган көннәрдә хәлегез ничек?*

**Илдар Юзеев.** Элеккеге совет кешеләренеке кебек.

***А.Ю.*** *Бүгенге хәлебез...*

**И.Ю.** Һәммәбезгә билгеле. Хәзерге халәтебезне мин кылычтан үткен, кылдан нечкә сират күперендә асылынып тору белән чагыштырыр идем.

***А.Ю.*** *Без кая барабыз?*

**И.Ю.** Бу сорауны мин сезнең үзегезгә бирер идем.

Безне эти-әниләр революция ясап котылган, Тукаебыз «читен тормыш капиталга чукынмасаң» дип каһәрләгән, капиталистлар үзләре дә канәгать булмаган җәмгыятькә кире алып китәргә ниятлиләр, ахры...

**А.Ю.** *Кемнәр?*

**И.Ю.** Рәсәй җитәкчеләре. Конституциясен кабул иткән суверен Татарстан үзенең халыкларын үз юлыннан алып китсә генә, без упкынга мәтәлүдән котылырбыз дип уйлыйм. Моның өчен узган хаталардан гыйбрәт алган, кылычтан үткен акыллы, кылдан нечкә дипломатиягә ия булган лидерлар зарур. Һәм... шагыйрьләр дә. Сәясәткә башка тыгылмам дип тәүбә иткән идем. Күрәсең, каләм иясе сәясәттән читтә кала алмыйдыр.

***А.Ю.*** *Сез бер гаиләдән ике язучы чыккансыз. Нил Гафурович — Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, тәнкыйтьче. Бер анадан туган ике бала, ничек әдәбиятның ике жанрына киттегез?*

**И.Ю.** Дәү әнкәй безне үз иманына — дингә, әнкәй — уйга-моңга, әткәй — сәясәткә тартты. Әнкәйнең тәэсире икебезгә дә кагылгандыр. Нил акыл юнәлешендә китте. Миндә ул як — чамалы. Язганнарымда бераз моң тапсагыз — әнкәйдән...

***А.Ю.*** *Сез әдәбиятка илленче еллар ахырында килеп кердегез. Хәзерге көн күзлегеннән караганда, үзегезнең иҗатка ничек карыйсыз?*

**И.Ю.** Утызынчы-кырыгынчы еллар шагыйрьләренең фаҗигаләрен кичермәсәк тә, безнең — үз драмаларыбыз. Бишектән үк канга, җанга сеңдерелгән юлбашчыларга — башта — Ленинга, аннан — Сталинга мин бала һәм яшь чакта ихлас ышандым. Аларга багышланган шигырьләремдә ялган юк. Әмма без хәзер сәясәткә сукырларча иярүдән, беркатлы иллюзияләрдән арынып киләбез. Шулай да ялган сәясәткә ышану минем язганнарымның бер ягы гына. Аларның хискә, чынбарлыкка нигезләнгән, коллык психологиясенә каршы көрәшкән төп өлеше — сәламәт.

***А.Ю.*** *Татарстан китап нәшриятында «Сайланма поэмалар»ыгыз чыгып килә. Шул уңай белән нинди уйлар туды?*

**И.Ю.** Поэмаларымны тагын бер кат карап чыктым. Элек төшеп калганнарын яки цензор булып үзем сызганнарны өстәдем, бүгенге таләп белән редакцияләдем.

Сөендергәне шул — күпчелек поэмаларым бүген дә яңгырый ала. Искергәннәре дә бар. Сәясәткә артык табынырга ярамый икән...

***А.Ю.*** *Шагыйрь буларак, Сез бәхетлеме?*

**И.Ю.** Бәхетле шагыйрь була микән? Аны бәхетле иткән илаһи минутлар, илһамлы көннәр, айлар бардыр... Юктыр, шагыйрь үз милләтеннән аерым бәхетле була алмый. Халкың бәхетсез булганда бигрәк тә... Гомумән, шигъри җанлы кешеләргә шәфкатьсез бу тормышта яшәү җиңел түгел...

***А.Ю.*** *Барысы да, кыюланып, туган тел турында язганда, сез тынып калдыгыз түгелме?*

**И.Ю.** Милләтнең хәле, туган тел турындагы уйларымны торгынлык дип аталган чорда төрле формаларда «Соңгы сынау», «Очты дөнья читлегеннән» трагедияләремдә әйтергә тырыштым. Яшьләргә безнең буын язучылары артык юаш, куркак булып тоеладыр. Безнең чорны аңлау өчен шул елларда яшәү кирәк. Без һәммәбез замана балалары. Рөхсәт ителгән кыюлыкны хәзер кайберәүләр батырлыкка саныйлар.

***А.Ю.*** *Шигъри трагедияләр язу һәм композиторлар белән иҗади дуслык Сезне сәнгатьнең катлаулы жанрына — операга алып килде. Рәшит Кәлимуллин белән Сез «Ерактагы кәккүк авазы»н яздыгыз. Татар операсы турында Сезнең фикерегез?*

**И.Ю.** «Татар операсы кризиста, ярдәм итәргә кирәк!» дип кычкыручылар бездә буа буарлык. Әмма шул жанрда эшләүчеләргә игътибар юк дәрәҗәсендә. Либретто язып караган авторга кабат ул өлкәгә килмәслек мөнәсәбәтне мин үзем сиздем. Әмма язуыма үкенмим, иҗат газапларында туган хезмәтне аңлаучы тамашачылар барлыгын тою өмет уятты.

***А.Ю.*** *Яшь өлкәнәеп, тәҗрибә арткан саен, язу җиңеләядер...*

**И.Ю.** Кемгә ничектер, миңа тагын да авырая. Бигрәк тә драматик әсәр язарга алынганда, мин үземне беренче тапкыр каләм тоткан яшь автор итеп тоям.

*2000*

# ЙӨРӘККӘ ЯЗЫЛГАН ИСЕМНӘР

## *Җыелы кулында — тургай чәчәге*

Безнең буынның әдәбиятка килеп керүе Хәсән Туфанның Казанга әйләнеп кайту чорына туры килде.

1956— 1960 еллар. Мин ул вакытта «Пионер» («Ялкын») журналында җаваплы секретарь. Олы шагыйрь Хәсән Туфан белән аралашулар — үзе бер кадерле хатирә. Шигырь сорап күп тапкырлар аның үзе янына барырга туры килде, үзен дә редакциягә чакыра идек. Ул беркайчан да шигырен матбугатка үзе тәкъдим итми. Хәсән аганың үз кулы белән язылган берничә шигыре әле дә минем архивымда саклана.

Бервакыт без, редакциядә киңәшеп, шагыйрьнең элек билгеле булган «Юкмыш бабай әкияте»н яңадан басып чыгарырга уйладык. Бу теләгебезне авторга да белдердек. Хәсән ага поэмасын ашыкмыйча гына яңадан төзәтте һәм безгә яңа вариант алып килде. Әкият, Лотфулла Фәттаховның матур рәсемнәре белән бизәлеп, басылып та чыкты. Архивымдагы иң кыйммәтле ядкәрләремнең берсе — «Юкмыш бабай»ның автор тарафыннан төзәтелгән варианты. Күп тапкырлар Хәсән ага белән бергә очрашуларда булганым бар. Аудиториядә берничә генә бала күрсә дә ул, һич тә авырсынмыйча, «Юкмыш бабай»ны яттан сөйли. Бер генә артист та ул әсәрне сөйләргә алынмады. Бәлки, Туфанның үзеннән соң сөйләргә кыюлыклары җитмәгәндер.

Олы шагыйрь поэзиягә килгән яшь шагыйрьләрне шунда ук үз күрде, якын итте. Туфан, Хәким кебек шагыйрьләрнең җылы карашын тоеп яшәвем белән мин үземне бәхетле саныйм. 1958 елда чыккан «Җырлар, шигырьләр» китабына Хәсән ага миңа шундый юлларны язды:

«Мин бәхетле, Илдар, авам икән — сез бар, дәвам итә алучы алмашлар бар. Такташ кына бу матур көннәрне күрә алмады. Аның өчен дә кулыңны кысам. Х.Туфан. 19.04.58».

1964 елны басылган «Сайланма әсәрләр»ендә исә яшел кара белән шундый автограф куелган:

«Иң яраткан әдәби энем Илдарга, бер үк сафта яшәгән көннәребез истәлеге итеп, чын күңелдән Х.Туфан. 12.2.65».

Мактану булып яңгырамасын өчен әйтеп куюны кирәк табам: аның «иң яраткан әдәби энеләре» миннән башка да шактый бар иде һәм ул мондый җылы сүзләрне, әлбәттә, бер миңа гына язмагандыр.

Ул елларда матбугатта минем поэмаларым турында шау-шулы бәхәсләр купкалады. 1968 елның 28 октябрь санында «Комсомолец Татарии» газетасында Хәсән Туфанның «Поэт переднего края» исемле мәкаләсе, Сибгат Хәкимнең шул ук елны «Татарстан яшьләре»ндә язмасы чыккач, минем иҗатыма мөнәсәбәт ачыкланды шикелле.

Хәсән абыйлары моны гел башыннан сыйпап кына торган икән, дигән фикер калмасын. Кирәк чагында, үзенә ошамаган шигырь яки поэманы укыгач, Хәсән абый аталарча «кыйный» да белә иде. «Карурман» поэмасының беренче вариантын ул ошатмады. Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыганда тәнкыйть фикерләре белән хат салды. Шуннан мин поэманы яңадан төзәттем һәм шуннан соң гына «Казан утлары»на бирдем. Поэманың Хәсән ага тамгалары куелган нөсхәсе әле дә саклана. Кыскасы, «Карурман»ның кайбер урыннарында Хәсән абыйның да җылы кулы бар.

Шул еллардагы поэзия секциясенең җитәкчесе буларак, Хәсән ага белән еш очрашырга туры килә иде. Ул үзенең бюро әгъзасы дигән вазифасына бик тә җаваплы карый, һәрбер утырышта катнашып, үз фикерен әйтмичә калмый. Кулъязманы кат-кат укып, фикерләрен кулъязмага язып куя, шигырьләр ошаса, ул авторны югалтмый, аның белән даими очраша.

Хәсән аганы мәҗлесләрдә утырганда күзәткәнем бар. Ашау-эчү белән мавыкмый. «Гомумән, ашый иде микән ул?» дип тә уйлап куям хәзер. Үзенә сүз бирмәсәң, гел тыңлап утыра, кеше сөйләгәнне ярата. Башкалар сизмәгәндә генә, өстәлдән салфетка алып, нидер яза. Ә инде сүз әйтүен үтенсәләр, гадәттә, шигырь укый.

Тагын бер сәер гадәтен әйтмичә булмый: Хәсән ага үз кулы белән беркайчан да шигыре өчен гонорар алмады, шул гадәте белән редакцияләрне, бухгалтерияләрне тәмам тилмертә иде.

Атналыкларда, җыелышларда, очрашуларда, кунак йортларында күпме тапкырлар бергә булып, мин аның үзе турында башлап үзе сөйләгәнен хәтерләмим. Сөйләгәне — шигырь, табигать, сәнгать... Аның белән матди әйберләр турында түгел, гел иҗат хакында гына сөйләшәсең.

Соңгы елларда, инде авырый башлагач, телефоннан шалтыратам: «Хәлегез ничек, Хәсән абый?» Һәрвакыт: «Нормально!» яки «Шәп!» — дип җавап бирә. Берсендә: «Аккош күленә кошлар килгәндер инде, каршыларга барасы иде»,— ди. Чын мәгънәсендә табигать баласы.

1980 елның декабрендә Хәсән абый безне, берничә әдәби энесен, үз өенә — сиксән еллык бәйрәменә чакырды. Кичә генә өлкән дуслары котлап киткәннәр. Шагыйребез, гадәттәгечә, күп сөйләмәде, күбрәк безне тыңлады. Әмма без аның: «Таркалмагыз, бердәм булыгыз!» — дип әйткән сүзләрен васыять дип кабул иттек һәм Кол Галидән алып бүгенге көнгә кадәр килгән буыннар чылбырын өзмичә сакларга, дәвам итәргә күңелдән сүз бирдек. Бу кадерле васыятьнең мәгънәсен һәрберебез үзенчә ачты, әмма аның төп асылы ачык иде: һәртөрле ваклыклардан өстен булыгыз, талантыгызны әрәм-шәрәм итмәгез, илебезнең олы җанлы гражданины булып, Тукайча, халык өчен яшәгез!

Вафат булырына берникадәр вакыт калгач, без аның янына хастаханәгә кердек. Үзе дөньядан инде китеп бара, ә үзе: «Хәлең ничек?» — дигәч, елмаерга тырышып: «Шәп!» — ди. Беренче керүебездә: «Мин сездән разый, егетләр!» — дип калды. Без, аның әдәби энеләре, искиткеч зур миссия (Хәсән абый ясаткан сүз) күтәреп барырга тиешбез: андый Шагыйрьнең фатыйхасын алу һәм васыятен үтәү — җиңел түгел!

Соңгы тапкыр хастаханәгә үзем генә кердем. Миңа Янган тауга санаторийга китәргә кирәк иде. Янында — Мөнҗия апа. «Йөреп караган иде, егылды»,— ди. Шуннан соң гел ятып тора икән.

— Хәлегез ничек, Хәсән абый?

— Нормально!

Мөнҗия апа өстәп куя.

— Аккош күленә ашкына...

Сизәм, Хәсән абыйга сөйләшү авыр, әмма сүзләрен әйтергә ашыга:

— Һәр елны Аккош күлендә бер чәчәккә игътибар итәм, әмма аның исеме юк. Ул чәчәк ел саен тургай килгәч ачыла. Нindидер серлелек бар монда...

— «Тургай чәчәге» дигән әзер шигырь бу, Хәсән абый, утырып язасы гына бар...

Соңгы очрашуны тойган кебек, ул бу юлы да:

— Мин сездән разый,— дип калды.

Изге Шагыйребезнең васыятьләре хәзер тынгылык бирми, төннәрен йокыдан уята.

Чын Шагыйрьнең беркайчан да картаймаганлыгын раслап киткән бөек Туфан, кулларына Тургай чәчәген тотып, ап-ак чәчләрен җилфердәтеп, Аккош күленнән килеп чыгар сыман...

*1982*

## Тулбай ае хәтерләтә аны

Минем уйны, хисне, омтылышны
Аңлар диеп уйлыйм күбегез,
Үлгәч мине туган авылыма —
Тулбаема илтеп күмегез.
Авылдашлар сезгә ярдәм итәр:
Әнкәм яткан җирне табыгыз.
Өсләремә йомшак юрган итеп,
Туган туфрагымны ябыгыз.
Өлкәнәйгән саен чишмәләрнең
Челтерәүләре үзенә тарттылар.
Актык сулышымда юллар мине
Тагын сиңа алып кайттылар.
Гәүдәм калсын туган җиркәемдә:
Казан аңлар диеп беләм мин.
Бөтенләйгә, китмәскә дип кайттым,
Авылдашлар, сезнең белән мин.

Бу — Шәйхи ага Маннур васыятенең минем күңелемдә туган шигъри чагылышы.

1971 елның августында ул мине, Язучылар союзы коридорында туктатты да: «Менә шуны ал әле»,— дип, кулга бер конверт тоттырды. Үзе, берни дә аңлатмыйча, китеп тә барды. Конвертның тышына: «Соңгы сәгать суккач укырсың...» дип язылган иде. Мин моның васыять икәнен аңладым. Шәйхи аганың хаста-

ханәдә вафат булуын ишеткәч, ачып укыдым. Бу — 1980 елның 10 июне иде. Васыятендә әйткәнчә, аны туган авылына — Мамадыш районының Тулбай авылына илтеп җирләдек. Авылдашы, дусты, «Чулпан» колхозы рәисе Галимҗан ага Җиһаншин (быел ул да вафат булды) васыятьтә әйтелгән урынны әзерләп куйган иде инде.

1980 елны Язучылар союзы идарәсе утырышында Ш.Маннурның мирас комиссиясе төзелде. Аңа Гомәр Бәширов, Хисам Камалов, Шәүкәт Галиев, Хәмит Ярми, Рәис Даутов, Лирон Хәмидуллиннар кертелде. Рәислек вазифасын миңа тапшырдылар. Соңыннан, секретарь буларак, Шаһинур Мостафин өстәлеп, ул эшебезне тагын да активлаштырып җибәрде.

Шәйхи аганың, васыятендә язылмаса да, үзе исән чакта телдән әйткән тагын бер изге теләген үтәдек. «Чулпан» колхозы, Олыяз авыл советы һәм Татарстан язучылар союзы идарәсе балалар әдәбияты буенча елның иң яхшы әсәренә, яшь авторның теләсә кайсы жанрдагы күренекле әсәренә Шәйхи Маннур исемендәге бүләк бирү турында карар чыгардылар. Шулай ук бу бүләкне ел дәвамында иң югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән колхозчыларга да тапшыру кирәк дип табылды. Жюри члennары итеп язучылар ягыннан Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев, Рашат Низамиев билгеләнде. Бу бүләкләрне һәр елны шагыйрьнең туган көнендә — 15 гыйнварда тапшыру инде матур бер традициягә әйләнде. Бу көнне без һәр елны остазыбызның туган төбәгенә барабыз һәм искә алу кичәсе үткәрәбез. Шул кичәләрдә Шәйхи Маннур премиясе дипломын алган язучыларыбызның исемнәрен атыйбыз:

**1982 ел.** Шагыйрь Зөлфәт һәм язучы Ринат Мөхәммәдиев.

**1983 ел.** Шагыйрь-рәссам Гакыйль Сәгыйров һәм прозаик Марсель Галиев.

**1985 ел.** Прозаик Нәбирә Гыйматдинова һәм тәнкыйтьче Мөдәррис Вәлиев.

**1991 ел.** Шагыйрь Рафаил Газизов һәм прозаик Зиннур Хөснияр.

**1992 ел.** Шагыйрь Газинур Моратов, прозаик Рашат Низамиев һәм Ш.Маннур әсәрләрен русчага тәрҗемә итүче Светлана Гыйльметдинова.

**1993 ел.** Прозаик Нәзифә Кәримова, шагыйрьләр Рафис Корбан һәм Рөстәм Сүлти.

**1994 ел.** Шагыйрьләр Ләбиб Лерон һәм Рәниф Шәрипов, балалар язучысы Вәкил Ахунҗанов...

**1982—1994** елларда әлеге бүләккә шулай ук утыз колхозчы лаек булды.

Алар арасында авылдашының васыятьләрен тормышка ашыруда күп көч куйган искиткеч олы җанлы кеше — «Чулпан» колхозы рәисе Галимҗан ага Җиһаншин, Тулбай авылы китапханәсе мөдире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Васыйга Зәйнетдинова, Мамадыш районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары Револь Гыйззәтуллин да бар. Баштарак бу бүләк шагыйрьнең үзе васыять иткән мирасыннан түләнде, соңрак бу эшкә колхоз үзе алынды, аның да көче җитмәгәндә спонсорлар ярдәм итте.

Кабере өстендә чардуганы бар. Шигыре ташка язылган. Үз акчасына салынган Тулбай китапханәсе киңәйтелде һәм яңартылды. Хәзер аңа дәүләт музее статусы бирелә. Шәйхи Маннурның музей-китапханәсендә ике кешелек штат каралган.

Васыятьтә әйтелгән теләкләрнең күбесе үтәлде. Кызганычка каршы, безгә бәйләнмәгән сәбәпләр аркасында, Ш.Маннурның томнарын басып чыгару мөмкинлеге юк. Туксан еллык юбилеен әнә шулай буш кул белән каршыларга мәҗбүрбез инде. Алла бирсә дип, йөз еллыгына өмет багларга кала.

Иҗатта да, тормышында да кыю кеше иде. Шул елларны җәлилчеләр эзеннән Көнбатыш Германиягә баруы, Шпандау төрмәләреннән яңа мәгълүматлар алып кайтып, «Муса» романын язуы — батырлык түгелмени?

Үзенчәлекле прозасына да, балалар әдәбиятындагы эшчәнлегенә дә тиешенчә бәя һаман да бирелмәгән. Фәннең, тәнкыйтьнең әллә кулы, әллә көче җитми...

Шәйхи абый кебек кабатланмас олы шәхесләр үзләре белән безгә менә бүген кирәк булган асыл сыйфатларын да алып киттеләр. Дөрес, күпләр аны «бик усал иде» дип искә алалар. Җыелышларда утырганда, әсәрләр тикшергәндә, мин нәкъ шул сыйфатын сагынам. Сикереп торыр иде дә, йөзеңә карап, туп-турысын әйтер дә бирер иде. Иске Академия театрында балалар әдәбиятының торышы тикшерелә. Докладчы — өлкә комитетының

идеология секретаре бик кызып кына сөйләгәндә, Шәйхи Маннур сикереп торды да: «Дөрес сөйләмисең!» — дип кычкырып, сигаретлы мөштеген авызына кабып, залны ташлап ук чыгып китте. Секретаребыз каушап калды, докладын чак-чак кына очлап чыкты.

Дөрес, миңа да бәйләнгәләде остазым. Цхалтубада ял иткәндә үзенә кунакка чакырып кертте. Һәм: «Нигә син ипине болай түгеп-чәчеп ашыйсың?» — дип, ачуланып алды. Ә иҗатка килгәндә, ул әллә ничә тапкыр урынсыз бәйләнүчеләрдән йолып алды. Минем «Фәрит-Фәридә» поэмасына ябырылганнар иде, Шәйхи ага яклады. Әнә шундый берничә яклаучың булмаганда, яшь авторга үсү бик авыр булыр иде.

Иң яратмаганы — үзе эшләгән редакциядә үзенең җитлекмәгән озын язмаларын бастырып утыручы кәсепчеләр иде. Башкалар әйтергә уңайсызланалар, куркалар, ә Шәйхи ага, олы трибунага чыгып, кәсепченең тетмәсен тетә. Берсен шулай, комиссия төзетеп, тикшертеп, эштән үк алып ташлатты. Сәләтле яшьләрне шунда ук күреп ала, аларга гел ярдәм итеп тора, уңышсыз әсәр чыгарса, бер генә сүз әйтә: «Халтура!»

Сагынырлык остазлар иде алар! Үземне аның васыяте алдында бурычлы санап, һәр елны Тулбайга барам...

Тагын килдем әле, Шәйхи абый,
Туган Тулбаеңа.
Төнен озак-озак карап тордым
Күккә, тын Аена.
Күңел тулгангадыр, Тулбай ае
Хәтерләтә сине...
Синең йөзең дә бит үзе кырыс,
Үзе тулы иде.
«Ул да миңа карый иде» диеп,
Әйткән кебек ул Ай...
Без дә бер китәрбез бу дөньядан,
Шәйхи абый, шулай.
Мәңге-мәңге күктә тын Ай йөзәр,
Агымсулар агар...
Безне сагынып һәм юксынып кемнәр
Тулган Айга карар?..

*1994*

# Ике җырчы арасында барам...

Ярсу океан суларын тарсынып үз-үзләрен коры ярга ташлап һәлак иткән китлар турында ишеткәнем бар. Бу серле фаҗигале үлемнең сәбәпләрен әлегә кадәр беркем дә ачалмаган.

Бөек җырчыбыз Хәйдәрнең көтмәгәндә дөньядан китүен аңа җитәрлек игътибар булмау белән генә аңлаталар. Ай-һай, шулай гына микән?

Ерак урманнан тар кысан бүлмәгә кереп, иркен һавага кире очып чыгалмыйча бәргәләнеп һәлак булган кошны күргәнем бар. Сандугач дигән асыл кошның үлү сәбәпләрен без, адәмнәр, аңлый алмабыз. Бәлки, парын югалткангадыр?..

Сандугачлар кунып кайда сайрый? —
Сарман буйларында тирәктә...

Табигать сандугачларны өләшкәндә, юмартлыгын кызганмыйча, Сарман якларына күбрәк бүлеп биргән. Югыйсә урманнарга да бик бай түгел инде ул яклар. Илһам яки Зөһрәләр үз якларының матурлыгы турында сандугачтай талпынып-өзелеп сайраганда, дөньяда Сарманнан да гүзәл җир юктыр кебек.

Сандугачлар кунып кайда сайрый?
.............................................
Нижгәр якларында тирәктә,—

дип җырлыйсы килә.

Асыл кошларын бүлгәндә, табигать Нижгәр якларын да сайлаган. Шул тарафтан очып чыккан Рәшит Ваһаповны тыңлагач, сандугачларның оясын күрү теләге туа. Шул ук оядан Хәйдәр Бигичев та күтәрелде.

Асыл кошлар бер-берсен ничек эзләп табалар һәм кавышалар икән? Бу да — табигатьнең бөек сере.

Кавышулары, иркәм, бик күңелле,
Әмма аерылулар бик яман.

Җырдагы үзәк өзгеч шушы бер җөмләгә үзләрен тудырган табигатькә гашыйк ике асыл затның бөтен тормышы-язмышы сыя.

Табигать аларга бер-берсен эзләп табарга ярдәм иткән.

Аларның бергә кавышып, пар сандугачтай бергә сайрауларын сөенеп-рәхәтләнеп тыңлый идек бит.

Күзләреңне тутырып карарсыңмы
Зәңгәр таудан яулык болгармын...

Бу юлларны өзелеп-өзелеп җырлаганда нидер тойган Зөһрә:

Бергә булулары бик күңелле,
Әмма аерылулар бик яман.

Пар сандугачның бәхетле сайрап яшәү мизгелләрен үз күзләрем белән күрдем, йөрәгем белән тойдым.

1994 елның 13 мартында без өчәү «Казан — Уфа» поездында идек. Уфадагы дуслар минем иҗат кичәсен үткәрергә уйлагач, Хәйдәр белән Зөһрәне чакырдым. Уфа тамашачыларының пар сандугачка күптән инде гашыйк икәннәрен беләидем. Тәүлек ярым бергә бару хәзер инде матур бер төш кебек... Бер-берсенә матур мөгамәләләрен күргәч, мин дөньяда болардан да бәхетлерәк затлар юктыр дип уйладым.

Алар ял иткән арада, күңелдә үзеннән-үзе шигырь юллары туды, йөрәктәге илаһи бер халәт — пар сандугач тудырган илһам булгандыр...

## Уфага барганда

*Зөһрә һәм Хәйдәргә*

Без утырган поезд алпан-тилпән,
Шыгыр-шыгыр килә арбадай.
Ике җырчы арасында барам,
Көй белмәгән ала каргадай.
Икесенең тормышлары көйле,
Алар асыл ике сандугач:
Берсен берсе эзләп табышканнар,
Дөньялары бөтен — пар булгач.
Тирә-якны сихри моңга салып,
Алар сайрап-җырлап баралар,
Авызларын ачып озатып кала
Минем кебек көйсез каргалар.
Юк, көнләшмим, юк, күпсенмим сездән,
Сайраулардан мәхрүм тусам да,
Шундый сандугачлар бар чагында,
Мин ризамын карга булсам да...

Уфа тамашачысы аларны чәчәккә, алкышка күмде. Моңа кадәр дә алар концерт белән берничә тапкыр килгәннәр һәм яраткан сандугачларга әйләнгәннәр иде инде. Үзләренең әйтүләренә караганда, шулкадәр чакыру-

га чак-чак кына Уфага күчми калганнар. Хәтта бервакыт Зөһрә Башкорт опера театрының штатында да торган. Халкының мәхәббәтен тойган Хәйдәр, Сара апаның минем шигырьгә язган җырны башкарганда, сандугачтан бөркеткә әйләнә.

Очты бөркет,
Төште бөркет,
Йөрәгендә — ярасы.
Яшь аралаш елмая ул,—
Югарыда — баласы...

Соңыннан, йөрәгендәге ярасыннан һәлак булгач, аны кыядан ташланган бөркеткә тиңләрләр. Ә хәзер безне Башкорт дәүләт опера һәм балет театры директоры, мәшһүр җырчы Радик Гәрәев озата. Ул безне зурлап, кичәне затлы опера театры бинасында үткәрү чарасын күргән иде, бүген Казанга кадәр үк кайтырга үзенең машинасын бирде. Яңавылдан күтәрелеп бөтен дөньяга танылган якташым Радикны беренче һәм соңгы тапкыр күрүем икән: аның да елмаюлары яшь аралаш булган ул да, яралы бөркет сыман, һәлакәте алдында торган.

Башкортстан каеннары пар сандугачларны, туганнары кебек якын күреп, башларын иеп озата баралар.

Туган ягым каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде.
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Сагышларга салалар инде...

Бергә яшәүләренең күңеллелеген берничә тәүлек кичергән кеше — мин — аларның мәңгегә аерылу мизгелләрен дә күрермен дип, хыялыма да китермәгән идем. Алар телевизор экранында Разил Вәлиев белән әңгәмә корып утырдылар.

Иң ахырдан пар сандугачлар — Хәйдәр белән Зөһрә, бер-берсенә карашып, бергәләп җырладылар:

Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына...

Асыл яр, кошкаем,
Аерылабыз, дускаем...

Хәйдәрнең соңгы тапкыр бәхилләшү җыры булган икән.

Хәзер ул миңа, гәүдәсе арабызда булмагач, тургайга әйләнгәндер һәм кырлар өстендә югарыда сайрыйдыр

кебек тоела. Сайраучы кош үзе күренми бит... Минем шигыремә Сәлимә Шәмсина язган көйне юкка гына күңеленә якын итмәгәндер Хәйдәр.

Тургайларда — кырлар моңы,
Мин алдым шулар моңын...

Гәүдәсе мәңгелеккә китеп югалган Хәйдәрнең һәм асыл ярын югалткан Зөһрәнең җырларын тыңлаганда, күзләремне йомам. Мин һаман да ике җырчы арасында ерак юлга — серле Гүзәллек дөньясына китеп барам сыман...

*1999*

## Ага сулар Болгарга...

И татарларның кәгъбәсе,
Мәккәсе — шәһре Болгар!
Мин генәме, сәҗдә кылып,
Карашын сиңа борган...

Башкортстанда яшәүче татарларның рухи багланышын ныгыту өчен, Уфада оештырылган «Рамазан» җәмгыяте ун ел инде әби-бабаларыбызның изге җиренә — Болгарга сәяхәткә алып китә. Башка елларны без аларны Казанда каршылап, әдәби очрашулар үткәреп, озатып кала идек. Җәмгыятьнең президенты — Башкорт дәүләт опера һәм балет театры солисты, филология фәннәре кандидаты, Башкорт дәүләт университеты доценты, вокалистларның Салих Сәйдәшев исемендәге конкурсында Гран-прига ия булган Марат Шәрипов бу юлы мине дә сәфәргә чакырды. Казан — Уфа автобусында барганда көпчәк шартлап, өч сәгатькә соңга калсак та, хатыным Тәфтилә белән икебезне Марат үзе һәм аның коллегасы — филология фәннәре кандидаты доцент Рәүф Идрисов каршы алдылар.

Утыз градуслы эсседә ерак юлдан килүебезне ишеткәч, Уфадагы бер танышым «Илдар башсыз малай икән» дигән. Башсызлыгым аркасында гомеремдә шактый гына ялгышлыклар эшләсәм дә, бу юлы мин башсыз булуыма һич тә үкенмәдем.

Германия күгендә Башкортстан балаларының һәлакәте Уфаны да, барыбызны да хәсрәткә салган авыр көннәр. Әмма тормыш агуында дәвам итә.

«Зайцев» теплоходында без милләтебезнең узганы — Болгарга агабыз. Тормыш агымында барганда мәңгелек тукталышта төшеп калган дусларыбызны, кадерле кешеләребезне юксынып искә алабыз. Уфага барган саен дустым Әнгам Атнабаев каршылый иде, өенә бардык — ул юк. Кайчандыр шигырь укышып бергәләп утырган өстәле янында сүзсез басып тордым.

Изге сәфәр корабына кайчандыр аяк баскан Әмирхан Еники, Нажар Нәҗми, Нил Юзиев, Ил Саттарлар да инде юк.

Моннан ун ел элек «Рамазан» җәмгыяте Башкорт дәүләт опера һәм балет театры бинасында минем иҗатка багышлап, әдәби-музыкаль кичә үткәргән иде. Без Уфага Башкортстанның якын дуслары Хәйдәр Бигичев һәм Зөһрә Сәхабиева белән килдек. Тамашачыларның җырчыларга чын мәхәббәтен белдергән алкышлар әле һаман йөрәктә. Безне үз итеп затлы сәхнә түренә мендергән халык җырчысы, театрның хуҗасы Радик Гәрәев тә, үзәкләрне өзеп җырлаган Хәйдәребез дә, кичәнең режиссеры күренекле артист Шамил Рәхмәтуллин да инде бу дөньядан китеп бардылар. Теплоходтагы иң беренче очрашуны без мәрхүмнәрне бер минут тын торып искә алудан башладык.

Әмма Агыйдел сулары да, тормыш та агуында дәвам итә.

Безнең белән — татарның да, башкортның да җан сандугачы, картаюның ни икәнен белмәс, армас-талмас Фәридә ханым Кудашева. Агыйдел буйлап узганда аны кошлар да сайравыннан туктап тыңлыйлар сыман. «Ел саен чыгам, мине шушы сәфәр дәвалый, яшәртә» ди Фәридә апабыз.

Безгә ерак булганлыктан, балачакта без Агыйдел турында халык җырларыннан, Фәридә апаның соклангыч тавышыннан ишетә идек. Дәү әни: «Фәридәне без намазны бүлеп тыңлыйбыз»,— ди торган иде. Хәзер без легендар җырчының үзе белән Агыйделдә агып барабыз.

Су өстендә узган минем иҗат кичәсендә Данис Фатыйхов, Әлфия Юлчурина, Венера һәм Марат Шәриповларның минем шигырьләргә язылган җырларын тыңлагач, Фәридә апа болай диде: «Бу җырларның берничәсе заманында минем репертуарда да бар иде. Бигрәк тә күңелемә «Яшь наратлар» җыры бик якын. Сугыш-

ка кадәр үк инде мин аны Җәүдәт Фәйзи көенә, Фатих Кәрим шигыре белән җырлаган идем. Шигырьнең авторын 1937 елларда гаепләп, төрмәгә утырткач, цензура «Яшь наратлар»ны тыйды. Таныш ул җыр 60 нчы елларда Илһам Шакиров башкаруында янә яңгырый башлады. Әмма сүзләре икенче иде. Көйне югалтасы килмичә, халыкта аның башка варианты туган. Әмма җыр сүзләре Илһамны канәгатьләндермәгән һәм ул Илдардан көйгә яңа шигырь язуын үтенгән. Җыр халыкта яңадан туа. Илһам һәм шигырьнең авторы, җырын терелтеп, Фатих Кәримнең истәлегенә һәйкәл куйганнар».

Үз күзләремә үзем ышанмыйм, карасам, алдымда Вахит Юныс басып тора. Ике инсульт, авыр операция кичергәннән соң инде өмет өзгән булганнар, хатыны — медицина фәннәре кандидаты Алия ханым Мәскәүдәге үз өйләрендә үзе дәвалап, могҗиза ясап, аякка бастырган. Алгарак китеп булса да әйтим: корабтагы рухи мохит аңа көч бирде, ул күзгә күренеп, терелүен дәвам итте. Аның тагын бер шатлыгы бар икән: Татарстан китап нәшриятында яңа гына «Алты мең көн чит илләрдә» дигән китабы нәшер ителгән. Ә корабта үткән җиде көне, җиде төне Вахит өчен берни белән чагыштырмаслык могҗизадыр.

Күптән түгел Рамил Чурагулны Казанда Татарстан язучылар берлегенә тәкъдим иткән идек. Ул безне гаиләсе белән таныштыра. «Бу сәфәргә ун ел тоташ чыгабыз, балаларым чын мәгънәсендә шушында үстеләр» ди ул. Аккан суларга карап сүзсез баручы, мәһабәт алып гәүдәле әфәндегә игътибар итәм: премьер-министрның элекке урынбасары, республика парламенты депутаты М.М.Усманов ул. Шундый уйчан-җитди кешенең баруы — сәяхәткә рәсми-җитди төс бирә.

Танышу кичәсендә өздереп биегән ханым — Салават каласыннан Сәвия Закирова икән. Бер предприятиенең бухгалтеры буларак аны эшеннән бу сәфәргә җибәрмәскә, ял бирмәскә тырышканнар, «Миңа сәяхәткә бару кадерлерәк, эшемнән китәм алайса» дип әйтү белән, эшендә дә калдырганнар, җибәргәннәр дә. Көнен дә, төнен дә авыл урамындагы кебек тальян уйнап йөрүче Фаиз Хафизовның бармаклары саен халык көйләренә мәхәббәт. Ул баянга кушылып уйнаганда, Сәгыйдулла абзый кың-

гырау чылтыратып тора — Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ы искә төшә. Күңел үзеннән-үзе җырга тартыла, үземнең дә әллә нинди шигырьләр язасы килә. Ә шигырь яратучы кызлар, егетләр — Марат һәм Рәүфнең шәкертләре — студентлары ялындырып тормыйлар, шигырьне күңелдән сөйлиләр. Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрьләргә багышланган кичәдә күп шигырьләрне алар сөйләгәннәр. Минем иҗат кичәсендә дә алар теләп катнаштылар.

Дүртөйле районындагы Сергеевка тукталышында сәяхәтчеләр өчен үткәрелгән сабантуйда шигырь сөйләү, җырлау, бию, аркан тарту, йөгерү ярышлары Агыйдел буйларын шаулатты. Анда үзе дә шигырьләр язучы, инде үз китабын чыгарырга өлгергән нефтьче Фәнис Рәхмәтуллин да катнашып, бүләк алды. Маратның хатыны, аның барлык эшләрендә ярдәмче мөлаем Венера Шәрипова йөгерешчеләрдән дә тизрәк йөгереп, җиңүчеләргә бүләкләр өләшеп йөрде: алда, артта килгән бәләкәч балаларга да, тыныч ялга чыгып монда чын-чынлап тынычланган өлкәннәргә дә... Венера ханымның җырлаганын ишетсәгез, сез үзебезнең мәшһүр Венера Шәрипованы искә төшерер идегез.

Сабантуйда йөгереп бүләк алган бер баладан: «Син кем малае?» — дип сорагач, «Бабич малае!» дип җавап бирде. Алар Уфаның Бабич урамында торалар икән. Ә «Бабич балалары» өчен «Шәрекъ» радиосы журналисты Венера Идрисова бер атналык «Рамазан» мәдрәсәсе ачкан. Сәфәр кылучы дин әһелләре, укытучылар, артистлар, галимнәр, язучылар, тегү осталары корабның салонында аларга дәрес бирәләр икән.

Корабта йөзүчеләр өчен «игелекле бала» дигән конкурс игълан ителгән. Путевка сатып алып әти-әниләрен сәяхәткә җибәргән берничә балага Марат алар аркылы бүләкләр озатты.

«Шәрекъ» радиосы хезмәткәрләре Венера һәм Рәүф Идрисовлар сәфәрнең башыннан ахырына кадәр саф татар телендә сөйлиләр, сөйләтәләр, җырлаталар, пристаньнарга килеп кергәндә һәм кузгалып киткәндә Тукай һәм Сәйдәш маршларын яңгыраталар. Ә Салават белән Роберт Миңнуллинның «Башкортстан татарлары» җыры — сәяхәтнең визит карточкасы. Уфадагы гастрольләре вакытында, бу җырны башкарып, Салават бөтен

Уфаны тетрәткән. Бу җыр, үзләре әйтүенчә, Башкортстан татарларының гимнына әйләнгән. Халык санын алу алдыннан бу җыр үзенең эшен бик шәп башкара. Радио үзенең бер көнен тулысынча Салаватка багышлады. Болгарда безне Салават үзе каршы алды, сәяхәтчеләр белән иҗади очрашу үткәрде, бик кызыклы сорауларга җавап бирде. Марат Шәрипов һәм Салават кебек шәхесләрне мин рухи алып дип кабул итәм. Апа-әбиләр Салаватның җиде кат әйләнә-әйләнә автоярышларда узышуын яратмыйлар икән. Нишләтәсең инде аны, Салаватның шашкын табигате җырлап кына тынычлана алмый. Шуның өстенә ул, Казанның мең еллыгына багышлап, түбәтәй әзерләү предприятиесе ачкан. Ул гына да җитмәгән, Казан сәнгать академиясендә эстрада артистлары әзерләүне үз өстенә алган. Була да соң дөньяда талантлы һәм булдыклы җаннар! Болгар тыюлыгының музей хезмәткәре Хәсән әфәнде әби-бабаларыбызның нинди уңган кешеләр булганлыгын сөйләгәндә, мин үзебезнең Салаватыбыз белән горурлану хисләре кичердем.

Шул ук Хәсән әфәнде шәһре Болгарда башка милләт, дин кешеләренең дә үзара тату яшәүләрен әйтте. «Рамазан»чыларның да ниятләре болгар бабалары кебек, алар урыслар белән дә, башкортлар белән дә туганнарча яшәү юнәлешендә эшлиләр. Шунлыктан палубада төрле милләт телләрендә сөйләшүне ишетү бик табигый.

Болгар хәрабәләрен карап йөргәндә, сәяхәтчеләр бабаларыбызның мәшһүр мунчасын да хәйран калып тамаша кылдылар. Андагы кебек үк булмаса да, корабның үз мунчасы, душы бар. Ул гына җитмәсә, рәхим ит, тукталышларда суга чум, Фәридә ханым сыман Агыйделнең алкын һәм салкын суында колач салып йөз, бу юлларның авторы сыман, Чулманның Иделгә кушылган урынында эшли башлаган башыңны суга тыгып ал, Болгарның изге суларында тәнеңне чистарт.

Әмма бу сәяхәтнең иң зур байлыгы — җан мунчасы, күңелне сафландыру. Бу хисне әби-бабаларыбыз җиренә аяк баскач бигрәк тә нык тоясың. Кече һәм олы манараларны, хан төрбәсен, ак палаталарны караганда да, сәҗдә кылып борынгы җиргә тезләнгәндә дә, хәзрәтнең догавәгазьләрен тыңлаганда да, күңелең гамь белән тула, «без әле ничек яшибез?» дигән уй борчуга сала.

Ташлар гүя тәкбир әйтә,
Тыңлап торам тын калып:
«Бармы Җирдә безнең нәсел?
Онытмагыз: без — Алып!»
Мин дә кушылам бу моңга.
Сискәнеп, уйга талып...
Без — Тукайлы, Җәлилле дә,
Тик хәзер нинди халык?

Болай да үзенең барлыгын, шөһрәтен сиздермичә йөргән, сәхнәне Галиябану, Галияләр белән балкыткан халык артисткасы Нурия Ирсаева уйчан карашын оныгына төбәгән: сез ничек яшәрсез икән, балакайлар? Галиябану, Галияләр кебек яши алырсызмы?

«Башсыз малай» булып чыгып киткән мин дә гамьле, башлы ир булып, узганнар аша киләчәккә агам. Башта — җавабын көткән мең уй, мең сорау...

Салонда татарча бию көе уйныйлар, яшьләр биилләр, кайберләре әлегә үз телен әйбәт белмәсә дә, татарча ритмга басалар. Мөгаен, сәяхәттән алар да уйланып кайталардыр.

Әтисе, җырчы-музыкант Радик Динәхмәтов белән сәхнәгә чыккан Сабина: «Минем җырлыйсым килә!» — дип аваз сала.

Түбән Камада сәяхәтчеләрне югары дәрәҗәдә каршыладылар. Вокалистларның Сәйдәшев исемендәге конкурсы монда үткәрелгән һәм сәяхәтнең рухи капитаны Марат Шәриповны Гран-при алуы белән иң беренче алар котлаган. «Яшь наратлар» белән ярыша-ярыша, Түбән Камада яшь Маратлар үсеп килә. Яшүсмер Марат Фәйрушинның җырлавын хәйран калып тыңладык һәм татар моңы агышыннан туктамас дигән өметле уйда калдык.

Башкортстанның атказанган артистлары Лилия һәм Халит Фатиховлар сәфәргә улларын да алып чыкканнар. Илшат — хәзер үк инде Хәния Фәрхиләр башкара алырлык көйләр иҗат итүче аһәңсаз, ә безнең Ринат Вәлиевне хәтерләткән Айрат сәнгать институтында укый, танына башлаган бик оста баянчы. Бу талантлы гаиләне җыр, көй бәйләп тора сыман.

Иншалла, төрле каршылыкларга, авырлыкларга карамастан, талантлы «Бабич балалары» туа, җырлап яши.

Кемнәрнең генә җырлавы яңгырамаган монда: Илһам Шакировның да, Рафаэль Ильясовның да, Хәмдүнә Тимергалиеваның да, шагыйрәләр Гөлшат Зәйнашева һәм

Флера Низамованың да җырлары дулкыннарда, йөрәкләрдә тирбәлгән.

Безне изге сәфәргә алып барган кораб Болгардан баеп кайтып килә: җан тулы күңел байлыгы, гамьле уй, ялгышларыбыз-хаталарыбыз өчен сызлану, үкенеч һәм киләчәккә өмет...

Чабаксардан Уфага килгән автобустагы тупас сүзләрдән, аяк астына шыплап тутырылган чемоданнардан, пассажирларның бер-берсенә тупас мөгамәләсеннән, иске машинасы ватылган саен татар шоферының урысча сүгенүләреннән тәмам арыган, авыру хәлгә төшкән идем. Матур сүзләр, ягымлы мөнәсәбәтләр, көләч йөзләр мохитенә килеп кергәч, кан басымы да, җан басымы да көйләнде, үземне егетләр кебек хис итә башладым. «Рамазан» сәяхәтендә Болгарга барган Швеция татары Туркер Соуккан да яшәреп кайткан. «Күңелем тулган иде һәм нәкъ шул мизгелдә татарлыкның ямен һәм бигрәк тә көчен тойган идем» дигән ул сәфәрдән кайткач.

Тиз агышлы сылу Агыйделдә, биек ярларындагы наратларын күккә сузган Чулманда, ике агымсуның көчен үзенә йоткан горур Иделдә тын гына агып бару, палубадан табигатьнең хозурлыгын күзәтү — тәнеңне, җаныңны тынычландыра, илһамландыра, күп вакытта тормышның кирегә агышын күреп сүнә язган өметеңне уята, Айлы-йолдызлы Күк йөзе уйларыңны мәңгелеккә алып китә. Бабаларыбыз бу юлларны кайчандыр каекларда узганнар, Идел суларында тирбәлеп, безгә мәңге җырларлык көйләр, шигырьләр калдырганнар.

Безне Марат Шәриповның «Рамазан» радиосыннан яңгыраган җыры уята:

> «Тор, шәкерт, җиттек Казанга,
> Алдыбызда бит Казан!»

Җиде көнлек сәфәрнең дүрт көне, дүрт төне безнең өчен тәмам. Без Казанда калабыз. Алар биредә көне буе булып, татар язучылары, шагыйрьләре белән очрашырлар, Тукай зиратына барып, Болгар сәламен тапшырырлар, истәлекле урыннар белән танышырлар.

Корабта узган дүрт көнем, дүрт төнем үзе бер гомер булып истә калыр. Их, дөньяның төрле ягына сибелгән халкыбыз да менә шулай, таркатырга тырышучыларга бирешмичә яшәсә иде!

Октябрь аенда халык санын алу алдыннан бу уйларым шигырьгә әйләнә һәм мин аны милләттәшләрем белән дә бүлешәм:

Һич ышанма,
Әйтсәләр дә:
Гадәттәге сан алу.
Аң бул,
Җан бул,
Бу — татардан
Сан киметеп җан алу.
Уйла, татар,
«Булмасын, дип,
Соңгы тапкыр тын алу...»
Бу — тарлыкка,
Татарлыкка,
Бөеклеккә сыналу!..

Әллә инде төш күрдем, әллә үзебез күрергә теләгән хыялый бер дәүләткә актым. Көннәр эссе, су кермәсәң — түзәрлек түгел. Күктә болытның әсәре дә юк. Ә мин Күктә бер әсәр күрәм. Юк, ул әсәр йөрәктә икән. Ул инде йөрәк читлеген кага.

Ике йөз мосафирны илаһи сәфәрдән алып кайтучы корабтан төшкәч, җирдә һаман чайкалам, дулкынланам. Бөтен барлыгымны җанга якын авазлар, аһәңнәр, көйләр, әби-бабаларыбызны назлаган Болгар җилләре иркәли.

Без төшеп калган кораб, Тукай маршын уйнап, туган җирләренә — Башкортстанга юнәлә. Якташларын, үз көй-җырларын озатырга Салават һәм Роберт Миңнуллин да килгәннәр.

Узганнар аша киләчәккә юл алучы корабта сагышлы да, дәртле дә, өметле дә җыр бара:

Булдылар, барлар, булырлар
Башкортстан татарлары!

*5— 9 июль, 2002*
*Агыйдел— Чулман — Идел*

# УКУЧЫ СОРАУЛАРЫНА ҖАВАПЛАРДАН

## «Гашыйклар тавы» чынбарлыктан алындымы?

Ул повесть-поэманы үзем ишеткән, күргән берничә вакыйгадан алып, шуларга хыялымны да кушып иҗат иттем.

1977 елның сентябрь аенда без Туфан Миңнуллин белән бергә, шәһәр советының чакыруын кабул итеп, Кемерово өлкәсенең Юрга каласында булган идек. Анда безне Хәнәфи ага каршылады. Өенә алып китте. Сугыштан инвалид булып кайткан. Сәнгать түгәрәге оештырып, шундагы татар яшьләрен туплаган. Җыр ансамблендәге яшьләр белән таныштык. Алар безне җыр белән урамда да озатып йөрделәр, киткәндә перронда җырлап калдылар. Кайтышлый эти-әниләрнең хәлен белергә үзебезнең Яңавылга да кердем. Әсәрнең башы шушы күренешләрне документаль төгәллек белән күрсәтә.

Гашыйклар тавы ул безнең Ямадыга якын гына урнашкан, еракта ук күренеп торган Йөгәмәш тавы. Аның кыр үрдәген атып казанга салган аучы турындагы риваяте бар. Әсәрнең нигезенә шул легенда алынды.

Татарстан язучылар оешмасы идарәсендә эшләгәндә, минем кабинетка өлкән яшьтәге бер ханым килде һәм үзенең фаҗигале хәлен сөйләде. Ул яраткан иренең сугыштан кайтуын бик озак көткән, үлем хәбәре килгәннән соң да көткән... Инде өметне өзгәч кенә, читтән кайткан авылдашы аның иренең исәнлеген, икенче бер хатын белән яшәп ятуын, ярты гәүдәсенең хәрәкәтләнмәвен әйткән. Үз гаиләсенә кайтмавын хатынына бәла булырга теләмәвеннән дип аңлаткан. Шундый хәлдә калган ханым нишләргә дип, миннән ярдәм сорый...

Әсәрне язарга этәргән тагын бер вакыйга. Балтач районына таба барганда, дулкынланып үскән арыш басуына карап, икенче бер апа турында сөйләделәр. Авылны күчергәннәр. Күпме генә тырышсалар да, бер апаны урыныннан кузгата алмаганнар. «Сугыштан кайтмый кал-



Уңнан сулга: Т.Миңнуллин, Хәнәфи Биккулов, И.Юзеев. Юрга. 1977

ган ирем кайтыр да мине таба алмый йөрер» дип көтә дә көтә,шуңа күрә моннан күчеп китәргә теләми икән. Шунда берүзе яшәп, соңгы сулышын алгач кына, бу җирләрне дә сөреп, арыш чәчкәннәр икән.

### *«Таныш моңнар» дагы Резидәнең прототибы бармы?*

«Таныш моңнар»ның прототибы безнең авылның егете Фәнәис Мусин. Ул: «Институтка кермәсәм, авылга кайтып күренмим»,— дип, үзенә сүз биреп киткән иде. Институтка керә алмауны бик авыр кичергән. Болай гына, заводта эшче булып эшли торыйм, дигән дә эшен, дусларын яратып шунда торып калган. Соңыннан югары уку йортын да тәмамлады.

### *Драматург буларак кайсы әсәрегез иң беренче язылды?*

1960 елны җәйге ялга хатыным Тәфтилә белән аның туган авылы Тәтешлегә кайткан идек. Үземә кызык итеп кенә «Янар чәчәк» исемле комедия язып куйдым. Көләкөлә җиңел яздым. Мин аны куелыр дип уйламадым да.

Архивка салып куйдым. Бервакыт Казан урамында йөргәндә, Празат Исәнбәт белән Вәкил Закиров очрадылар. Мин аларны өемә чакырдым. Островский урамындагы (Клячкин хастаханәсе каршында) өйгә кереп сөйләшеп, мәзәк хәлләр сиптереп утырабыз. Шул вакыт Празат: «Син бик шаян кеше икән, безгә бирәр комедия язмыйсыңмы?» — дип әйтеп куймасынмы! Мин дә шаярып кына, кыюланып: «Үзем өчен генә язган бер нәрсәм бар барын, ул куярлык түгел инде», — дидем. Мине укырга күндерделәр. Көлә-көлә тыңладылар. Минем күңелне күрү өчен генә дип уйласам, чынлап булып чыкты. Празат әйтә: «Мин моны куям!» — ди. Вәкил әйтә: «Председатель Җәләевне үзем уйныйм!» — ди.

Уеннан уймак чыкты. «Янар чәчәк» спектакле Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә 1961—1962 елларда уңышлы барды. Вәкилнең Җәләеве, Ибраһим Гафуровның Җәмәе нык истә калды. Фәнәвине яшь Шәүкәт Биктимеров, Фәүзияне яшь Рауза Хәйретдиновалар романтик хискә төреп уйнадылар.

### *«Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы ничек туды?*

Мәктәптә укыган елларның, хыялый балачакның моңсу истәлеге бу. Фәнәви, Фоат һәм Риф минем якын дуслар иде. Без бергәләп үзебезнең Гәрә елгасы буйлап көймәдә сәяхәткә чыктык. Ниятебез елганың койган урынын эзләп табу иде. Әмма без максатыбызга ирешә алмадык. Бик күп авырлыклар күреп кире кайтсак та, без җитдиләнеп, олыгаеп кайттык. Беребез шул авырлыкларга түзә алмыйча, беренче көнне үк кире киткән иде. Без түздек, өч дус бергә калдык.

Поэманың нигезендә менә шушы вакыйга ята.

### *«Олы юлның каены» поэмасы ничек язылды?*

Бу поэма баштан ахырга кадәр доументаль материалга нигезләнгән.

1983 елның җәендә Яңавылда яшәп яткан әти-әни янына кайткан идем. Күршедәге журналист Әмир Фатыйхов хәлләре бетеп, йөгереп керде.

— Ой, Илдар, син исән икән, сине Яңавыл больницасында үлгән икән, диләр.


Фәнүс Юзеев

Больницада авырып үлгән кеше минем туганнан туган абыем Фәнүс Юзеев булып чыкты. Больницага йөгереп бардым. Мин барганда ул исән иде әле. Икенче килгәндә мәңгегә күзләрен йомган иде инде. Үзенең апасына: «Илдар минем турыда нәрсә дә булса язсын, мине онытмасын»,— дип әйтеп калдырган. Фәнүсне Ямады зиратына күмдек. Соңгы юлга озатырга бик күп нефтьче дуслары килде. Соңгы юлга озаткач, аның үз өендә искә алдык, хатирәләр сөйләдек.

Икенче көнне үк мин Фәнүс турында шушы поэманы язарга утырдым. Фәнүснең исемен поэмага Фәндүс дип керттем.

Татарстан радиосы бу поэма нигезендә постановка әзерләде. Татар академия театры артистлары башкарды. Җырга музыканы Мәсгут Имашев язды. Аерым җыры Зәһрә Сәхабиева башкаруында популяр булып китте.

Поэманың исемен китапта икенче тапкыр чыкканда «Туган ягым каеннары» дип куйдым.

### *«Миләүшә» поэмасын нигә үзгәрттегез?*

«Миләүшә» поэмасы 1954 елны язылган. Нигез итеп шулай ук Фәнүс Юзеевны алдым. Фәнүс кырык чакрым ераклыктагы Эткенә авылыннан үзенә кыз урлап алып кайтты. Электән үк ул кыз белән яратышып йөргәннәр булып чыкты. Ата-бабаларыбыз гадәтен тормышка ашыру гына булган.

Поэманың беренче варианты Питрәч район газетасында басылды. Кайбер язучылар тарафыннан тәнкыйтькә очрады. Кыз урлау безнең җәмгыятькә ят күренеш дип таптылар. Шәйхи ага Маннур әсәрне яратса да, әсәрне яңадан төзәтү ягына борды. Хәзерге вариантын юмористик тонда төзәтергә туры килде.

Озак еллардан соң шундагы Миләүшә җырына Сафьян Ибраһимов көй язган. «Сине уйлап янам» исемле ул җыр халыкта җырлана.

### *Композиторлар белән язылган җырлар*

«Янар чәчәк»тән Фәүзия һәм Лира җырлары. Шул исемле спектакльгә композитор Мирсәет Яруллин тарафыннан язылган җырлар. Алтмышынчы елларда ук иҗат ителгән бу җырлар озын гомерле булып, хәзер дә җырланалар.

Мирсәет белән иң беренче язган җырыбыз «Яшьлек дустыма» булды бугай. Ул миңа әзер көй китерде һәм шуңа текст язуны үтенде. Иҗек үлчәүләре гадәттәгечә булмагангадыр, бик авыр язылды. Шуңа күрә мин аны шигырь дип түгел, текст дип атыйм.

«Таң кызы җыры»н Мирсәет Яруллин Минзәлә драма театрында 1982 елда куелган «Соңгы төн» шигъри трагедиясенә язды. Хәзер аерым җыр булып калды. Вафирә Гыйззәтуллина һәм Клара Хәйретдинова репертуарында.

«Серле чәчәк» җыры.

Көннәрдән бер көнне чәчәкләр үстерергә яратучы Ләбибә апа Ихсанова дачадагы өеннән минем яныма килде. «Ишеткәнең юкмы, кичен йомылып, иртән ачылучы бер чәчәк бар икән, шуның исемен белмисеңме?» — диде ул.

Мин белми идем.

Шул сүзләр йөрәгемә кереп калды һәм чыкмады. Мирсәеткә дә мин шул сорау белән бардым. Ул да белми иде.

Чәчәкнең исемен без икәү бергә эзләргә тотындык: мин — шигырьдә, ул — көйдә. Һәм... таптык. Ул «Серле чәчәк» булып чыкты.

«Ике малай китә армиягә» шигыренең җырлануын беренче тапкыр халыктан, хәрби хезмәткә китүче, озатучы яшьләрдән ишеттем. 60 нчы елларда студентларның яраткан җыры булуын да белдем. Соңрак, концертын тыңлаганда, Рафаэль Ильясов башкаруында ишеттем. «Халык җыры» дип игълан иттеләр. Җырчыга мин язганны әйткәч, аптырап калды. 70 нче елларда Казанга Башкортстанның үзешчән композиторы Әкрам Даутов килде һәм миңа ул җырның авторы икәнен әйтте.

«Мәтрүшкәләр» шигырен Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыганда яздым. Җыр булып китәр дип уйламаган идем. Беренче тапкыр халыктан ишеттем. Әкренләп радиодан да җырлый башладылар. Авторы Зәй районында доктор булып эшләүче Алмас Гыйләҗев булып чыкты.

### *«Мәхәббәт китабы»ндагы «Сирень чәчәге» геройлары тормышта бармы?*

Чыннан да, мин аны үзем белгән кешеләрдән алып яздым. Фәнүдәнең исемен дә үзгәртмәдем. Ямады урта мәктәбендә җиденче класста укыганда, Фоат дустым классташыбыз Фәнүдәгә гашыйк булды. Фәнүдә дә аны ярата икән. Әмма Фәнүдә бик каты авырып китте һәм барыбызны да кайгыга салып, үлде. Фоат акылдан шаша язды, мин дә бик тирән кичердем. Төзәтә алмаслык бер үкенечем калды: исән чагында мин аны, шаярам, дип рәнҗеткән идем. Укытучы класска килеп кергәндә, алдымдагы Фәнүдә торып баскач, мин аның урындыгын тартып алдым. Шаярам, имеш. Фәнүдә башы белән партага бәрелде һәм елап җибәрде. Әлбәттә, моның өчен ул миңа ачу тотмады. Әмма мин үземне шуның өчен гомер буе гафу итмәдем.

Фоат дустым хәзер Мәскәүдә яши. Очрашкан чакларда яшьлек мәхәббәтләребезне искә алып, җырлап-моңаеп алабыз. Поэмада аның исемен Айдар дип үзгәрттем. Ул бит документаль әсәр түгел, шигъри хыял белән баетылган.

### *«Онытылмас бәет»нең материалын каян алдыгыз?*

Ул драманы туган авылым Ямадыда булган вакыйгадан алып яздым. Камил дигән авылдашыбыз сугыштан бик күп орденнар тагып кайтты. Кавалерист булган. Кайту белән сельпо рәисе итеп куйдылар. Төрле шәһәрләр белән бәйләнешкә кереп, кибетне товар белән тутырды. Бердәнбер көнне язгы ташу вакытында Камилебез илле мең сумманы алып, юкка чыкты. Авылда төрле легендалар таралды. Яңавылга акча тапшырырга барганда суга баткан, имеш... Акчасын талап, үзен үтергәннәр, имеш...

Акчаны алып, Свердловски ягына качкан, имеш... Эзләп тә табалмадылар. Озак еллардан соң тагын бер хәбәр таралды: Камил исән икән. Хөкем ителү срогы чыккач, Яңавылдагы сеңлесенә кереп чыккан. Фамилиясен үзгәртеп, Пермь өлкәсендә әллә колхоз рәисе, әллә совхоз директоры булып эшли икән...

Равил Тумашев куйган спектакльдә Вәдүтне (мин аны шул исем белән бирдем) артист Мәмәшев әйбәт уйнады. Аны Академия театрына алгач, пьеса репертуардан төште, илле тапкыр гына уйналып калды.

### *«Сандугачлар килгән безгә» әсәре ничек язылды?*

Моңсу комедия 1973 елда язылды. Моңсу комедия дигән жанрның татарчасын иң беренче мин керттем. Аңа кадәр бездә бу атама юк иде. Урысларда грустная комедия диләр. Миннән соң барысы да моңсу комедия дип яза башладылар.

Пьесадагы төп вакыйганың шаһиты мин үзем. Аркадагы авыруны дәвалау өчен берничә ай Казандагы 15 нче хастаханәнең нейро-хирургия бүлегендә яткан идем. Шунда авылдан Хәмзин дигән кешене карчыгы китерде. Аның баш миенә операция ясап, шешен алдылар. Шул вакытта Хәмзин хәтерен югалтты.

Спектакль күп кенә сәхнәләрдә куелды, озын гомерле булып чыкты.

«Бәхетемнән узып барышлый». 1979 елда Татар дәүләт күчмә театрында куелды. Язган чорда танылган скульптор Василь Маликовның остаханәсендә берничә тапкыр булдым, рәссам тормышын күзәттем. Әсәргә Василь тормышының, иҗатының кайбер моментлары кергәндер. Айтуарны Марсель Җаббаров уңышлы уйнады. Премьера булган көнне аның малае туган. Исемне озак эзләмичә, Айтуар дип кушкан.

### *Төштә дә иҗат итәсезме?*

Бик сирәк. Ике шигыремне төш күргәндә яздым дип әйтә алам. Менә бер төш. Берәүгә сөйлим: «Әгәр мин физика укытучысы булсам, хәзерге самолет тизлеген

болай аңлатыр идем. Мин сөйгәнем янына кайтам. Самолет китү алдыннан хәбәр җибәрәм. Кайткач, сөйгәнем сорый: «Нигә хәбәр итмәдең?» — ди. Ә мин әйтәм: «Хәбәр җибәргән идем. Хәбәремнән алда кайтып җиткәнмен. Чөнки самолет тавыш тизлегеннән тизрәк оча...»

Уянгач, мин моны шигырьгә әйләндердем.

Икенче төш.

Авылыма кайтып барам. Менә инде туган өйнең тәрәзәсе күренде. Хәзер әти, әни килеп чыгар. Моңа кадәр бер тапкыр да аларны кочакламадым, салкын гына күрештем. Бик җылы итеп күрешергә дип, кочагымны ачам... Уянып китсәм, әти дә, әни дә юк, мәңгелек йортка киткәннәр.

Бу төшне шигырьгә әйләндердем.

### *Шигырь ничек туа?*

Өч авторның берьюлы бер үк исемдә бер үк җөмләфикергә шигырь язуы мөмкинме? Мөмкин икән. Андый шигырьне без язып карадык.

Болай булды: 1994 елның июнендә Казанга Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры гастрольләргә килде. Мин театр белән бергә килгән дустым — шагыйрь һәм драматург Рафаэль Сафин янына — «Дуслык» кунакханәсенә киттем. Бераздан безгә Туфан Миңнуллин да кушылды. Дуслар җыелган җирдә (Туфан әйтмешли) хикмәт булмыйча калмый инде ул. Сөйләшә-сөйләшә, бүлмәдән бүлмәгә йөри-йөри, СССРның халык артисткасы Гөлли Мөбәрәкова бүлмәсенә барып кердек. Кунакчыл хуҗабикәнең чаен эчә-эчә, гәпләшә-гәпләшә, бәхәсләшә-бәхәсләшә, шактый озак утырганыбызны сизеп калган түземсез Туфан, сәгатенә карап: «Әйдә, киттек, егетләр!» — дигән бер җөмлә әйтеп ташлады. Ә минем бер дә китәсем килми. «Утыраек әле чак кына»,— дим. Сабыр холыклы Рафаэль сикереп үк торды: «Үзе шигырь бит бу җөмлә!» Туфанга җитә калды: «Әйдәгез, өчебез дә шул исемдә шигырь язабыз!»

Күңелгә кереп оялаган шул җөмлә өчебездә дә шигырьгә әверелде...

## «Син каян?» дип сорасагыз...

Әни ягыннан — мулла нәселе.

Минем дәү әни — Тәскирә исемле. Башкортстанның Караидел районы Подлуб авылыннан. Әхмәтдин мулла кызы. Әхмәтдин, беренче хатыны үлгәч, икенчегә өйләнә. Сәлмән Таһиров һәм Гыйльмия Таһирова — икенче хатыннан. Тәскирә — дәү әни Иштебай авылы (Мишкә районы) мулласына кияүгә чыга. 1930 елларда биш мулланы Ново-Троицк дигән урыс авылы янында аталар. Шуның берсе — минем дәү әти була. Исеме — Хәбиб.

Мин болар турында бик соң гына, әти-әниләр үзләре вафат булгач кына белдем. Алар бу фаҗигане бездән яшергәннәр, Нил белән миңа сөйләмичә китеп бардылар. Ул вакытларда безнең юл киселер дип уйлаганнардыр инде.

Безнең әнкәй — Шәкүрә мин туганнан бирле урын өстендә ятты. Хәзер уйлыйм: шул чорның газаплары аны авыруга сабыштыргандыр. Беренчедән, әтисенең фаҗигале үлеме, икенчедән, әнисе — атылган мулла хатыны, өченчедән, әткәй — коммунист. Аны КГБ органнары туктаусыз эзәрлекләгән. Нахак ялалар нигезендә кулга алып сорау алганда, Яңавылда бик нык кыйнаганнар. Үз мәктәбен яндыруда гаепләгәннәр. Мәктәп җыештыручы хатынның ваемсызлыгы аркасында янган. Уфада да интектерәләр, ябуда тотып, газаплыйлар. Кыйналу нәтиҗәсендә акылына зыян килә. Аны хастаханәгә салып кына төрмәдән алып калалар. Берничә ел буе укыта алмый.

Бу хакта безгә сөйләмәделәр, яшерделәр.

Дәү әни бик диндар иде, мин аның биш намазны калдырганын белмим. Дини китаплары бик күп иде, шуларны Нил белән миңа укый иде. Шул мифологик әкиятләр, риваятьләр әдәбиятка мәхәббәт уятуда сәбәпләрнең берсе булгандыр дип уйлыйм. Җыр тыңларга бик ярата, бигрәк тә Фәридә Кудашеваны бирелеп тыңлый.

Әнкәй бик тә шигъри күңелле, нечкә җанлы. Гомер буе шигырь язды. Без әни ягыннан — хисле, моңлы нәселдән. Дәү әнинең бер туганы — Сәлмән Таһиров — 1941 елны «Ленин» ордены белән бүләкләнгән полковник-разведчик. Әдәбият-сәнгатьне яратучы, милли җанлы

зыялы кеше иде. Татар телендә «Урман гарнизоны» исемле әдәби-документаль повесть язды, урысчага үзе тәрҗемә итеп нәшриятта чыгарды. Бер туганы — Гыйльмия Таһирова — балалар язучысы, «Тыңлаусыз чыпчык баласы» дигән китабы да бар. Хәмит исемле тагын бер туганнары радиокомитетның аккомпаниаторы— музыканты. Сугышта һәлак булган.

Әнкәйнең сеңелләре — Әминә белән Мәрьям утызынчы елларны Үзбәкстанга китеп, шунда саргаеп яшәделәр, үлделәр. Ямадыны сагынып кайтып, елый-елый кире китәләр иде. Анда китүләренең сәбәбен хәзер генә аңладым. Энеләре Гарәби Беломорканал төзелешенә җибәрелеп, шунда юкка чыккан.

Әнкәйнең бертуган энесе Зөфәр Халиков (Әнкәйнең кыз фамилиясе — Халикова) гармунда уйный иде. Сугышка китте. Бик бәләкәй булсам да, гармунда уйнавы күңелдә калган. Моңның бер тамчысы, бәлки, шуннандыр. Соңыннан гармун белән җенләндем. Абыйдан калган гармун турында соңыннан шигырь дә яздым. Зөфәр исеме «Таныш моңнар»га шуннан килеп керде. Зөфәр абый ауга йөрергә ярата иде. Куян атып кайтканын әнисе бер дә яратмады. Шул чорның комсомолы буларак, Зөфәр абый диндар әнисе белән каршылыкка кереп, күпмедер вакыт башка квартирада яшәгән. Бала чакта мин моңа әһәмият бирмәгәнмен. Ул армиягә сөенеп китте, ниһаять, уеннан чын сугышка китәм дип уйлагандыр, мәрхүм. Аннан сугыш башланды. Беренче айларда ук хәбәрсез югалды. Бергә киткән якташлары соңыннан һөҗүм алдыннан соңгы тапкыр күргәннәрен әйткәннәр.

Әнкәй, гомере буе диярлек урын өстендә ятып, 1986 елда (25.01.86) вафат булды. Кабер ташына үзе исән чакта язган шигырен кадакладык:

«Сау булыгыз, гомер иткән җирләр,
Тыныч тормыш сезгә миннән соң!»

Әткәй — Юзеев Гафур Фәрвәзетдинович (1903—1985) үзебезнең Яңавыл районы Ямады авылында туган. Балачакта ук әти-әнисез ятим калган. Көтү көткән. Революция аның кебекләргә юл ачкан. Мәдрәсә тәмамлаган. Гомер буе укытучы булып эшләде. 1919— 1924 елларда Кызылъяр волком комсомолының секретаре. Аннан волком председателе. 1930— 1933 елларда Казанда ТКУда укый. Так-



(Сулдан уңга): дәү әни — Тәскирә, Мәскәүдәге туганыбыз Рәмзия, Гафур Юзеев, Шәкүрә Юзеева, Илдар Юзеев. 50 нче еллар

ташның сәхнәдән ничек оста итеп шигырь укуын сөйли иде. Үзенең дә Казан матбугатында очеркка тартым бер язмасы басылган. Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр артиллерист капитаны булып катнашты. Чехословакия һәм Венгрияне азат иткәч — хәрби комендант урынбасары. Сугыштан 1946 елда гына кайтты. Аннан соң — Ямады урта мәктәбендә директор, укытучы, тәрбияче. Мине дә тарихтан укытты. Аның дәресендә утырганда бик уңайсызлана идем. Аны бөтен тирә-як, район ихтирам итә иде. Авыр хәлгә калганда, ярдәм сорап аңа киләләр иде. Халыктан уңайсызланып, үзебезгә йорт та салмады (ул заманда шундый аскет коммунистлар да бар иде). Без гел кеше өендә тордык. Берничә ел Чытырман очта ташландык бер өйдә яшәгәнне яхшы хәтерлим.

Әткәй сугыштан кайткач, ниһаять, 1948 елларда йорт салды. Аны хезмәт укытучысы, үзенең дусты Малик Даутов — Нил белән бергә очлап чыктылар. Кечкенәрәк булгач, мине катнаштырмадылар. Шуңа күрә Нил балта эшен белә, мин ул яктан — булдыксыз.

*23.11.98*

## Әнкәй истәлеге

*Әнкәй моны Башкорт дәүләт педагогия институты студентлары соравын искә алып язган.*

1941 елны сугыш башлану белән, әтисе фронтка китте. Шул елны Илдар беренче класска укырга керде. Мин элек укытучы булсам да, Илдар тугач, озак еллар авырып ятарга туры килде. Балаларның бигрәк тә инша язганда сүз табалмый интегүләрен белә идем. Шуның өчен мин аларга кечкенәдән үк төрле әкиятләр сөйли һәм шигырьләр укый торган булдым. Үзләреннән кечкенә шигырьләр ятлата идем. Өченче класска җиткәч, бу эшләр белән икесе дә мавыгып киттеләр. Экскурсияләрдән, урманнардан, җиләктән кайткач, үзләреннән сөйләтеп, күргәннәре турында язарга куша идем. Шуннан матур инша язарга өйрәнеп киттеләр. Үзләре дә кечкенә шигырьләр яза башладылар. Өченче класста укыганда Яңавыл район газетасында икесенең берьюлы шигырьләре басылып чыкты. Илдарның 1944 елны чыккан бер шигыре истә калган. Ул «Минем әти капитан» дигән шигырь иде. Алар үзләре дә пионер журналлары һәм «Пионерская правда» газетасын алдыралар, андагы оештырылган уеннарга җаваплар язалар, газета-журнал, радиотапшыру редакцияләренә шигырьләр һәм хәбәрләр җибәрәләр, аларга һәрвакыт җавап хатлары килеп кенә тора иде.

Илдар сугыш вакытында балалар өчен кечкенә пьесалар да язгалый иде. Аны Ямады клубында һәм Максим авылында куйганнар иде. Немецлар басып алган җирләрдә пионерларның көрәше турында. Ул, әлбәттә, бик балаларча язылган, чөнки үзе дә пионер яшендәге бала иде бит.

Сугыш туктаган елны «Ямады егетләре» дигән озын шигырь язды. Ул ун классны бетереп сугышка киткән һәм батырларча һәлак булган авылдашлар турында иде. Аны концерт вакытында үзе укыды, ата-аналары бик җылаганнар. Бу инде хәзерге поэмаларының башлангычыдыр дип уйлыйм.

Әдәби китапларны да бик күп укыйлар иде. Артык бирелеп китеп, укуларына зыян килереннән курка идем. Шуның өчен һәрвакыт шагыйрь яки язучы булу өчен бик күп фәннәрне тырышып укырга кирәклекне аңлатып тора идем. Икесе дә әдәби китапларны бик яратып

укыйлар иде. Балачакта Илдар Тукайны яратып сөйли, үскәчрәк Такташны бирелеп укыганы хәтердә калган.

Пионер яшендә иптәшләре белән Гәрә елгасы буйлап походка чыктылар. Берничә көн йөзеп, кояшта янып-пешеп тагын көймә белән кайттылар. Соңгы язган «Өчәү чыктык ерак юлга» дигән поэмасы шуны хәтерләтә торгандыр.

Ун классны бетергәч, Казан педагогия институның филология факультетына керде һәм беренче көннәрдә үк яшьләр газетасында «Саумы, институт!» дигән шигыре басылып чыкты.

*Шәкүрә Юзеева*
*16 февраль, 1966*



Илдар — 7 нче класс укучысы. 1948

# Әнкәй шигырьләре

## *Ана теләге*

*(Илдарның туган көненә)*

Илле яшең котлап ниләр бирим?
Гөлләр бәйләмеме?
Зур өметләр белән горурланып,
Көттем бәйрәмеңне.
Гөлләр шиңә. Намус-вөҗдан
Бүләк итәм гомергә.
Ана васыяте онытылмасын,
Гамьсезләнеп,
Әйләнмәсен көлгә-күмергә.
Гомер баскычларын менгән чакта,
Авыр була олы юл башы.
Изге теләкләрем алып барсын,
Ак бәхетләр булсын юлдашың.

Шатлыгым зур. Инде теләгем шул:
Гомергә кал иҗат үрендә!
Шәфкать, назлар үссен,
Тамыр җәйсен күңелең түрендә.

*1983*

## *Хушлашу*

Мин дөньядан киткәч бик ямансу булыр
Йортымдагы һәрбер үләнгә.
Сугардым бит көчле мәхәббәтем белән,
Матурлыкның кадерен белгәнгә.
Агач саен кәккүк кычкырганда
Бик ямансу була урманда.
Кәккүгемә һич тә үпкә тотмыйм,
Калган гомерем кыска булганга.
Сирень чәчәкләре аткан чакта
Сагышлырак була язларда.
Мин булмагач, сирень чәчәкләре
Мохтаҗ булыр инде назларга.
Кем иркәләр сирень чәчәкләрен,
Кулларында тоеп җылысын?
Сау булыгыз, гомер иткән җирләр,
Тыныч тормыш сезгә миннән соң.
Сау булыгыз, сез дә, авылдашлар,
Сау булыгыз, басу-кырларым...
Балаларым, искә алырсыз бит,
Сезгә кала шушы җырларым.

*1985*

## *Мин каен булалмадым...*

Әнкәй мине авыр тудырган. Мине якты дөньяга китергәннән соң хәле җиңеләймәгән, гомерлеккә өзлегеп калган.

Әнкәй каеннар ярата иде. Безнең өйнең тәрәзә алдында ак каен үскән. Мин аны хәтерләмим, сабый чагымда күрә алмый калдым.

Әнкәй табигатенең бер сыйфаты күчкәндерме, мин дә гомерем буе каеннарга гашыйк! Һәрбер поэмамда диярлек каеннар, туган ягым каеннары... Каләмдәшләрем дә, үзем дә каеннарны гүзәл кызга тиңлибез, «каен сеңелләр» дип дәшәбез.

Хәзер мин ак каенны әнкәйгә тиңлим.

Шулай беркөнне әткәй мине — ике яшьлек сабыйны күтәреп, тәрәзә янында басып тора икән. Тышта көчле яңгыр ява, күк күкри, яшен яшьни, каеныбыз, давылланган чәчләрен-яфракларын тузгытып, җиргә кадәр иелә, нидер әйтергә тели кебек... Урында яткан әнкәй, эчтән генә белгән догаларын укый-укый:

— Яшен яшьни, кит тәрәзә яныннан! — ди.

Әткәй тыңламый. Курыкма, янәсе, безгә тими ул!



Әнием белән...

Сүзен әйтеп бетерергә дә өлгерми, коточкыч шартлау өйне тетрәтә. Әткәй идәнгә барып төшә. Урында яткан әнкәй мине көчсез куллары белән эләктереп ала. Башта мине яшен суккан дип куркалар, бераз вакыт узгач, мин кычкырып елап җибәрәм...

Һушларына килеп, тәрәзәгә карасалар: өй алдындагы каенны яшен суккан.

Ак каеныбыз, яшеннең үтергеч көчен үзенә юнәлтеп, мине коткарган.

Әнкәй дә, ак каен сыман, тормышның бөтен авырлыгын үзенә алып, авырып, мине саклап калды бит.

Хәзер мин әнкәйне ак каенга тиңлим.

Мин генә каен булалмадым. Әнкәйне авырулардан, үлемнән саклап кала алмадым.

## Сәлам белән шагыйрь улыгыз...

1959 елның кышында Шәүкәт Галиев белән аның туган авылы Олы Бакырчыда әдәби кичә үткәрдек. Клуб ягылмаган, шактый салкын, дәртләнеп шигырьләр сөйли-сөйли, бераз җылындык. Шәүкәттән соң миңа сүз бирделәр. Уку өчен яшьләрнең Мәскәүдәге бөтендөнья фестивале тәэси-



Гафур Юзеев

рендә туган шигырьләрне сайладым. Англиядән килгән таныш делегатка багышланган «Авторучка» исемле шигыремне сөйлим:

Очрашырга язсын
киләчәктә,
Автоматлар түгел,
Авторучка тотып кулларга!

Күрәм: шул вакыт клуб ишеге ачылып, тун кигән бер абзый керде дә иң алгы рәткә килеп утырды. Үзе игътибар белән тыңлый, күршесеннән нидер сорап та куйды. Шигырьне тәмамлагач, тыңлаучылардан сораулар көтеп калдым. Тун кигән абзый сүз сорады да безнең янга сәхнәгә менде.

— Белдерүне укып, күрше авылдан килдем. Әйтегез әле, сезнең фамилиягез, чыннан да, Юзеевмы?

— Әйе.

— Исемегез Илдармы?

— Әйе.

— Әтиегезнең исеме Гафур түгелме?

— Әйе. Гафур.

Абзый шатлыктан кычкырып ук җибәрде:

— Гафур Юзеев! Минем фронтташ дустым! Ул исәнме?

— Исән. Сез аны каян беләсез?

— Белмичә! Без аның белән фронтта очраштык. Өйдән килгән хатларны бер-беребезгә укый идек. Гафурның, татар егетләрен җыеп, кечкенә улы Илдардан килгән, шигырь белән язылган хатларны укыганы һич онытылмый. Салкын окоп туган өй шикелле җылынып киткәндәй була иде. Кем уйлаган ул бала шагыйрь булып, без яулап алган тынычлыкны яклап, шигырьләр язар дип! Сәлам әйт Гафур дустыма, Хәй Галимов исән, диген!

Шундый очрашулар да була тормышта.

1996 елның февралендә укытучылар Шәүкәт белән икебезне очрашуга чакырдылар. Бер ханымның Олы



Илдар һәм Нил этиләре белән. 1946

Бакырчыдан икәнен белгәч, мин теге вакыйганы сөйләдем дә:

— Хәй Галимов ага исәнме? Миннән сәлам әйтегез,— дидем.

Хәй абзыйның авылдашы башын түбән иде:

— Ул юк инде.

Минем әткәй дә юк инде. Шундый очрашулар да була тормышта. Укытучылар Шәүкәт белән минем дуслыкның кайчан башлануы турында кызыксындылар. Көтмәгәндә Шәүкәт болай диде:

— Якташым Хәй абый сугышка кадәр минем әткәй белән дус булган. Илдар белән минем очрашу ихтималы безнең этиләрдә үк булган, димәк...

Ә 1943 елда фронттагы әтиемә язган, татар солдатлары җыелышып укыган шигырьне мин кесәмдәге дәфтәремдә кадерләп йөртәм. Аның белән укытучыларны да таныштырдым. Менә ул:

Дошманнарга төбәп аткан чакта,
Калтырамаслык булсын кулыгыз.
Сугышларда батыр булыгыз,
Сәлам белән шагыйрь улыгыз...

# Яшьлек дустыма хат

Яшьлек дустым Газиз белән без Казан дәүләт педагогия институтында бергә укыдык. Укуны тәмамлагач, ул үз теләге белән, язучы булу һәм тормышны өйрәнү өчен дип, Себергә китте. Ул аннан миңа хатлар язып торды. 1956 елның августында язган хатында шундый юллар бар: «Сиңа Урал таулары артыннан Себер сәламнәре җибәрәм. Кызык кына бу язмыш, ә? Әле яңа гына Казандагы дус-ишләр белән шау килеп йөри идек. Бүген менә мин япа-ялгызым бер Себер авылында, тайга арасында моңаеп утырам. Ниһаять, эш урынына килеп җиттем... Ну, малай, монда материал! Бик күп! Рәтләп яза белүче генә кирәк. Йөрсәң, күрәсең икән аны. Яңадан-яңа кешеләр, яңадан-яңа пейзаж. Килгәнемә үкенмим». Түмән өлкәсенең Киндер авылыннан язган хатларында Газиз Казан хәбәрләрен кыска язуым өчен үпкәли. Менә хәзер шул еллардагы ялкаулыгым өчен үкенеп, аны югалтканга егерме сигез ел тулган көннәрдә аңа хат язып утырам.

«Син Займищедагы дачаңда учак кабызып, берүзең уйланып, хыялланып утырырга ярата идең. Хәзер мин учак ягам, хыялымда булса да терелтеп, синең белән сөйләшәм. Исеңдәме, элекке монастырьда тулай торакта яткан, кайнар су эчеп, бер телем икмәк кабып лекциягә чапкан чаклар? Затлы киемнәрең булмаса да, син бик пөхтә киенергә яраттың, ул чордагы студентлар модасы — вельветка үзеңә килешеп тора иде. Әдәбият түгәрәгендәге кайнар бәхәсләрдә артык кызып китсәк, син безне аз гына сүзләр белән тынычландыра идең. Ә үзеңнең шигырьләреңне тикшерүне хәтерлисеңме? Иллә дә каты эләкте үзеңә. Мин булсам, түзә алмыйча үпкәләп чыгып китәр идем. Ә син, тыштан берни сиздермичә, барысын эчеңә йоттың, берничә көн башыңны түбән иеп йөрдең. Караватыңда уйланып яттың да: «Миннән шагыйрь чыкмый, башка шигырь язмыйм»,— дидең. Озак кына вакыт узгач, гаҗәпкә калдырдың. 1955 елны «Чаян»да шаян хикәяң басылып чыкты. Син күкнең җиденче катында идең, әмма борын күтәрмәдең, тыныч кына хикәяләр язуыңны дәвам иттең. Кыска хикәяләр язуда-



И.Юзеев, Г.Мөхәммәтшин — Казан дәүләт педагогия институты студентлары. 1953

гы маһирлыгыңны танылган сүз осталары күреп алдылар, сине бигрәк тә юмор остасы Мирсәй Әмир үз итте. «Ялкын» журналында эшләгәндә, без (мәрхүм Габделхәй Сабитов та) бөтенләй балаларга әверелдек. Редакциягә әйбәт әсәр килеп керсә, зур чуртан тоткан кебек сөенә идек. «Без әле җирдә яшибез», «Саумысез, аккошлар» кебек повестьлар, кызыклы хикәяләр язып, син үзең дә балаларны сөендердең.

1972 елның февралендә Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыганда, Казаннан шалтыраттылар: «Газизнең йөрәге тибүдән туктаган...» Сагынуыңа түзә алмыйча, кар-буранлы салкын көндә, чанага ятып җырлый-җырлый кайткансың: «Минзәләне күрү өчен...» Соңгы тапкыр кайтуың булган икән...

Кайчандыр син яшәгән урыннарда учак кабызам һәм, ялгызым гына, синең белән сөйләшәм. Сагынырлык кеше идең шул син, яшьлек дустым Газиз...

## Рәми килгән минем энигә

Бик-бик теләсәм дә, соңга калдым,
Рәхмәт әйтәлмәдем Рәмигә.
Илдә җырлар җыеп йөргән чакта,
Ямадыга кергән, энигә.
Әнкәйдән ул үз улларын сагынып
Язган шигырьләрен сөйләткән.
Безне тибрәтүче бишек җыры
Агылгандыр арган йөрәктән.
Әнкәй дә юк хәзер, Рәми дә юк,
Ә җырлары һаман җылылар.
Миндә генә түгел, Рәмидә дә
Әнкәйләрнең сагыну моңы бар,
Әнкәйләрдән күчкән җылы бар...

## Абыйлы еллар ядкәре

Үземнән өч яшькә өлкән булса да, мин аңа «абый» дип дәшми идем. Хәзер, үзенең юклыгын көннән-көн көчлерәк сизгән саен, аның абыйлыгын, олылыгын тоям.

Безнең балачак авыр сугыш елларына туры килде. Әтиебез — фронтта. Әниебез озак еллар инде авырып ята. Ярый әле безнең бәхеткә зурнәй (дәү әни) бар. Үз өебез булмаганлыктан, без хуҗасыз калган бер иске йортта торабыз. Иртә таңнан торып, икебез чана тартып урманга утынга китә идек. Берничә тапкыр каравылчы тотып, балтаны алып, чанабызны тураклап ыргытты. Аннан якындагы чытырманлыкка зиреккә йөрдек. Колун балта белән Нил абый чыбыкларны сындыра, мин көрткә бата-бата, юлга чыгарам. Каравылчы колун балтаны да «конфисковать» итте. Шуннан без авылдан җиде чакрым ераклыктагы Җырка урманына иярләштек. Март аенда таң алдыннан кар катысыннан барабыз, җылытып кар эрегәнче кайтып та җитәбез. Өйгә кайтып бияләйләрне салгач, өшегән куллар әрни, мин түзә алмыйча, кычкырып елыйм. Абый булгач, Нил түзә инде, яшьләрен күрсәтми, әле мине «елак-мылак» дип үрти дә...

Әтиләр, абыйлар, ирләр сугышта. Колхоз кырында хатын-кызлар, балалар, картлар... Нил абый кыш көне



(Уңнан сулга): Башкортстанның халык шагыйре Рәми Гарипов фәнни экспедиция вакытында минем әнием Шәкүрә янында. 1960 еллар

мәктәптә пионервожатый, җәй көне колхозда бригадир ярдәмчесе. Ындыр табагындагы ашлыкны декабрь аенда суктыралар.

Әдәби иҗат белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башладык. Әнкәйнең тәэсире зур булгандыр. Ул Бөре педагогия училищесын тәмамлаган һәм авырганчы укыткан. Безгә темалар биреп иншалар яздыра иде. Үзебез дә шигырьләр яза башладык. Нил олимпиада смотрларында үзенең шигырьләрен сәхнәгә чыгып укый һәм бүләкләр ала иде. Бервакыт ул «Мунча вакыйгасы» исемле пьеса язды, аны үзләре куйдылар да. Авылны басып алгач, фашистлар мунчага керәләр, партизаннар аларны шунда тар-мар итәләр. Шул ук вакытта Нил район һәм республика матбугатында мәкаләләрен бастыра. Аңардан күрмәкче, мин дә Уфадагы «Кызыл таң»га кадәр үрмәлим. Нил мәктәптә укыганда укытучылар куйган спектакльләрдә дә катнаша иде. Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызыл йолдыз» дигән постановкасында да уйнаганы хәтеремдә калган.

Ул елларда урта мәктәпне тәмамлап чыгуны бик авырлаштырдылар. Ун классны тәмамлаучылар имтиханны район үзәгенә — Яңавылга барып тапшырырга



Тукай-Кырлай, 1986. Тукайның 100 еллыгында абый белән икәү

тиешләр иде. Мәгариф бүлеге мөдиренең ул фәрманын әле дә аңламыйм: ни өчен шундый каты тәртип керткәндер... Ниллар чыгарылышыннан бары тик өч кенә укучыга өлгергәнлек аттестаты бирелде. Шундый каты Яңавыл имтиханнары аркылы миңа да үтәргә туры килде.

Казанның югары уку йортларына безнең Ямады якларыннан беренче юл салучы Нил университетка сынауларны уңышлы узды. Миңа язган хатларында әдәби Казанда ничек кайнавын хәбәр итеп тора иде. Ул минем кызыгуларым, ул минем Казанга талпынуларым! Озак та тормадым, аның артыннан юнәлеп, мин дә татар башкаласының педагогия институтына барып кердем. Укытучы булу теләге юк иде югын, ни өчендер Нил мине шунда керергә өндәде. Университетка керә алмас дип уйлагандыр инде.

Тугызынчы класста укыганда, мин аның янына бардым. Алар безгә туган тиешле Гыйльмия апада өчәү: Нил, Аяз Гыйләҗев һәм Алексей Краснов яшәп яталар иде. Андагы әллә ничә романлык драматик вакыйгаларны мин озак еллардан соң гына белдем. Шуннан соң ул квартирда Илбарис Надиров белән яшәделәр. Бехтерев урамындагы ул агач йортта студентлыкның беренче елында мин дә тордым.

Университетка кергәч, Нил шигырь-хикәяләрен беркемгә дә күрсәтмәде. Аны тәнкыйть өлкәсе үзенә тартты: күрәсең, аңарда аналитик фикерләү сәләте көчлерәк булгандыр. Башта Илбарис Надиров белән, аннары үзе генә Нил бик күп әдәби китапларга рецензияләр бастырды. Тәнкыйди эшчәнлеге аны бөтенләе белән фән юлыннан алып китте. Әмма ул фәндә дә шагыйрь булып калды, элек шигырь язуы юкка гына булмаган...

# Җырлар килгән монда бар дөньядан

Яшьләрнең һәм студентларның республика фестиваленә багышлап үткәрелгән әдәби конкурста минем «Таныш моңнар» поэмасы беренче урынга чыкты. Аның бүләген алган автор буларак мине 1957 елда Мәскәүгә — Яшьләрнең һәм студентларның бөтендөнья фестиваленә җибәрделәр. Ул вакытта миңа егерме дүрт яшь булган икән. Унҗиде яшенә кадәр район үзәге Яңавылдан башка «кала»ны күрмәгән авыл малаена моннан да зуррак бәхет булуы мөмкинме? Бөтендөньяның төрле телдә сөйләүче яшьләре белән очрашу, аңлашу, мөгаен, минем үз милләтем өчен горурлануымны тагын да көчәйткәндер. Юкса без, берничә татар егете, төркемнән аерылып, Мәскәү урамнары буйлап, беркемнән дә уңайсызланмыйча, кимсенмичә, үзебезчә җырлап йөрмәс идек.

Рәхмәт «Таныш моңнар»га: ул мине үзем белмәгән олы дөнья белән очраштырды. Кемнәр белән генә танышмадым, истәлекләр алышмадым! Англиядән килгән яшьтәш кызга авторучкамны бүләк иттем:

«Ул татарча язды «Тынычлык» дип,
Инглизчә дә
«Тынычлык» дип язсын иде ул!..



Бу рәсемдә Татарстан делегатлары арасында минем бәхетле башымны арттагы рәттә ике кыз уртасында күрәсез



Остазларымны юксынганда, мин шушы кадерле рәсемне кулга алам

## *Остазларымны юксынганда...*

Гомеремдәге онытылмас иң гүзәл чорларның берсе Мәскәү белән бәйләнгән.

1957 ел. Илебезнең башкаласында Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелде. Бу олы бәйрәмгә мине дә — егерме дүрт яшьлек егетне дә алдылар. Мондый зур игътибардан каушадым да, горурландым да, үземдә җаваплылык хисе дә тойдым. Мин ул чакта «Таныш моңнар» исемле беренче китабымны чыгарган бик яшь автор гына идем бит. Әнә мин (уңнан беренче) РСФСР Язучылар союзында поэзиябез турында сөйләшүне тыңлыйм. (Сулдан уңга) Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Гариф Ахунов, Әхмәт Фәйзи, Рафаил Төхфәтуллиннар белән бер рәттә булу бәхетнең кабатланмас мизгелләре түгелмени? Поэзиягә җитәкләп алып керүче Сибгат ага Хәким, ышаныч-өмет баглап безгә фатихасын биргән Хәсән ага Туфан, «Флейталар»ы, «Умырзая»сы белән шигырь кыйбласына әйдәгән Әхмәт ага Фәйзи — гомеремдә илаһи мизгелләр бүләк иткән гүзәл затлар булып хәтеремдә мәңге сакланырлар.

# Бер генә җырым калса да...

Бездән алда әдәбиятта исемнәре яңгыраган шагыйрь-әдипләрнең күбесен хәзерге яшьләр белмиләр.

Әйтик, кем ул Сәхаб Урайский?

Мин аны укып та күреп тә белә идем.

Бар иде 50 нче елларда Урайский дигән шагыйрь. Фронтовик. Журналист. Нәшриятта редактор. Чын фамилиясе — Мәүлетов. Кушаматын туган авылы Урайдан алган. Сембер мишәре.

Мәктәптә укыганда мин шигырьләремне Уфага да, Казанга да юллый идем. Җавап хаты килгән көн — минем өчен бәйрәм — үзең укыган китапларның авторы Гариф Гобәйдән хат килсен әле! Казаннан беренче хатны мин Язучылар союзы консультанты Оркыя Гыйззәтуллинадан алдым. Бик озын рецензия язып, шигырьләремнең басарга яраксыз икәнен исбатлаган. Әмма барыбер бирешмим. 1949 елны Казанда «Яшь сталинчы» газетенең яңадан чыга башлавын ишетеп, шигырьләремне шунда җибәрдем. Җавап хатын шагыйрь Сәхаб Урайский язган. Бер генә түгел, әллә ничә хат алдым мин аңардан. Һәрберсендә бер үк җөмләләр кабатлана: «Каләмегез шома күренә. Әмма болары басылырлык түгел. Язгалап торыгыз. Сәлам белән С.Урайский». 1950 елны Казанга институтка укырга килгәч, Урайскийның эш бүлмәсенә, «Яшь сталинчы»га кердем. Сөйләшүе дә гади генә, тәмәкене дә безнең авыл агайлары кебек беткәнче тарта, киеме дә шагыйрьләрчә түгел, югыйсә шигырьләрендә «якты еллар» да «бәхетле тормыш»... Соңыннан мин аның еш кына акча җитмәүдән, балалар күплектән зарланганын ишеттем. Коридорга тәмәке тартырга чыккач: «Хатынның итәгенә кагылыр хәл юк — балалар коелып кына тора»,— дип, моңсу гына шаярып та алды. Шигырьләре белән үз тормышын чагыштырып карыйм да, кайчак: «Бәхетлеме соң Сез?»,— дип сорыйсым килә. Әмма сорарга ярамаганны тиз аңладым, үземне дә шулай язарга, шигырьләрнең ахырын «рәхәт тормыш өчен юлбашчыбызга рәхмәт!» дип тәмамларга өйрәттеләр.

Бу чор шагыйрьләренең аянычлы язмышын мин соңыннан гына аңладым: алар социалистик реализм кысала-

рында иҗат итәләр бит. Күпмесе шул методның корбаны булып, талантларын тулысынча ача алмыйча, киләчәктә укый алырлык әсәрләрен калдыра алмадылар диярлек. Сәхаб абый әнә шул кызганыч хәлләрен аңлагандыр инде, Нур Гайсин турында: «И Нур Гайсин, Нур Гайсин, очалмаган тургай син!» — дигән эпиграмма чыгарган, диләр. Нур Гайсин да аптырап калмаган: «Урайский, син үзең дә шулай бугайский!» — дип җавап биргән, имеш.

Ул чорда Шәйхи Маннур кебек шактый талантлы шагыйрьләр дә шулай көчләрен әрәм иттеләр. Мин әле Шәйхи абыйның нефтьчеләр тормышына багышланган «Җир-Әнкәнең сылу кызы» исемле дүрт мең юллык поэма язганын хәтерлим. Аралаш рифма белән! Китап булып чыккач, берәрсе укып чыга алды микән аны... Хәзер бу язманы белүче дә юк. Ярый әле Шәйхи абый иҗатының соңгы чорында шигъри талантын прозага җикте һәм менә дигән прозаик булып танылды. Ярый әле безгә — әдәбиятка алардан соңрак килгәннәргә заманның иркенлек җилләре исте.

Әмма барыбер ул чор язучыларының кыюраклары, талантлыраклары, үзләрен очалмаган кош хәлендә хис итсәләр дә, шул заманның классик әдәбиятын тудырдылар.

Сибгат абый Хәкимнең: «Үземнән соң бер генә җырым халык күңелендә калса да — мин бәхетле»,— дип әйткәне исемдә. Аллага шөкер, аның шигырьләре дә, җырлары да яши.

Башкортстан композиторы Мәсәлим Вәлиев шагыйрь Зыя Ярмәкине «Аккаен» җыры белән мәңгеләштерде. Күңелләрне әсир итәрлек көй чыгарып, шагыйрьне бер җыры белән булса да яшәтүче композиторларга рәхмәт!

Сәхаб абый да бәхетле: аңардан Мансур Мозаффаров иҗат иткән гүзәл бер җыр калды: «Син кайтмадың».

«Аккош китәр урман күлләреннән,
Син китмәссең минем күңелемнән...» —

дигән җыр юлларын тыңлаганда, мин «Таныш моңнар» исемле беренче китабымның редакторы булган өлкән шагыйрьне олылап искә төшерәм.

Юк, очалмаган тургай гына булмаган Сәхаб абый, күңеленнән аккошлар да очырган...

# Тынчы Мәхмүт

Мәхмүт Хөсәенне соңгы тапкыр язучылар йортында очраттым. Мәрмәр баскычлардан төшкәндә туктаган да башын иеп уйга калган. Сагышлы халәтеннән аерырга теләмичә, мин аны читтән карап тордым. Уйларыннан бүлеп исәнләшкәч, моңсу гына: «Җитмеш яшемне үткәрү алдыннан хастаханәгә кереп чыгам әле, юбилеема алдан ук чакырып куям»,— диде. Әмма юбилеенә килеп җитә алмады, мәрхүм.

1983 елда универсам ресторанында алтмыш яшен билгеләгән идек. Мин шигъри тост әйттем:

Бер карыймын: син — сабый,
Бер карыймын: син — абый,
Бер карыймын: син — бабай,
Бер карыймын: син — малай.
Бер карыймын: син — акын,
Сәсәннәргә бик якын.
Запастагы артиллерист,
Һаман да туп атасың,
Дошманны да, дусларны да
Үзеңә каратасың,
Шушы яшеңә җиткәч тә,
Кызларны яратасың.
Юбилейный мактауларны
Шул урында туктатам,
Артиллерист булмасам да,
Бакчаңа бер туп атам:
Син ярату гына җитми,
Кызлар сине сөйсеннәр,
Йөз яшьтә дә яшь-яшь кызлар
«Мәхмүт җаным!» дисеннәр.
Хуплар идек, Такташ белән бергә,
Ярым ачык калган ишектән
Бер кызыйның:
«Мәхмүт бәгърем, җибәр!..» —
Дигән тавышын да ишетсәк...

Янымда утырган алып гәүдәле Нури Арслан, ризык тулы өстәлне селкетеп көлде. Мәхмүт үзе елмаеп кына куйды. Юан гына, йомры гына шагыйрьнең хатын-кызларга мөнәсәбәте бик нечкә иде. Ике тапкыр өйләнгән Мәхмүт әллә үзе алардан уңмады, әллә алар аңардан уңмады... Кырык китап чыгарып та язучылар оешмасына алынмавының бер сәбәбе, бәлки, шул булгандыр. Хәсән Туфан яратмый иде Хөсәенне. Үзен дә, шигырьләрен дә. Чыгышла-



Мәхмүт Хөсәен белән Красный Ключ пионер лагеренда. 1962

рында аны гел кире яктан мисалга китерә иде. Абсолют саф кеше буларак, Хәсән абый башкалардан да шулай булуны таләп итә иде. Ә Мәхмүтнең нечкә күңеле вакытвакыт өзелеп китә һәм союзга кабул итәргә җыенганда гына, ул ниндидер «гөнаһ» эшләп куя иде. Бүгенге күзлектән караганда әлләни зур гөнаһлар да түгел инде югыйсә. Ул вакытта язучылар әгъзасына таләп икенчерәк иде шул.

Иң күп тәнкыйтькә эләккән шагыйрьләрнең берсе — Хөсәен. Күп яза иде. Гәзитләр заказын бик тиз үтәп, чүп тә яза иде. «Заводлар өчен кирәк металл, читән үрергә кирәк чи тал» кебек тезмәләреннән рәхәтләнеп көлә идек.

Аудым командировкада,
Градусым кырык чамасы.
Больницага илтеп куйды мине
Киң табанлы колхоз чанасы,—

дигән җитди шигырен пародия урынына сөйләп йөрдем. Үзенә дә үз тавышы белән сөйләп күрсәттем. Әмма Мәхмүт үпкәсен белдермәде. Ул мондый гына туры атуларны сугышта да, тәнкыйть фронтында да күп күреп, тәмам чыныгып беткән иде инде.

Артиллерист Мәхмүт сәхнәгә үзе дә туп шикелле тәгәрәп менә иде, соңгы көннәренә кадәр шуннан төшмәде һәм шигырьләрен артистларча сөйләве белән популяр шагыйрьгә әйләнде. Шигырьдә дә тынычлык дошманнарына

ерактан атты, тидерә алгандырмы, юкмы, анысы икенче мәсьәлә. Татар яшәгән кайсы гына төбәккә барма — анда Мәхмүт Хөсәен шигырь сөйләп киткән, аны белмәгән кеше юк. Аның белән бергә чыгыш ясаган шагыйрь нинди генә әйбәт шигырь укымасын, Хөсәеннән соң алкышлар алалмый. Мәхмүт сәхнәне ялгызы биләп калды һәм хаклы рәвештә эстрада шагыйре дигән исемне яулады.

Мәхмүт халык алдында үзен зур шагыйрь итеп күрсәтә дә белә иде. Очрашуга барыр алдыннан өлкә комитетка керә, фәлән районга шагыйрь Мәхмүт Хөсәен бара, тиешле дәрәҗәдә каршылагыз, дип хәбәр иттертә. Бөтен район, шәһәр шаулый: «Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен килә!» Анда баргач, әлбәттә, беренче секретарь белән генә эш итә. Сәхнәгә менгәч, ул инде Кара диңгездәге кебек йөзә. (Чыннан да, ул диңгездә шәп йөзүе белән иҗат йортындагы язучыларны шаккатыра иде.) Әнә шулай Мәхмүт җитәкчеләрне язучыны ничек кабул итәргә өйрәтте. Безнең артыгы белән тыйнак әдип-шагыйрьләребез аның бу галәмәтләрен бик өнәп бетермәделәр. Бәлки, аның шигырьләренә мөнәсәбәт кыркурак булгангадыр.

Үзенә төбәп күпме генә туплар атылса да, Мәхмүт кире чигенмәде. Соңгы дәвердә ул үзенекен генә түгел, башка шагыйрьләрнең шигырьләрен сәхнәгә мендерде. Үзен яратмаган Хәсән Туфанның шигырьләрен дә аеруча яратып, зурлап халыкка җиткерә иде.

«Халык мәхәббәте лауреаты
Сөеклебез Салих Сәйдәшев! —

дип, үз заманында Мәхмүт Хөсәен әйткән иде. Бу сүзләр хәзер бөек композиторыбызның музеена пароль кебек язылган.

Гомеренең соңгы елларында ул Дәрвишләр бистәсендәге фатирында яшәде. Мине дә кунакка дәшкәләде. Бары тик шигырь турында гына сөйләшә идек.

Казакъ далаларында туып, Казанда күкрәп яшәгән, сәхнәләрне шигырь белән нурландырган шагыйрь Дәрвишләр бистәсе туфрагында ята.

Җиде төн уртасында уятып яңа шигырен тыңларга мәҗбүр иткән шагыйрьнең җанлы рәсеме һаман күз алдымда.

Мәрмәр баскычлардан төшеп килгәндә тукталган да тирән уйга калган...

## Икебез дә Яңавылдан, Дуртебез дә Ямадыдан...

Без өч зур милләтнең: татар, башкорт һәм урыс әдәбиятлары йогынтысында тәрбияләндек. Минем республика күләмендә беренче шигырем башкорт телендә чыга торган «Әдәби Башкортстан» журналында дөнья күрде. Башкорт язучылары белән гомер буе туганлашып, дуслашып яшәдек. Мәгълүм тарихи сәбәпләр аркасында күпләренең паспортында «башкорт» дип язылса да, райондашлар үзләрен татар дип санныйлар. Берәүләр Уфа югары уку йортларына китеп, шунда төпләнеп калалар, республикага танылган шәхесләр булып китәләр. Яңавылдан киткән Радик Гәрәев җырчы буларак дөньяга танылды. Безнең районда туган Гайнан ага Әмири башкорт әдәбиятының күренекле язучысы булып китте. Нурихан Фәттахны, Нил абый белән мине Тукай, Такташ Казаны күбрәк тарткандыр инде, без әдәбият Казанына юнәлдек. Шуңа карамастан башкорт дусларыбыз белән аралар беркайчан да суынмады.

Моннан утыз еллар элек Башкортстан телевидениесе татар-башкорт әдәбиятларының дуслыгына багышланган тапшыру оештырган иде. Экранга безне Гайнан ага Әмири белән чыгардылар.

— Илдар кустым, менә мин башкорт шагыйре, синең белән рәхәтләнеп башкортча сөйләшеп утырам. Син мине тәрҗемәсез дә яхшы аңлый торгансыңдыр бит? — ди агаем.

— Нишләп аңламаска,— дидем мин,— икебез дә Яңавылдан ич!

Бу диалогны соңыннан мәзәк итеп сөйләп йөрделәр.

Әмма соңгы елларда хәлләр җитди төс алды. Башкортстанда яшәүче миллионнан артык татарларның теленә башкорт һәм рус телләре белән бергә дәүләт статусы бирелмәде. Әлегә аның үз телендә чыгучы «Кызыл таң», «Өмет» газеталары, «Толпар» журналы, «Нур» театры бар. Үзләренең әйтүләренә караганда, матбугат органнары хәзер үк кыенлыклар кичерә. Татар мәктәпләрен башкортчага күчерү тәҗрибәсе яңадан калкып чыкты. Мин моның ни белән тәмамланасын күз алдына китерәм: баш-



Барыбыз да Яңавылдан

корт телен белгән укытучы кадрлар җитмәү сәбәпле, ул мәктәпләрне рус телендә укытуга күчерәчәкләр.

Сталин заманында да татарча укытылган Ямады урта мәктәбеннән Рәдиф Тимершин, Нил һәм Илдар Юзеев, рәссам Эрот Зарипов чыгып, әдәбият-сәнгатькә юл алдылар.

Шундый сәясәт дәвам итсә, без укыган мәктәптән киләчәктә ни татар, ни башкорт, ни урыс язучысы чыкмастыр...

## Ул безне җырлатып яшәтте

Гомерем буе композиторларга сокланып, аларны ихтирам итеп, илаһи серле затлар күреп яшәдем. Халыкны җырлатып-биетеп, сагышландырып, тирән уйларга салып, өметләндереп яшәтүче иҗат кешесеннән дә бәхетлерәк кеше бар микән?

Шундый гаҗәеп шәхесләрнең берсе Сара ханым Садыйкова иде.

Иҗат ителгән беренче җырлары белән үк ул халык күңеленә юл салды. Илленче елларда без яратып җырла-

ган «Мин сине көтәм» җырын гына искә төшерик. Ул көй яшен-картын җырлатты да, биетте дә...

«Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине көтәм, һаман көтәм...»

Халкыбызны рухландырган оптимистик бу сагыш шул чорның музыкаль ядкәре булып күңелләрдә һаман яши.

Соңрак, Казанга килеп, иҗат кешеләре арасында кайный башлагач, миңа Сара апаның үзе белән дә якыннан танышырга туры килде.

1958 елда Татарстан китап нәшрияты минем «Тау чишмәсе» исемле шигырьләр җыелмасын басып чыгарды. Анда «Кайтам инде» дигән шигырем дә бар иде. Бер көнне мин эшләгән «Ялкын» журналы редакциясенә Сара апа үзе килеп керде. Туп-туры минем янга килде дә:

— Илдар, мин сезнең бер шигырегезгә көй яздым. Музыка таләп иткәнчә, бераз үзгәртә алмассыз микән? — диде. Шунда ук җырлап та күрсәтте. Әлбәттә инде, шунда ук бергәләп үзгәрттек. Озак та үтмәде, җырны мәшһүр җырчылар башкардылар. Ул популяр җырларның берсенә әверелде.

Тора-бара мин Сара апаның поэзия яратуын, һәрбер шигырь китабын укып баруын, үзенә ошаган сүзләргә генә җыр язуын төшендем. Сара апа күңеленә яраган шигырь бәхетле ул, канатланып, җыр булып халыкка китә.

1970 елны Татар дәүләт республика күчмә театры минем «Бөркетләр кыяга оялый» комедиясен куярга ниятләде. Баш режиссер Равил Тумашев белән киңәшеп, музыка язуны Сара ханым Садыйковадан үтендек.

«Пьесаны укымыйча вәгъдә бирә алмыйм»,— диде Сара апа. Икенче көнне үк язарга ризалыгын бирде. Һәм бик тиз вакыт эчендә спектакльгә җырлар язып, безгә уйнап күрсәтте. Композиторның якты сагышлы, җиңел агышлы музыкасы тамашачыны битараф калдырмады, алар спектакльне дә яратып карадылар. Шулар арасыннан берсе — «Бөркет турында баллада» бәхетле язмышка очрады — спектакльдән соң да мөстәкыйль тормыш белән яши башлады. Ул әле дә җырчыларыбызның репертуарында.



«Бөркетләр кыяга оялый»

Сара апаның очрашканда: «Яхшы шигырең булса, миңа бир, тик яхшы булсын»,— дигән сүзләрен искә алып, «Чит илләргә чыксаң» дигән җырымны аңа тапшырырга батырчылык иттем. Бу шигырьне мин Әлфия Афзаловага багышлаган идем. Финляндиягә баргач, Әлфиягә: «Китмә, бездә калып җырла»,— дип әйткәннәр, имеш... Фикере шуннан туды.

Иҗат иткәнен үз күзләрем белән күрмәгәч, мин Сара апаны бик җиңел һәм тиз яза дип уйлый идем. Бу юлы ул, үзенең әйтүенә караганда, озак эзләнгән һәм иҗат газаплары кичергән. «Хәзер җырның җиде-сигез варианты бар, менә соңгысын тыңлап кара»,— дип, ул телефон аша үзе уйнап, үзе җырлап та күрсәтте. Авыр табылган бу җырны җиренә җиткереп, үзәгенә төшеп, Флера Сөләйманова һәм Айдар Фәйзерахманов җырлый.

Композиторлар союзында ул вакытта партия оешмасы булмагандыр инде, Сара апа Татарстан Язучылар союзының партия оешмасында исәптә тора һәм һәр айны җыелышка килә торган иде. Аның яшьләрчә кайнар, җырлары сыман тирән хисле чыгышларын һәммәсе дә кызыксынып тыңлыйлар. Тәнәфес игълан ителгән чакларда сәхнәгә йөгереп менә, пианино янына утыра да: «Менә яңа җыр яздым, тыңлап карагыз әле»,— дип, бар-

макларын клавишларда биетә башлый. Гомумән, Сара апа язучыларны бик хөрмәт итә, ярата, әдипләр дә аны үз кешесе итеп тоялар иде.

Ни өчендер талантлы популяр композиторны озак вакытлар Композиторлар союзына алмыйча, читләтеп йөрделәр. Янәсе, устав нигезендә, член булу өчен консерваториянең композиция бүлеген тәмамлау мәҗбүри икән. Идарәнең элекке составы күп еллар шушы фикерне алга сөрде. Әмма халыкны җырлатып, рухландырып яшәтүче композиторның зур иҗаты уставтан чигенергә мәҗбүр итте. Яңа идарә Сара Садыйкованы рәсми рәвештә дә композитор итеп таныды.

Гомеренең соңгы елларында Сара апа әллә чынлап, әллә шаярып, үзе белән булган бер вакыйганы сөйләде. Көне-төне акылдан шашып пианино янында утырган, «бер минут та тынычлык бирмәгән композитордан» котылырга теләп, күршесе психо-неврология больницасыннан машина чакырта. «Килеп керделәр берзаман гренадер кебек ак халатлы ике егет,— ди Сара апа,— мине алып китмәкче булалар. Мин композитор, Сара апагыз... Мине тыңлап карагыз, яңа көй яздым»,— дип уйнап җибәргән идем, егетләрем телсез калдылар. Рәхәтләнеп музыка тыңлагач, гафу үтенеп чыгып киттеләр...»

Шушы вакыйга мине «Сөйгәнемнең туган көне» исемле трагикомедия язарга этәрде. Бу хакта Сара апаның үзенә әйткәч, рәхәтләнеп көлде дә: «Музыкасын үзем язармын»,— дип куйды.

Әмма ул спектакльгә музыканы язарга өлгерә алмады...

## Атнабайлы еллар ядкәре

Яңавыл районының Ямады урта мәктәбендә укыганда Нил абыема ияреп мин дә шигырьләр яза башладым. 1943 елда район газетасында «Нил һәм Илдар Юзеевлар иҗаты» дигән зур исем астында икебезнең шигырьләребез басылып чыкты. Мин ул вакытта өченче класста укый идем. Бердәнбер көнне өебезгә озын буйлы, чәчләрен Такташка охшатып үстергән бер абый килеп керде. Газетадагы шигырьләре аша таныш булган Атнабаев икәнен белгәч, башларыбыз күккә тиде. Кульязма әдәби жур-



Минем юбилей көннәре. Сулдан уңга: Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин, Венера Ихсанова, Илдар Юзеев; икенче рәттә: Ризван Хәмид, Марат Кәримов, Шәүкәт Галиев, Ренат Харис, Габдулла Шәрәфи. 1983

нал чыгаручы, үзе шагыйрь, үзе рәссам, үзе түгәрәк җитәкчесе Атнабаев Әнгам үзе! Безне эзләп килгән. Шигырь, хикәяләребез белән үзе оештырган «Яшь пионер» дигән журналында катнашырга чакыра. Үзе яшәгән Күрдем авылы да бездән унике чакрым гына икән. Ул бездән сорашып, шигырь җене кагылган авылдашларыбызның да исемнәрен язып алды. Соңыннан ул безнең барыбызны Һади Такташ исемендәге әдәби түгәрәгенә кушты, ике районның берләшмәсенә әйләндерде. Икенче килүендә ул инде берләшмәнең Ямады авылындагы күчмә утырышын уздырды. Беренчесен безнең мунчада үткәрдек. Уены-чыны бергә: агачтан ясалган мылтык тотып, чиратлашып постта торабыз: үзебезне шигырь дошманнарыннан саклыйбыз. Бер-беребезнең шигырьләрен укыйбыз, җитәкчебез безне ничек шигырь язарга өйрәтә, кимчелекләребезне дә әйтә. Әйбәтрәк табылганнарын алып китә дә журналында бастыра. Ул чыгарган журналны күргәч, мин шаккаттым, үзе ясаган матур рәсемнәр белән бизәлгән, хәрефләре китапныкыннан ким түгел! Әнгам «Яшь пионер» журналын берничә ел чыгарды. Мәскәүдә «Пионерская правда» газетасы үткәргән

конкурста катнашып, беренче урыннарның берсен яулап алды. Әмма шунысы: журналларын кире җибәрмәгәннәр, ул шуңа бик борчылган иде. Менә шулай безнең чын әдәбиятка килүебез уеннан башланды. Әнгамнең һәм безнең кумирыбыз Һади Такташ әйтмешли:

Кем уйласын шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип...

Ул елларда Әнгам Күрдем мәктәбендә пионервожатый булып эшләде. Әдәбиятта безнең дә вожатыебыз иде.

Без тормышта Әнгам белән бергә озак еллар буена авыр чакларда бер-беребезне коткарып юбилейларны бергә бәйрәм итеп яшәдек. Телефоннан сөйләшеп тә, хатлар язышып та сагынуларны киметә идек. Менә аның Яңа ел белән котлау шигыре:

*«Ел артыннан еллар ага,*
*Ярларда таллар кала.*
*Башын игән таллар кебек,*
*Чәчләрдә чаллар кала.*
*Чәчебездә чал калдырган*
*Елларның колымы без?*
*Шул елларны йөгәнләгән*
*Заманның колымы без?*
*Колы булмасак иде лә,*
*Ә кулы булсак иде,*
*Чәчләрдәге чаллар кебек,*
*Елларга кунсак иде.*

*Өр-яңа иҗат елы, саулык теләп: Ә.Атнабай. 25.12.77»*

Үзем шушы юлларымны язып утырам, үзем телефоннан сөйләгән тавышын ишетәм, бөтенләй янда гына кебек, ә шул вакытта мәңгелектән салкын ят тавыш пышылдый: «Әнгам юк бит инде, юк...» Ах, Әнгам, суга баткан кебек югалдың шул... Сизми калдык, коткара алмый калдык. Әҗәл кулларыннан беркемне дә йолып калып булмый шул. Ә үзең син шигырьләрең белән күпме рухи батучыларны коткардың. Юк, син үзең дә аларның күңелендә, миллионнар җанында яшисең, сине үз әсәрләрең мәңгелеккә бөтенләй батудан коткарды. Сине киткән дип уйлаучылар авыр хәсрәттән соң җиңел сулыш алып әйттеләр:

Ул кайтты!

*29 июнь, 2000*

# Атнабай хатлары

## Беренче хат

*«Хат башы, яз каршы!*
*Сагынычлы хат башларын*
*Яза перо һәм каләм.*
*Дустың Әнгам һәм Кирамнан*
*Сиңа ялкынлы сәлам!*
*Җырлый-җырлый аккан Гәрә*
*Һаман шулай агамы?*
*Әтәң, инәң һәм апаең (монысы мин булам)*
*Исән генә торамы?*
*«Начар язганнар» димәгез,*
*Бозык булды шул пером.*
*Шушы хатны язучылар*
*Әнгам дустың һәм Кирам.*
*Сагынудан хат язабыз*
*Утыз тиенне түләп,*
*Сталинның портреты*
*Әнгамнән сиңа бүләк.*
*Менә, иптәш Нил дускаем,*
*Шундый план корабыз:*
*Бик зур гына шигырь уйлап*
*Язарга дип торабыз.*
*Гәрә буйлап агып килә*
*Кыска гына бер салам.*
*Синең энең Илдарга да*
*Бездән ялкынлы сәлам!*
*Басуларга ашлык чәчтем*
*Саклар өчен орлыкка,*
*Син дә безгә хат язгала,*
*Китте диеп онытма.*
*Их, дускаем, иптәшкәем,*
*Син безгә кунакка кил.*
*Сүзләремнең азаккысы,*
*Гаепләмә, дустым Нил.*
*Шушы хатны яза-яза*
*Талып бетте инде кул.*
*Рәхәт яшә мәңге-мәңге,*

*Бездән теләк сиңа шул.*
*Гәрә суы буйларында*
*Үсә микән җир җиләк?*
*Дуслыкларны онытмыйча,*
*Хат язышу бик кирәк.*
*Нил дускаем, сезнең якка*
*Текәп карыйм күземне.*
*Сәлам әйтеп, хатлар язып,*
*Тәмам итәм сүземне.*

*Язучы: Атнабаев.*
*Карап утыручы: Кирам.*
*Башкирия, Янаульский район, деревня Ямады,*
*Юзееву Нилу или Ильдару*
*Татышлинский район, Сараштыбашевск с/совет,*
*деревня Ст.Курдым.*
*От Ангама Атнабая».*

## Икенче хат

*«Нил һәм Илдар!*

*Атнабайдан ялкынлы сәлам!*

*Дөрес, сез үпкәләгәнсездер, чөнки мин сезгә күп вакытлардан башлап хат яза алмадым. Минем соңгы вакытларда вакыт булмады. Тик шул сәбәпле генә мин сезгә хат яза алмадым. Аның өстенә Күрдемдә аз булырга туры килде. Яңавылга бардым, Тәтешледә заочно укыдым, пионерлар лагеренда бер ай. Менә шулай вакыт дигән нәрсә җитми дә кала. «Яшь пионер» журналын да регулярно чыгарып булмады, ләкин калган номерлар артыннан куып җитәрмен әле, дип уйлыйм.*

*Сезнең әдәби эшләр ничек соң? Әниегезнең сүзләренә карап, әллә әдәбият белән шөгыльләнүне куеп торасызмы? Болай эшләсәгез, бик-бик начар. Чөнки сезнең икегездә дә талант бар. Ул талантны үстерергә, баетырга һәм ныгытырга гына кирәк. Әгәр язган әсәрләрегез булса, зинһар, миңа җибәрегез әле, үземнең дә танышасым килә, шулай ук «Яшь пионер» да материал сорый. Ямадыдагы башка иптәшләрегезгә дә шул «зинһар»ны җиткерегез. Материалларыгыз бишьеллык план турында, укучыларның җәйге ялы, хезмәте, Ва-*

*танибыз кырларында барган бөек төзелешләр, хезмәт батырлыклары, яңа уку елына хәзерлек барышы, үзегезнең районда, авыл советында, авылдагы үзгәрешләр турында булсын. Гомумән, нинди яңа нәрсәләрегез бар, җибәрегез.*

*Әтиегез өйдәме, әниегез нихәлдә, әбекәй нишләп кенә йөри соң әле? Аларга сәлам! Сагынам мин сезнең семьягызны. Печән, утын хәзерләдегезме?*

*Нил, лагерь тормышыннан берәр нәрсә язып җибәр. Ул турыда мин бик кызыксынам һәм синнән җавап алырмын дип ышанам.*

*Илдар (кечкенәм минем!), җәйне ничек үткәрәсең, күңелсез түгелме, шигырьләр язасыңмы? Минем дә укыйсым килә ул шигырьләрне.*

*Хат көтәм. Йә, сау булыгыз, минем кечкенә дусларым!*

*Эшегездә бөек уңышлар теләп: Атнабай.*

*31 июль, 1946 ел. Күрдем».*

## Өченче хат

*«Яшь пионер» журналы каршында оештырылган шигырь, рәсем һәм хикәяләргә конкурсның II премия*

*Мактау грамотасы*

*«Салют», «Краснодон геройлары» исемле шигырьләре һәм «Гвардеец» исемле хикәясе өчен Ямады урта мәктәбе 6 нчы класс укучысы Юзеев Нил Гафуровичка бирелә.*

*Конкурс комиссиясе председателе: Атнабаев.*
*Членнары: (имзалар).*
*Алучы: (имза).*

*Бирелү вакыты: 20 февраль, 1944 ел.*

## Сак-Сок

### *(Атнабайның туган көнендә укылган шигырем)*

Бәет әйткән бабайларны
Бүген искә алыр чак.
Балачактан бертуганнар:
Күрдем — Сок, Ямады — Сак.
Авыллар якын иде бит,

Нигә без ерак булдык:
Әнкәбез дә каргамады,—
Нигә Сок һәм Сак булдык?
Милләтебез язмышына
Без, ахрысы, тап булдык.

Казаны да, Уфасы да —
Безгә туган як бит ул.
Уфа үзе Сок булса,
Казан үзе Сак бит ул.
Сәяси максат аерган,
Мин — Сак, ә син — Сок булдык.
Эчебез тулы ут булса да,
Тыштан — шаян, шук булдык.
Бала чаклар — үзе бәет...
Бер-беребезгә сак булдык.
Яшьлектә гөнаһлар да бардыр,
Әмма Җырда саф булдык.
Бабайларның рухлары да
Бүген разый, хуш булсын,
Туганлыкны аерып торган
Киртә-чикләр юк булсын.
Язмыш ялгышын төзәтик:
Бәхетле Сак-Сок булыйк,
Картлык көнендә булса да,
Әйдә, Әнгам, кушылыйк!

*1998*

## Үзенә үзе кокем чыгарган...

Басылган әсәрләремне кабат кайтып барлаганда: «Фәлән кадәр китапларым чыккан!» — дип мактанасым килеп китә дә, әйбәт кенә әсәрләр калдырган мәрхүм Әнәс Камал күз алдына килеп баса. Ул, сыра эчеп алгач, градусы чыгып беткәнче дип (башка вакытта оялчан кеше иде), элек үзе эшләгән Язучылар союзына йөгерә. Каршына кем очрый, шуның юлына аркылы төшә. Яшь авторлар белән эшләү бүлеген җитәкләгәндә, минем үземә дә яратып кына бәйләнгәне бар:



(Сулдан уңга): Әнәс Камал, Илдар Юзеев, Әнәс Камалның кызы Диләрә, аның ире Рәис Даутов. 1956

— Менә мин, Галиәсгар Камалның баласы Әнәс Камал, кырык еллык иҗат гомеремдә кырык пьеса яздым! Кыяфәтсез тәре, син ничә пьеса яздың?! Эйзенхауэр (ул чактагы Америка президенты) ничә пьеса язган?! («Ачуланып әйтмим, шаярам» дигән кебек, бер мизгелгә елмаю билгесе дә күрсәтеп ала.)

Дөньядан китәренә берничә ай калгач, мин Әнәс абыйның өенә хәлен белергә бардым. Ул, үз-үзе белән сөйләшкән кебек, миңа карамыйча гына, сүнә барган карлыккан тавыш белән ярды да салды:

— Әйтте миңа Галиәсгар Камал: «Маташма, Әнәс, барыбер синнән драматург чыкмый»,— дип... (Хәзер «Ә мин кырык пьеса яздым!» дип мактана башлар дип торганда, кыска гына монологына нокта куя.) И... чыкмады!!!

Гомер йомгагында үзенә-үзе шундый аяусыз — рәхимсез хөкем карары чыгарган башка кешене мин белмим.

Без үзебезгә нинди хөкем чыгарырбыз?

Барысы да алда әле...

# Йөрәккә язылган яшел сүзләр

Бөек остазым Хәсән Туфан белән очраштырган елларга рәхмәт укыйм. Ул минем шигырьләремне, поэмаларымны игътибар белән күзәтеп барды. Миңа гына дип әйтмим, сәләтле күренгән һәрбер яшь авторга киңәшләр бирде, дәртләндерде. Олуг шагыйрь минем иҗатым турында «Алгы сафтагы шагыйрь» дигән мәкалә дә язды.

Остазым мине гел мактап, баштан сыйпап кына торган икән дип уйламагыз. Хәсән абый миңа карата вакыты белән бик таләпчән дә иде. 1971 елны, мин Мәскәүдә югары әдәби курсларда укыганда, «Карурман» поэмасын тәмамлагач, ул кульъязма белән танышып, хат җибәрде. Фикерләрен искә алып поэманы яңадан төзәттем. Хатны сезгә дә тәкъдим итәм.

*«24.11/71. Казан.*

*Кадерлебез Илдар!*

*Хатыңны — сәламеңне алдым. Рәхмәт.*

*Быелгы «К.У.»дагы («Казан утлары»ндагы) шигырьләрең өчен дә рәхмәт. «Хушыгыз», «Бәрәңге чәчәге», «Заман агышыннан...», «Балачакка кире кайтыйм әле», «Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп», «Шагыйрьләр нигә картаймый?», «Дуска» һәм «Иптәшләре җәза бирделәр дә...» кебекләр — аерата нык дулкынландыра торган җан азыклары алар.*

*Безнең олы буынны, Илдар, сезнең бар булуыгыз тынычландыра: әгәр дә көтмәгәндә-уйламаганда китеп барсак та, барыбер иманлы, гамьле дәвамнар бар, юл өзелмәячәк бит! — дип ышанабыз. Шуңа күрәдер, синең бу әсәрне күздән кичергәндә, форсат барында әйтеп кую яхшы булыр дип, шигырьнең кайбер ритмик яклары турында да кайбер карашларымны әйткәләп үттем. Алар мәҗбүри түгел — менә шулай итү яхшырак булмасмы дигән киңәшләр генә.*

*Бу әсәрең — «Карурман»ың исә — уйландыра, әле дә уйландыра. Темаң җитди һәм актуаль. Дөнья гуманистларының күбесе табигатьне коткарып калу турында фикерләшәләр. Шагыйрь дә бу мәсьәләдә бер читтә, битараф мәйданда кала алмый, билгеле.*

*Әйтергә теләгәнең, дөресе — әйтми калырга мөмкин булмаган сүзең (фикерең-хисең) — асылда, ул синең има-*



(Сулдан): Г.Паушкин, Х.Туфан, Ш.Галиев, И.Юзеев, А.Расих. 1979

*ның. Иман исә ата шайтанга да бирелмәскә тиеш. Иман чигенү белән юлдаш була алмый. Димәк, үзең ышанып җиткән идеяңне-иманыңны шигъри чаралар белән расларга тиешсең. Синең бу әсәрдә исә үз фикереңә иманың камил үк түгел кебек тоела. (Беренче кат укулардан түгел, күп тапкырлар укыгач, уйлана торгач кына шундый карашлар туа башлады миндә.)*

*Әсәр космополит «физика» белән мәңгелек лирика бәрелешеннән, «физика»ның коры, гамьсез «физика»ның бабайдагы лирик хисләргә төкереп кенә, мыскыл итеп кенә каравыннан башлана кебек иде. Лирик геройның, авторның тел төбе — лириканы (бабайдагы гүзәл хисләрне) инкарь иткән булып (ирониялəгән булып), космополитик карашларның үзләрен көлкегә калдыру телəгенә юнәлтелгән кебек иде. Ләкин лирик герой «шайтанның» аңа бирәчәк репликаларына, бәйләнергә әзер булуына колак сала.*

*Төзәтүләр, үзгәртүләр аңа («шайтан»га) ташлама ясауга түгел, ә бары иманыңны төгәлрәк, көчлерәк, ачыграк итеп әйтүгә юнәлсен иде.*

*Әсәрнең старты дөрес сызыктан — космополитик карашларны сүтүдән башлана.*

*Әсәр әле гөмбәзе очланмаган бина кебек булып тоела. Гөмбәздә иманың байрагы (төп ниятең) җилфердәми кебек әле.*

*Хәким бәйрәме көннәрендә Казанда булырсың бит. Монда әйтелми калганнарын шунда — үзең белән очрашканда әйтермен.*

*Абыйлар сәламе белән: Хәсән».*

## Бар иде шундый шагыйрьләр...

Илленче елларда «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасының җаваплы редакторы шагыйрь Гали Хуҗи иде. Фатих Кәримгә багышланган «Гражданин, солдат, шагыйрь» исемле, ул заман өчен әйбәт поэманың авторы. Ул эшләгән чорда газета яшь авторларның үзәгенә әйләнде. Беренче тапкыр Гали абый кабинетына студент чагымда барып керергә җөрьәт иттем. Кулымда — яңа гына язылган ике шигырь. Беренчесе — Сәйдәш, икенчесе мәхәббәт турында. Оялып кына, куркып кына басып торам. Елмаеп, утырырга тәкъдим итте. Тимер сейфыннан ике шешә сыра чыгарды да мине бөтенләй үз итеп: «Тамагың киптеме?» — диде. Күзләрем дүрт булды. «Юк, юк, мин эчмим...» дип, әчәсем һәм дусларым алдында бик мактанасым килсә дә, баш тарттым. Гали абый тамагын чылатып алды, аннары тиз генә укып чыкты да: «Әйбәт шигырьләр! Мә, секретариатка кертеп бир»,— диде. Ишектән чыкканда карасам, «Киләсе санга, Г.Хуҗиев», дип куйган имзасын күрдем.

Ике көннән шигырьләремне газетада күреп, башым күккә тиде.

Гали абый редакциягә йөрүче яшь иҗатчыларны туплап, әдәби-иҗат берләшмәсе оештырды һәм аның җитәкчесе итеп шагыйрь Шәрәф Мөдәррисне чакырды. Шәрәф абый фикерен туп-туры өздереп сала, кайнар бәхәсләргә дә урын калдыра, мактау сүзен әйткәләп, үсендереп тә җибәрә, бер сүз белән язмаңны юк итеп тә ташлый. Без аның батыр сугышчы булганын, «Тупчы Ваһап» кебек көчле поэма язуын, җиңүче буларак, рейхстаг диварына имзасын куеп кайтканын да беләбез. Шуңа күрә аңа их-



Ш.Мөдәррис җитәкчелегендәге әдәби түгәрәкнең бер утырышы

тирамыбыз да зур, авызыннан чыккан һәрбер сүзне күңелгә сеңдерәбез. Шагыйрьләр арасында ул вакытта әдәбият теориясен иң яхшы белүче дә Шәрәф Мөдәррис булгандыр.

Беренче әдәби курсларны мин Шәрәф Мөдәррис семинарларында үттем дип әйтә алам. Шул вакытларда «Яшь сталинчы»да «Тормыш җиңә» исемле беренче поэмам басылып чыкты. Бүген әдәбиятыбызда күренекле урын тотучы шактый язучыларыбызның тәүге иҗат мәктәбе мөдәррисе, һичшиксез, Шәрәф абый иде.

Без аның тыныч чорда да батыр йөрәкле икәнен күреп тордык.

Партия өлкә комитетының беренче секретаре Игнатьев хакимлек иткән чордагы зур бер җыелышта трибунага менде ул һәм районнардагы дубляж газеталар чыгаруны гаепләп чыкты: «Хәтта Англия колонизаторлары да бу чиккә килеп җитмәделәр. Ә сез?!» — диде ул, Беренче хакимнең күзләренә карап. Бөтен зал, куркып, шым булды.

Ул елларда мондый сүзләрне әйтү — рейхстагка менүдән дә зуррак батырлык сорый иде.

## *Уяты китте...*

Озаграк йоклап, кая булса да соңласам, Әнвәр Давыдов искә төшә. Бар иде бездә шундый шагыйрь. Сугыштан исән кайткан фронтовикларның берсе. Камышлыда район газетасының редакторы булган. Бик кыю поэмалары белән әдәбиятка бәреп кергән шагыйрьне Казанга — нәшриятка, аннан соң Язучылар оешмасына җаваплы секретарь итеп чакырдылар. Фикерләре — трибунага, уйлары шигырьгә сыймый иде. Шәхес буларак та рәсми кысалардан чыккалаганын күреп тордык. Гаиләсенә тугры булса да, мәхәббәт байлыгын беркемнән дә яшермәде. Әмма җаны саф иде. Хәсән абый аның шигырь ритмикасыннан чыгып киткәләвен яратмады. Әмма барыбер бер-берсенә ихтирам белән карадылар. Әнвәр абый иҗатташ дусларының кимчелекләрен күзләренә карап үзләренә әйтә. Сибгат Хәкимнең «Бакчачылар» поэмасын сүккәч, бик гаҗәпләнгән идем. Иҗатымның башлангыч чорында Такташ алымнарына иярүемне ул искәртеп, әйткәләп торды.

Миңа шагыйрьне төрле халәттә — үзе әйтмешли, «бөек чагында да, түбәнлеккә төшкән вакытында да» күрергә туры килде. Трибунада, иҗатта — рухи Алып... Кайва-



Татарстан язучыларының V съездында. Сулдан уңга: Кави Латыйп, Мәгъсүм Латыйфуллин, Әнвәр Давыдов, Илдар Юзеев. Февраль, 1963

кытта мин яшәгән квартирага килеп керә: төне буе йокламаган, сакал-мыек кырылмаган. Җан сызлавын сиздермәскә тырыша, шаян сүзләр әйткән була. Сизәм: «лампа эчендә май кими».

Шагыйрь, газапланып, үзен лирикада тулысынча ача алмыйча, 49 яшендә арабыздан китеп барды. Ирек сөйгән җаны заман кысаларына сыймады.

Бервакыт Әнвәр абый үзенең гаиләсе белән туган ягына — Камышлыга ялга китеп барды. Өен сакларга Хисам Камал белән мине калдырды. Берничә төн йокламыйча сакладык. Әмма алар кайтып кергән төнне тирән йокыга талганбыз. Әнвәр абый, хатыны Нина апа, уллары Рөстәм дөбердәтәләр, кыңгырау чылтыраталар,— без уянмыйбыз икән. Нәни Рөстәм борынын салындырган. «Болар безне бөтенләй кертмәсәләр, нишләрбез?» — дип елый ук башлаган. Ниһаять, без уяндык. Әнвәр абый шаярып кына әйтеп куйды:

— Уяу булыгыз, малайлар...

Ул безне, ике буйдак яшь шагыйрьне, ышанып, җылы өйдә калдырды.

Әнвәр абый безне шигърият дигән изге өйдә калдырып, гамьсез йокыдан уятып китте...

## *Юбилей болай да була икән...*

Алтмыш яше тулган Әмирхан ага Еники юбилеен туган ягында — Башкортстандагы Дәүләкәндә үткәрергә уйлады. Үзенә юлчы итеп ни өчендер мине чакырды. Әлбәттә инде, шатланып риза булдым. Уфадан Башкортстан Язучылар оешмасы секретаре Вазих Исхаковны да алды. Әмирхан ага, акыл ияләренә хас булганча, күп сөйләшми, иң кирәкле сүзне генә әйтә. Безнең кызыксынулы сорауларга: «Баргач күрерсез...» — дип кенә куя. Мин инде көтәм шау-шулы, бүләкле, адрес папкалары өелгән тантаналы кичәне. Ә безне Әмирхан ага туптуры китапханәгә алып китте. Анда безне өлкән яшьтәге апалар һәм абзыйлар көтә иде. Ул, исемнәрен әйтеп, танып, һәммәсе белән аркаларыннан сөеп күреште. Аннары безне өстәл янына утырттылар. «Башла, Вазих, кичәне»,— дип, морзабыз дилбегәне аңа тоттырды. Остаз турында сөйләү өчен Вазих миңа сүз бирде. Бу әле юби-



(Сулдан уңга): Вазих Исхаков, Әмирхан Еники, Илдар Юзеев. Март, 1969. Дәүләкән

лей кичәсе түгелдер, дип уйлыйм. Шуннан морзабыз, йомшак кына тавыш белән, әкрен генә яшьлек дусларының һәрберсенә хөрмәтләү сүзләрен әйтте. Аннары Казаннан алып килгән бүләкләрен: үзенең китапларын, яулык, мамык шәлләр өләште. «Кайчан гына әле без яшь комсомоллар идек...» — дип, шул елларны искә төшерде.

Минем мондый юбилейны күргәнем юк иде, бәлки, башка күрмәм дә. «Нишләп кичәдә рәсми җәмәгатьчелек катнашмады?» — дип сорагач, Вазих: «Ул үзе шулай теләде, китапханәгә яшьлек дусларым килсә иде, дип, башта ук әйтеп куйды»,— диде.

Кабатланмас шәхес иде шул бөек якташым.

Ул мине беркайчан да мактамады, кимчелекләремне әйткәндә дә бик сак, ипле генә әйтә иде. Аның бер киңәшен каләм алган саен искә төшерәм: «Хисләреңне яшеребрәк, салкын кан белән язу мәслихәт, әмма язганыңны укыгач, хисләнерлек, тетрәнерлек булсын...»

Аның үз әсәрләре шундый.

Ун елдан соң, җитмеш яшенә Әмирхан абыйның «Юлчы» исемле китабы чыкты. Кереш сүзне миңа язарга туры килде. Үзе үтенгән икән.

«Күңел карурманнарың тургае» дип исемләгән идем. «Тургай карурман өстендә булмый инде ул булуын, ярар, калсын, шагыйрьгә килешә»,— дип төзәттермәде. Әмма

үз китабымда кабатлап бастырганда, исемне «Күңел карурманнарыннан» дип үзгәрттем.

Олуг әдиптән миңа да бүләк эләкте: Әмирхан абый «Юлчы» китабына шундый сүзләр язган иде: «Юлчы» капчыгыннан беренче бүләк сиңа, Илдар,— шигъри сүзең, ихлас сүзең өчен! Тирән хөрмәт белән, Әмирхан Еники».

Мәкаль итеп йөртерлек сүзләрен 1973 елда басылган «Без дә солдатлар идек» дигән китабына язып калдырды: «Илдар туган! Көлү һәм моңаю чын шагыйрьдә генә була. Яратып, Әмирхан».

Мин моны олуг якташымның «Шулай булырга омтыл!» — дип теләгән фатихасы дип аңлыйм.

## *Төнбоеклы яшьлегемә кайтам...*

«Өстәлләрдә икешәр гармун,
Уйный белмибез икән»,—

дигән җыр безгә туры килми.

Без икебез дә гармунда өздереп уйный идек. Аерым-аерым да, парлап та. Икебезгә бер җыр язарга теләк, мөгаен, шулай тугандыр. Ләбиб Айтуганов көен башта яздымы, әллә шигыре элегрәк иҗат ителдеме, анысы истә дә калмаган. Ләбибнең үзе әйтмешли: истә, һаман да истә: бу җыр туганда без бер җанга әверелгән идек.

Безне илленче елларның ахырында Казан педагогия институты очраштырды. Көйсез тормышыбызны көй белән көйли идек. Ләбиб яңа көен мандолина кылларында таба иде.

Беренче җырыбыз ни өчен төнбоекка багышланган иде соң әле? Шул җыр гомере кадәр яшәгән исән авторның берсе — мин — яшьлегемнең моңлы дустын юксынып, «Төнбоек» көен гармунда уйныйм.

Ләбиб үзе дә бөтен төсе-кыяфәте, саргылт чәчләре белән төнбоекка охшаган иде. Дулкынланган күлдә тирбәлгән чәчәк кебек, ул үзенең җанын шул көйдә ачты, алдан ук гомеренең кыскалыгын тойган кебек... Гашыйкларны да, сөю газабын кичермәгәннәрне дә уй, моң күленә салды.

Яшьлекнең авыр табылган бу көен иң беренче без икебез бергәләп гармунда уйнадык.



Студент дусларыбыз туенда да без «Төнбоек»ны җырладык. Ләбиб алдагы рәттә сулдан бишенче. 50 нче еллар

Хәзер ялгызым гына уйныйм.

Ни аяныч, гомере үз көеннән кыскарак булды шул.

«Төнбоек» бездән соң да калыр әле. Кемнәрдер, парлап та, ялгыз да уйнарлар, җырларлар...

## Барыбыз да шунда булмабызмы?..

Һәр иртәне эшкә барган чакта, Горький исемендәге культура һәм ял паркы тукталышында автобус көткәндә, каршыдагы һәйкәл-монументка карап уйга калам. Яраланган сугышчы соңгы көче белән уң кулын күтәреп, алга — киләчәккә чакыра. Партия идеологиясе хакимлек иткән чорда калыккан бу сынның рәсми эчтәлеге дүртьюллык шигырь итеп язылган.

Гражданнар һәм Ватан сугышы каһарманнарына багышланган һәйкәл янында һәрвакыт җанлылык. Мин бигрәк тә яңа тормыш башлаган яшьләрнең монда килеп һәйкәлгә чәчәк куюларын карап торырга яратам.

Халык бу әсәргә үз атамасын бирде: «Барыбыз да шунда булырбыз...» («Все будем там...») Ни өчен дигәндә,



Васил Маликов һәм Илдар Юзеев. Июль, 1980

көрәштә яраланып һәлак булучы көрәшченең кулы — Арча кырындагы урыс зиратына күрсәтә. Димәк, монумент — сәнгать әсәре, аның мәгънәсе партия идеясеннән өстенрәк, киңрәк... Сын алдына килеп баскан һәркем туу, яшәү, үлем турында, үзенең гомере турында уйланып тын кала. Зиратка юнәлгән кул бу уйны тагын да көчәйтә.

Һәйкәлнең авторы — танылган сынчы Васил Маликов. Актаныш ягыннан, фронтовик. Берничә тапкыр аның остаханәсендә иҗаты белән танышканым бар. «Бәхетемнән узып барышлый» драмасындагы Айтуар образында мин Василның кайбер сыйфатларын алдым.

1968 елны Татарстан комсомолының өлкә комитеты әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Муса Җәлил исемендәге бүләк бирү турында карар кабул итте. Иң беренче лауреатлар булу — шушы һәйкәле өчен Васил Маликовка һәм «Миләүшә» исемле поэмалар китабы өчен миңа насыйп булды. Татарстанның Тукай исемендәге дәүләт бүләген дә без Васил белән бергә алдык.

Үзен дә мәңгеләштергән мәһабәт һәйкәл иҗат иткән Васил да, дүртьюллык шигырен исемсез генә язып кал-

дырган Зәки Нури да «барыбыз да шунда булырбыз...» дигән урынга — мәңгелеккә киттеләр.

Һәркөн иртән эшкә барган чакта, яраланган көрәшче сынына карыйм да аларны искә төшерәм. Минем дә шунда — мәңгелек тукталышка барасы бар бит әле... Шунда? Кайда? Көрәшче урыс зиратына күрсәтә ич... Василны язмышы урыс кызы Галина белән бәйләгән. Ул аны чын мәхәббәт белән ярата иде. Үзеннән алда китте... шунда... ул күрсәткән якка. Ә Васил? Кай тарафларда сине җир үз куенына алды? Васил да шунда... урыс зиратында ята. Шигырь авторы Зәки Нури кайда? Без аны Яңа бистәгә озаткан идек бит... Дөрес хәбәр түгелдер, нишләп ул Арча кырында ятсын? Чыннан да, Зәки абзабыз да шунда икән. Хатыны Валентина шунда күчерткән.

Безнең Ибраһим ага Газины да хатыны Марфа ханым шунда җирләгән.

Һәркөн иртән эшкә барган чакта, тукталышта күзәтәм: бер-берсен яратып кушылган, әлегә бәхетле парлар, матур гадәт буенча, чәчәкләр тотып, һәйкәл янына киләләр. Араларында башка милләт белән кушылганнар да шактый.

Яңа тормыш башларга уйлаган яшь милләттәшләремә сөенечле — борчулы карашымны юнәлтәм дә, кинәт сискәнеп, үземә дә, аларга да сорау бирәм:

«Барыбыз да шунда булмабызмы?»...

## Трускавецтан килгән хатлар

Өлкән остазларымның иң якыннары Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Нил Юзиев... минем иҗатка багышланып язучыларның Тукай клубында үткәрелгән (1964 ел, 3 апрель) әдәби кичәгә килгәннәр иде. Хәзер аларның берсе дә юк, истәлеккә әсәрләре, рәсемнәре, хатлары гына калды.

Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укыганда да, аннан кайткач та, Сибгат абый миңа хатлар язып тора иде. Гадәттә, ул һәр елны диярлек ашказанын дәваларга Трускавецка бара һәм уй-фикерләрен миңа да җиткерә иде.

*«Илдар, Тәфтилә!*

*Сезне, балаларыгызны Яңа ел белән котлыйм, яңа*

*бәхет, уңышлар телим. Илдарны икеләтә котларга туры килә, туган көне белән дә. Яңа поэма бетте, ул исәпкә керми, тагын да тирәнрәк, ялкынлырак, романтикага бай әсәрләр туарына ышанам.*

*Такташ җене, Такташ рухы синдә,*
*Ашкынулы тиле романтик.*
*Сине ерак алып барса барыр*
*Тәфтиләгә булган роман тик.*

*Сезнең исәнлеккә бер стакан... нафтуся!*

*Сәлам белән: Сибгат Хәким.*
*г.Трускавец, Бориславская, 15.*
*Декабрь, 1972».*

*«Москва, Добролюбова, 9/11, ком.212. Юзееву Илдару.*

*Илдар!*

*Хатың килде, китабың килде, дарулар килде. Рәхмәт.*

*Синең кәеф рәтләнер. Шагыйрь үзе яраткан әсәрен язгач, терелеп китә. Синдә күбрәк шагыйрьләр авыруы, чын шагыйрьләр авыруы: борчулар, иҗат борчуларыннан туган авырулар. Сирәк кешеләр генә шулай авырый. Хәзер күбесе башка чир — ялагайлык, икейөзлелек, карьера чире белән чирли. Әниеңә, әтиеңә рәхмәт әйт. Намуслы итеп тәрбияләгәннәренә. Анда, Мәскәүдә, син мондагы ыгы-зыгылардан читтә әле. Монда мин бөтенесен күреп шулхәтле җаным рәнҗи, сыкрый, яшисем килми башлый. Кешеләр үзләре турында шулчаклы кайгырталар, оештыралар, косасы килә. Правление утырышы булды. Тукай премиясенә кандидатлар тикшерелергә тиеш иде. Бар да алдан әзерләнеп беткән, алдан оештырылган, безгә сүз дә калмаган. Ә без синең белән булдыксыз, кулдан андый эш килми... Төкер барысына.*

*Синең яңа җыентыкны укып чыктым. Басылачак кулъязманы. Поэмаларны әйбәт төзәткәнсең. Шигырьләр әйбәт, уйнап-шаярып кына язылган шикелләләр. Формалары төрле. Син генә күреп алган шигырьләр, миндә дә юк алар, Шәүкәттә дә юк, Туфанда да. Дөньяны шагыйрь шулай үзенчә күрсә әйбәт. Ыгы-зыгылар узар, постлар онытылыр, яхшы җыр, яхшы шигырь, поэмалар калыр.*

*Мине Ржевка чакыралар, горком чакыра. 3 мартта Ржевне азат итүгә 30 ел. Менә, ичмасам, язмыш! Бу инде*



И.Юзеев иҗатына багышланган кичәдәнт соң. 1964

*Язучылар союзындагы ыгы-зыгы түгел! Шагыйрьне шәһәрләр үзенә чакыра, халык. Әле Белгород, әле Харьков, әле Ржев! Мин язмышыма куанам. Миңа вакланырга ирек бирми! Барырмын дип торам. Кайтышлый Мәскәүдә тукталсам, сиңа керермен дә әле.*

*Сәлам белән: Сибгат Хәким.*

*22.11/73».*

*«Илдар!*

*Бүген дә төш күреп уяндым. Миңа гел сугыш белән бәйле төшләр керә. Бер сугышып кайтканнан соң йә яңадан алалар, семьядан яңадан аерылам, Казаннан, язучылардан. Инде миңа илле-алтмыш яшь икән, һаман солдатка алып газаплыйлар. Союздан бронь да юк. Язучы икәнемне күрсәтү өчен үзем белән китапларымны да алмаганмын. Бәшир Казанда, аңа хат язып карыйм, мине кайтаруны сорап. Җавап юк. Шулай интегәм. Йә әсир төшәм. Әсир төшүдән куркам.*

*Бүген күргән төш икенче төрлерәк. Өченче сугыш алды, сине, Шәүкәтне армиягә алганнар. Авыл ишегалды, кыш. Озатырга дип керсәм, сез юк. Мине әле, сугышта бер булганнарны, тәҗрибәлеләрне, имеш, соңрак алачаклар. Ялгыз калганмын, бер үзем, күңелсез. Синең язып бетергән бер поэмаң калган. Илдар фронтта да күп язар дигән уйда йөрим, имеш.*

*Башкалар минем төшкә керми, Шәүкәт, син, Хисам миңа турылыклы булып калдыгыз. Башкалар вакытлы, үтеп барышлый. Олы буыннан — Туфан, урта буыннан — сез, ахырынача.*

*Үзем туйганчы су эчәм, гарык булганчы. Тамакка ингаляция алам. Көзге урманда, Карпат урманында йөрим. Бер юл да язганым юк. Башка елларны берәр мәкалә алып кайта идем, йә Дәрдмәнд, йә Вафирә, йә сезнең буын шагыйрьләре турында. Быел — юк. Быел Казахстан белән Красноярскида булдым, арыдым. Күргәннәрне күңелдә йөртәм, аннан, күңел тәмам тулгач, моңсулык тәмам баскач, боегып, читләшеп, бизеп, күзләргә яшь килер дәрәҗәгә җиткәч, язарга утырырмын. Ленин турындагы әсәрләрне дә шулай яздым мин. Тетрәүләрдән соң, сугыш алды (1937) еллары, Ватан сугышы елларыннан соң, Ленин турында әйтәсе, язасы килде, язмый берничек тә булдыра алмас хәлгә килдем. Ленинны сагыну туды күңелдә. Хәзер шуның дәвамы яши: Себер, Шушенское, Енисей, Себер киңлеге һәм Ленин карашлары киңлеге... Себердә мин утырткан кедр һ.б. Быел күп йөрдем, күп күрдем, хәзер гомумиләштерәсе бар. Миңа иҗат итәр алдыннан алда Казахстан далалары ятсын. Мин элек тә сан артыннан кумадым, хәзер дә. Күп нәрсә настроение белән бәйле. Сугыштан калган тромбалы аяк авырта, тагын тыгылды. Кайткач, салсалар, урын булса, операциягә керермен, ахры. Әнә шул аяк дүрт-биш елга түзәр микән?*

*Трускавецта ике китап кибете бар, рус телендә бер әдәби китап та юк. Елап эзләсәң дә юк. Бары да тик украин телендә.*

*Менә шулай минем хәлләр.*
*Вакыйфның повестен укыйм.*
*Шәүкәткә сәлам!*
*Сәлам белән: Сибгат Хәким.*

*1 октябрь, 1979»*

# Нәҗар абый ачкан капкадан...

Ун яшемдә беренче шигыремне район гәзитендә күрсәм дә, язганнарымны республика матбугатында чыгару хыялы көчле иде. Шигырьләремне Казанга җибәреп тә карадым. «Әлегә басылырлык түгел» дип, җавап килсә дә, башым күккә тия иде. «Минем көнем» исемле шигыремә Гариф Гобәйнең үзеннән хат килгәч сөенгәнемне белсәгез иде! «Шигырең ярыйсы гына кебек, мин аны Татгосиздатка Абдулла Әхмәткә биреп карармын»,— дигән бит! Әмма шигырь барыбер дөнья күрмәде. Унынчы класста укыганда мин ул шигырьне Уфага — «Әдәби Башкортстан» журналына юлладым. Озак та үтмәде, редакциядән — Нәҗар Нәҗмидән җавап килде: «Шигыреңне журналга тәкъдим итәм»,— дигән бит! 1950 елның июль санында үземнең шигырьне күргәч, шатлыктан күкнең җиденче катына мендем. Шунда ук урнаштырылган мәкаләсендә Нәҗар абзый «...И.Юзеев һ.б. иптәшләр киләчәктә өмет казанырга вәгъдә итәләр» дип тә язгач, үз-үземә ышаныч тагын да артты.

Шулай итеп, Нәҗар абый олы әдәбиятка капка ачучы иң беренче остазым булды, һәм гомерем буе олуг шагыйребезнең җылы карашын, игътибарын тоеп яшәдем. Татар шагыйрьләренә хат рәвешендә язылган әдәби-тәнкыйди мәкаләләрендә никадәр киң күңеллелек, өлкән һәм яшь каләмдәшләре өчен ихлас сөенү!

1994 елның 14 мартында Уфада минем иҗатыма багышланган кичә үткәрелде. Тамашачылар арасында Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗми, Әнгам Атнабай, Муса Гали, Шәриф Биккол, Нәҗип Асанбайларны күргәч, бик дулкынландым. Нәҗар Нәҗми һәм Әнгам Атнабайның минем иҗатны олылап әйткән сүзләре һаман онытылмый. Күңелне күтәрергә теләгәндер инде, Нәҗар абзый: «Мондый затлы бина (Башкорт опера һәм балет театры) теләсә кемгә тәтеми»,— дип тә җибәрде.

1997 елның 27 маенда Казан, кичә үткәреп, Нәҗар абыйны үз шагыйре итеп таныды. Шул көнне мин дә остазыма шигырь багышладым:

«Һәрнәрсә дә соңлап килде сиңа»...
Җырда ашыгучан булмадың.
Чал табигать картлык өләшкәндә,
Шигырь язып калдың, соңладың.



Нажар абый һәрчак уртада

Мин дә шигърияткә килеп кердем
Нажар абый ачкан капкадан.
«Үземнән дә яшьрәк остазым» дип,
Горурланам хәзер, мактанам.
Шигырь генә менәр биеклеккә —
Кыяларга мендең әкертен.
Бик күп яшьләр мине остаз, диләр,
Ә мин һаман синең шәкертең...

## «Казан утлары»на кергәндә

«Совет әдәбияты» редакциясендә булган кызыклы бер вакыйга искә төште. Ләбибә Ихсанова белән Нури Арсланов бер бүлмәдә утырган елларда, яшь автор килеп керә. Ул арысландай мәһабәт гәүдәле, чал чәчле шагыйрь янына килә дә каушап, оялып кына:

— Ләбибә апа Ихсанова сез буласызмы? — дип сорый.

Билгеле инде, моны көтмәгән мәшһүр шагыйрь ачуланып сикереп тора һәм бер генә минутка булса да затлы нәселдән икәнен онытып, үзенең арысланлыгын исбат итәргә мәҗбүр була.

Беренче тапкыр редакция ишеген ачып кергәндә, мин дә әнә шул яшь егет хәлендә идем. Әмма без, Сибгат Хәким кебек остазлар үз канатлары астына алган яшьләр, тора-бара журналның үз авторларына әвереләдек. Мәктәп тәмамлап кына Тукай, Такташлар яшәгән Казанга ашкынып килгән бездәй авыл гыйбатларына журнал, чын мәгънәсендә, әдәбият институты, остаханә булды. «Совет әдәбияты»ның 1955 елгы 10 нчы санында «Таныш моңнар» поэмасы басылып чыкканчы ук Сибгат Хәкимнең плюс билгесен күрмәсәм, Шәйхи Маннурның «Афәрин!» сүзен ишетмәсәм, башка әсәрләрем туар идеме икән? Соңгы биттәге фамилияләргә күз салу да җитә: редакторы — Гази Кашшаф, редколлегиядә Ибраһим Гази, Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов... Абруйлы шагыйрьләрнең җылы сүзләреннән башка поэма күтәреп кереп кара син алар янына! Ибраһим Гази хәтта Такташка да ирония беләнрәк карый, соңрак, союз идарәсендә бергә эшләгәндә, ул «синең Такташың» дип кенә җибәрә иде. Шигъри әсәрләрнең язмышын нигездә Сибгат Хәким хәл иткәнлектән, проза осталары поэзиягә әллә ни тыгылмыйлар, аларның үз жанрларында үзләренең яратканнары һәм яратмаганнары бар.

«Таныш моңнар» каршылыкка очрамады. Шул ук журналда аның турында зур мәкалә укып сөендем.

Журнал битләрендә игълан ителгән «Фәрит-Фәридә» поэмасы исә, һич көтмәгәндә, «Совет Татарстаны» битләрендә зур бәхәс куптарды. Зыя Мансур, күләмле мәкалә язып, Ватан сугышы каһарманнарын йомшак күңелле, нечкә хисле, романтик планда күрсәтүне гаепләде. Аңа каршы, поэманы, иҗади алымны яклап, Шәйхи Маннур күтәрелде. Шау-шулы бәхәскә хәтта Ибраһим Гази да килеп кушылды. Аннары укучылардан хатлар яуды. Бер айга якын сузылган бәхәс редакция мәкаләсе белән ябылды. Хәзер, озак еллардан соң ул поэмамны укып карыйм да гаҗәпләнәм: тавыш-гауга куптарырлык әллә ни булмаган югыйсә... Кискен тәнкыйтьнең дә, мине яклауның да, һәрхәлдә, зарары тимәде, киресенчә, укучының минем язмаларыма игътибары артты гына. Китап итеп чыгарганда үзем кирәк тапкан тәкъдимнәрне искә алдым.

Бер генә оешма да безне үз игътибарыннан калдырмады: өстән дә, астан да, үз арабыздан да укып, тың-



Остаз белән янәшә. Утырганнар (сулдан уңга): Хисам Камал, Сибгат Хәким. (Икенче рәттә): Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гамил Афзал

лап, күзәтеп торалар иде. Ул вакыттагы пропаганда бүлеге мөдире Ф.Ә.Табеев зур бер җыелышта минем политик яктан өлгермәгән әсәрләр язуымны тәнкыйтьләде. Мөгаен, дөрес әйткәндер. Ул вакытта мин моны авыр кичердем.

Ул елларда безнең ниләр язуыбызны гына түгел, кемнәр белән, кайда, ниләр сөйләшүебезгә кадәр белеп торалар иде. Безгә кунакка килгән Башкортстан язучылары белән мәҗлестә утырганның икенче көнендә үк, мине идарә рәисе Афзал Шамов чакырды.

— Сез кичә «Казан» ресторанында башкорт язучылары белән интернациональлеккә каршы килә торган, политик яктан зарарлы сүзләр сөйләшеп утыргансыз икән. Бу — гадәттән тыш хәл...

Шул ук көнне партия оешмасы секретаре Гази Кашшаф, шул ук кабинетка алып кереп, ишекне бикләп үк куйды.

— Ниләр сөйләгәнеңне чамала, икенче вакыт авызыңны үлчәп ач, дусларыңнан саклан...

Шулай да без өлкән буыннан бәхетлерәк булдык —

1937 еллар артта иде инде. Әмма барыбер шул чорның кара шәүләсе, үзе күренмәсә дә, барлыгын искәртеп-куркытып тора иде.

Мөгаен, өлкән татар язучыларының күп сөйләшергә яратмавы шуннан калгандыр.

Журналыбыз безне какмады, кирәк вакытта яклады, масаеп китүдән саклады, үз ишеген беркайчан да япмады.

Әле дә ул шундый.

Кыскасы, иҗади гомеремнең кырык биш елы «Казан утлары» белән бәйле. Әсәрләремнең күпчелеге шунда дөнья күрде. Кайберләре шома гына узды, кайберләрен цензура яки редактор туракдады, кайбер урыннарны, үземә-үзем цензор булып, үзем сызып ташладым.

«Соңгы сынау» драматик легендасы чыккан вакыт иде, мине телевидениегә чакырып, аларга килгән бер хат тоттырдылар. Анда «идеологик яктан зарарлы бу поэманы экранга үткәрмәскә!» дигән таләп куелган һәм хатның өч инстанциягә җибәрелүе турында искәртелгән. Татар теленең йотылуга, бетүгә баруы хакындагы фикерләр Мефистофель авызыннан әйтелсә дә, хат авторы сәяси уяулык күрсәткән. Ул заманнарда туган телебезнең аяныч хәлен укучыларга җиткерергә теләгәндә, төрле әдәби хәйләләр уйлап табарга туры килә иде шул. «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясендә шундый уйларымны Тукайның патша белән сөйләшүендә бирә алдым шикелле. Шунлыктандыр, цензура бәйләнмәде.

## *Халыкка туры карап...*

Без мәктәптә укыганда ук инде абыем Нил белән шигырьләр, пьесалар яза идек.

Шул елларның истәлекләрен эзләгәндә, кызыклы бер хатка юлыктым. Киләчәктә күренекле язучы, Тукай бүләге лауреаты, булачак якташыбыз Нурихан Фәттахтан Нил Юзиевка килгән хат иде бу.

*«Яңавыл районы, Ямады авылы, урта мәктәп, 7 нче класс укучысы Юзеев Нилга.*

*17.1.1945. Яңавыл.*

*Исәнме, Юзеев!*

*Мин сезнең 17 гыйнварда район күләмендә үткәрелгән*



Якташ язучылар Нил Юзиев, Риза Ишморат, Нурихан Фәттах.
80 нче еллар

*худ.самодеятель. олимпиадасында ясаган чыгышларыгызны чын күңелемнән тыңлап утырдым. Синең шигырьләреңнең кайбер җирләре миңа бик ошады, һәм мин сине шуның өчен котлыйм. Ләкин сиңа район каршында чыгыш ясаганда тагын да уңышлы чыксын өчен үз өстеңдә ныграк эшләргә кирәк иде. Киләчәктә син үзеңнең (түбәндә мин әйтеп киткән — ачуланма!) ялгышлыкларыңны бетерергә тырыш. Беренчедән — синең ялгышлыкларың: халык алдында торганда туры тор, селкенмичә тор, шигыреңне дәфтәрдән карап сөйләмә — ятла; халыкка туры карап интонация белән сөйлә. Әгәр синдә шушы кимчелекләр булмаса,— синең сүзләрең халыкны дулкынландырырлык, живой һәм матур чыгар иде. Әмма болар бик зур кимчелекләр түгел, син аларны киләчәктә төзәтә алырсың!*

*Сиңа минем хикәя һәм шигырь язуда бераз киңәшләр: моннан соң язуыңны нык үзгәрт, мин язган кебек печатный язу булсын, чөнки әгәр син башка зур җирләргә шигыреңне яки хикәяңне бастырырга дип җибәрсәң — шушындый итеп язу таләп итеlә; ана теле грамматикасын нык өйрән: тыныш билгеләрен, сүзнең дөрес язылышларын; бигрәк тә русча китапларны күп укы, теле-*

*ңне күнектер — авылда бер рус белән сөйләшмәсәң дә, тиз русча сөйләшергә өйрәнерсең, рус теле — иң кирәк тел.*

*Сораулар: әдәбият белән күптәннән шөгыльләнәсеңме һәм беренче шигырьләр язарга нинди теләк тартты? Мәктәбегездә берәр әдәби журнал чыгарасызмы, чыгармасагыз — әдәбият укытучысы белән берлектә әдәбият белән кызыгучы балаларны җәлеп итеп журнал чыгарырга тырышыгыз. (Безнең мәктәптә: «Безнең иҗат» дигән әдәби журнал чыга.) Шигырь һәм хикәяләрең миңа күрсәткән кадәр генәме, тагын да бармы?*

*Киләчәктә сиңа уңышлар теләп: Фәттахов.*

*Миннән энеңә дә сәлам! Яздым: төнлә 17.1.1945.*

*Хат язсаң — минем адрес:*

*Пос.Янаул, ул.Красноармейская, дом № 14, шк. № 1, ученику 9 класса Фаттахову Нурыйхану С.*

*(Тик шушы формада гына яз адресны.)»*

Кызык факт: Нурихан Фәттахның 1945 елда ук «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Көз» һәм «Кыш» исемле шигырьләре басылып чыккан иде. Шул ук шигырьләрне «Уку китабы»нда күреп сөенгән идем. Үзебезнең Яңавыл районының 10 нчы класс укучысы — «классик»(!) Нуриханның бу хаты безгә нык тәэсир иткәндер, шул яшьтә үк халык алдында җаваплылыгын тоеп иҗатка тотынган язучы безгә олы, җитди бурычлар куя бит!

Үзегез белгәнчә, Нурихан Фәттах гомере буе шул югары принципка — халыкка туры карап язуга тугрылык саклады һәм халкыбызның олуг әдибе булып танылды.

Нил абый иҗатташ дусты Нурихан әйткән киңәшләрне дә искә алгандыр дип уйлыйм: ул тормышында да, иҗатында да халыкка туры карап яшәде.

## Без дә патшалар сараенда йөрдек...

1986 елның 24 июнендә Мәскәү Кремлендә, СССР Верховный Советының утырышлар залында СССР Язучылар союзының VIII съезды ачылды. Без, Татарстан язучылары-делегатлары һәм кунаклары, алдан ук барып, сигезенче рәттә урын алдык. Беренче утырышта М.С.Горбачев җитәкчелегендәге Политбюро катнашты. Г.М.Мар-



ков, хисап докладын унбиш минут сөйләгәч, кинәт туктап калды. Зал тып-тын. Ни булганын беркем аңламый. Шулчак ике егет килеп, аны ике ягыннан култыклап алып киттеләр. Трибуна — буш. Президиум бераз киңәшкәннән соң, Советлар Союзы Герое, язучы В.Карпов трибуна янына басып, доклад укуны батырларча дәвам итте. Соңыннан безгә «киеренкелеккә түзә алмыйча, Марковның йөрәк өянәге кузгалган» диделәр.

Бездән алдагы рәттә М.С.Горбачевның тормыш иптәше (бу урында «хатыны» дип әйтү килешми) Раиса Максимовна утыра, һәммәсенең игътибары аңа юнәлгән. Аның янына әрсезләнеп Сергей Островой дигән шагыйрь килеп утырды. Сакчылар куып та карадылар, китмәде. Тәмам теңкәсенә тиде патшабикәнең. Без дә үзебезчә кыюланып киттек, һәммәбез кул куеп, Муса Җәлилнең сувенир китабын бүләк иттек. Арабыздан кемдер: «Әйдәгез, аның белән рәсемгә төшәбез!» — дип тәкъдим итте. Тәнәфескә чыгу белән, Россия Язучылар союзында эшләүче Гәрәй Рәхим фотограф эзләп чапты. Әмма ул килеп өлгергәнче, без, фотограф табып, Раиса Максимовнаның үзен залга чакырган идек инде. Ул бер дә ялындырмыйча гына без көткән урынга килде һәм ягымлы елмаеп, тыйнак кына сөйләшеп, уртабызга басып, рәсемгә төште.

Рәсемнәр безнең үзебезгә эләкмәс инде дип борчылып йөргәндә, икенче көнне Раиса Максимовнадан килгән егет (сакчысы булгандыр инде) безгә фоторәсемнәрне тапшырды.

Шулай итеп, безне оештырып йөргән Гәрәй Рәхим, патша сараенда адашып, тарихка эләгүдән мәхрүм булып калды. Ә ул чактагы председателебез Туфан Миңнуллин кайда дисезме? Үзенә тиешле җирдә — президиумда... Бу съездда аны СССР Язучылар союзы секретаре итеп сайладылар.

Минем дә дәрәҗәне бөтенсоюз масштабына күтәрделәр: СССР Язучылар союзына идарә әгъзасы иттеләр. Әйе, бар иде безнең дә Кремль сарайларында патшабикәләрнең үзләре белән күзгә-күз карап сөйләшеп йөргән чаклар...

Ышанмасагыз, әнә рәсемгә карагыз. Уңнан сулга: Миркасыйм Госманов, Илдар Юзеев абзагыз, Тәлгать Галиуллин, Әмирхан Еники, Раиса Горбачева, «Правда» газетасы корреспонденты, Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Дания Зарипова, Ренат Харис.

## Мәхәббәт ничә була?

1972—1973 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзының Югары әдәби курсларында укып яткан көннәрнең берендә мин яшәгән бүлмәгә өлкән яшьтәге бер ханым килеп керде.

— Сез Илдар Юзеевмы? Ярый. Яшь автор булмасам да, Сезгә килдем әле. Мин Мәскәүдә яшим: Мөбинә Таһирова.

— Шигырьләр язасыздыр инде.

— Шигырьләр дә язам. Әмма бу юлы шигырьләр алып килмәдем. Мин Муса Җәлил турында истәлек китабы яздым. Сез укыгыз әле, мин берничә көннән килермен.

Шактый күләмле калын кульязманы йотлыгып укып чыктым. Өлкән яшьтә булуга карамастан, күзләрендә яшьлек очкыннарын, сөйкемлелеген югалтмаган ханым белән кабат очрашуны мин шикләнеп тә, кызыксынып та көттем. Ул сурәтләгән хәлләр, чыннан да, дөресме? Хәзер бит боларны берәү дә раслый алмый, шуның өстенә



Югары әдәби курсларда укыган чак. И.Юзеев — өченче рәттә уңнан икенче

Әминә ханым да дөньяда бар бит әле. Мөбинә ханым үзен Мусаның беренче мәхәббәте итеп күрсәтә: янәсе, алар бер-берсен бик яратып, өйләнешү алдында калганнар. Иптәшләре туй өстәле әзерләп көтеп тора, ә Муса дусты Ченәкәй белән бергә кәләшне алырга китә һәм... озак көткәннән соң, ул, башын түбән иеп, кайгылы кыяфәттә кайтып керә. Яшь гүзәлкәй, башта риза булып та, иң соңгы минутта кияүгә чыгудан баш тарткан. Туй өзелә. Кызлардан беркайчан да каршылыка очрамаган Муса гарьлегеннән нишләргә дә белми.

Мин ышаныр-ышанмас, ни әйтергә дә белмичә сорыйм:

— Монда язылганнарны ничек раслый аласыз соң?

Мөбинә ханым мине үзенең өенә чакырды һәм анда тагын да кызыклырак мәгълүматлар белән таныштырачагын әйтте.

Менә мин аның ике бүлмәле җыйнак фатирында Мусаның яшьлеге белән танышып утырам. Казанның гүзәл кызы Мөбинә иптәш кызлары белән — анда Муса да бар. Аның белән төшкән тагын берничә рәсем. Боларны мин беренче тапкыр күрәм.

Истәлекләр китабында әлегәчә билгеле булмаган башка вакыйгалар да бар. Кызык бер факт: Эрнст Тельман Казанга килгәч, Казан университетында да чыгыш ясый, аны тәбрик итүчеләр арасында Мәскәүдән эш белән кайткан Муса Җәлил дә була. Ялгышмасам, аларның соңгы язмышлары Моабит төрмәсе белән бәйләнгән.

Казанга кайткач, мин Гази ага Кашшафны эзләп таптым һәм бу кызыклы табыш турында сөйләдем. Гази абый сабыр гына, ашыкмыйча гына миңа болай диде:

— Беләм мин Мөбинәне. Мондый истәлекләргә бер дә исем китми. «Мин Мусаның беренче мәхәббәте идем» дип язган берничә ханымның истәлеген укыганым бар. Син аларга игътибар итмә.

Мусаның васыятен тормышка ашыручы дусты шулай дигәч, Мөбинә ханымның истәлеге шик астында калды. Артык кызыксынуны туймагач, Мөбинә ханым минем янга үз шигырьләрен генә укытырга һәм киңәш алырга килә башлады.

Узды еллар. Тузды чорлар. Мусаның иң якын дусты Гази абый да юк инде. Мөбинә ханымның да якты дөньядан китеп барганын ишеттем.

«Идел» журналының быелгы 1 нче санында Рабит Батулланың «Карчыга» исемле документаль әсәрендә Ф.Мөсәгыйть сөйләгән сүзләрне укыйм: «Муса Мөбинә исемле чибәркәйгә өйләнмәкче булды... Мөбинә чибәркәй Мусага отказ биргән...» Төп-төгәл мин Мөбинә ханымның истәлегендә укыган вакыйга. Монда Гази Кашшаф үзе дә булган. Ул хакта үзе миңа әйтмәгән иде.

Димәк, Мөбинә Таһированың истәлекләрендә ялган юк. Гази абый нигә моны яшерде икән? Минемчә, Гази абый Мусаның Әминәдән башка берәүгә (берәүгә генә микән?) мәхәббәтен «фаш итү»не кирәк тапмаган. Ул бит белә: партия геройны барлык яктан да пакь, камил итеп, бер генә мәхәббәтле итеп күрсәтергә рөхсәт итә. Хәзер инде безгә мәгълүм: Мусаны кызлар бик яраткан, ул да йөрәк хисләрен кызганмаган.

Әхмәт ага Исхакның сөйләгәне искә төште әле. Яшьләр мәҗлесендә утыралар икән. Икесенең арасында чибәр кыз утыра. Икесе дә гашыйк булганнар моңа. Әхмәт абый, ашъяулык астыннан нәзек билгә үрелсә, анда Мусаның кулын очрата. Муса алданрак өлгергән.

Казанда яшәүче туганым Гыйльмия апа янына аның якын дусты, радиода эшләүче Зәкия Садыйкова килеп йөри иде. Җәлил шигырьләренең кайткан вакыты бу. Гыйльмия апа ул килеп кергәнче үк: «Кызы Люция исемле, Мусадан» дип, колакка гына әйткән иде инде. Якынаеп алгач, Зәкия апа ачылып китте һәм: «Без, хатын-кызлар, Мусаны бик яраттык, бәйләнеп, газаплап та бетерә идек, мин дә үз шигырьләрем чыккан китапта «Өч хат» дигән шигырь багышлап, аңа усал сүзләр әйттем...» Муса турында Зәкия апа искиткеч яратып сөйли иде.

Без хәзер Мусаның совет чорында кимчелек дип саналган, яшерелгән «мәхәббәт гөнаһлары»ның кайберләрен беләбез. Белмәгәннәрен эзләргә, шагыйрьнең күңелендә казынырга кирәкми дә.

«Чын мәхәббәт була бер генә» дип раслаган шигырьләрне мин дә яздым һәм әле дә бу сүзләремнән баш тартмыйм. Дөньяда Мәҗнүннәр мәхәббәте бар бит әле. Абсолют мәхәббәт! Дан һәм хөрмәт аларга! Ә кем язган «кеше бер генә яратырга тиеш!» дигән канунны? Мәхәббәт, йөрәк бернинди акыллы кануннарга да буйсынмый.

Мусаны йөрәгендә уянган барлык мәхәббәтләре белән кабул итәргә кирәк. Анда — шагыйрьнең хисләр сафлыгы, тойгылар бөеклеге, шигъри көче! Дөньяда тиңе булмаган батырлык кылырга Мусаны саф мәхәббәт хисләренең муллыгы да әйдәгәндер.

Табасы иде дә чыгарасы иде Мөбинә чибәркәйнең яшь гашыйк Муса турындагы истәлекләрен. Аларда яшь шагыйрьнең йөрәк тибешләре, күңел тибрәнешләре, Казандагы һәм Мәскәүдәге яшьлеге...

(Ул истәлекләр «Идел» журналының 2002 елгы саннарында басылды).

Ә Әминә?..

Әминә — Мусаның соңгы мәхәббәте. Ир-егетләр, авыр сүзләр әйтмәгез аңа. Кызлар-ханымнар, күпсенмәгез Әминә ханымның фаҗигале-илаһи мәхәббәтен! Үзегез аның хәлендә калып, «Әминә Мусаны көткәндәй» көтеп карагыз! Яшьләр, Мусага охшарга тырышам дип, барлыюклы гыйшык-мыйшыкларыгызны чәчеп йөрмәгез, баш-та уйлагыз: сез Муса кебек батыр да, матур да була аласызмы?..



«Чаян»чылар. 1969

## Мин дә «Чаян»да эшләдем!

«Пионер» («Ялкын») журналында җаваплы секретарь булып унике ел эшләү дәверендә дүрт редакторны алыштырдым. Редакторлар килә дә китә, килә дә китә — мин калам. Үстермиләр дә, эштән дә кумыйлар. Ә китәсе килә! Җай килеп чыкты бит әй! Ул чакта коммунистик хезмәт коллективы бригадиры Валентина Гаганова методы бик хуплана иде. Артта калган бригадага түгел, азрак хезмәт хакы түли торган эшкә күчәргә! Эштән мактый-мактый, приказ язып рәхмәтләр белдерә-белдерә җибәрделәр. Шулай итеп, «Чаян»га әдәби хезмәткәр вазифасына барып кердем. Миннән алда инде бу бүлектә әллә ничә язучы кереп-чыгып, кайсы ярты ел, кайсы бер ай, кайсы бер атна эшләп киткән. Мин рекорд куйдым! 1966—1967 елларда нәкъ унбер ай эшләдем. Альберт Яхин миннән фельетончы ясамакчы иде, бик тырышып караса да, хыялына ирешә алмыйча, кул селтәде. Кул селтәве ничәнче тапкыр булганын үзе генә беләдер. Мине әдәбият бүлегенә тапшырды.

Дөресен әйткәндә, бу редакциядә эшләү миңа «Мин дә «Чаян»да эшләдем!» дип горурлану өчен, салам торхан, әтрәк-әләмнәрне, бюрократларны өркетү өчен кирәк иде. Ни өчен дигәндә, ул вакытта «Чаян»нан куркалар иде. Сатираның абруе зур иде!

Фельетон язарга өйрәтә алмасалар да, юмор бакчасына керергә, мактанырга мин әнә шул унбер айда өйрәндем. Хезмәт кенәгәмдә «килде— китте» дигән мөһерем дә бар. «Чаян» миннән уңмаса да, мин аңардан уңдым бугай. Тормыш юлымны сөйләгәндә: «Мин «Чаян»да эшләдем!» — дип, һаман мактанып алам.

## Куклардән эзлим...

Хәсән Туфан турында сөйләргә уйлагач, туктап калдым. Үземне тыя алмыйча, күп сөйләп ташламаммы? Тыңлаучы ни уйлар? Мине Хәсән абый үзе тыңлап тора сыман. Ә ул үзе иң кирәкле сүзне генә әйтә, башкаларны, ни генә сөйләсә дә, бүлдермичә, игътибар белән тыңлый белә иде. Бөек акыл һим хис ияләренә хас сыйфат.




Мәскәүгә декадага барганда тукталыш. Уңнан: Х.Туфан, И.Юзеев, А.Әхмәт, 1957

Хәсән абый турында сөйләгәндә, прозага сыю мөмкин түгел.

Син бит тыңлый белә идең —
Сөйгәнне, сөймәгәнне...
Күңелеңә җыя идең
Башкалар сөйләгәнне.
Әллә тел, әллә гадәтне
Һаман да тыя алмыйм:
Сөйлим дә сөйлим, сүзләргә
Һич нокта куя алмыйм.
Тыңлау осталыгы белән
Үзеңә карат икән.
Башкаларны тыңлый белү —
Үзе бер талант икән.

Мин бәхетле: тормыш юлында атам кебек кешеләргә юлыктым. Алар мине бик яшь килеш араларына алып, кирәк чакта мактадылар, яшьлек шайтаны котырткан чакта, колакны боргалап тордылар.

1957 ел. Без Мәскәүгә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына барабыз. Арада — егерме дүрт яшьлек егет — мин дә бар. (Мактанудан тыелам, Хәсән абый тыңлап тора кебек.) Әле кесәдә язучылык билеты да юк. «Пионер» («Ялкын») журналында җаваплы секретарьмын. Эшкә мине журналның редакторы Абдулла абый Әхмәт алды. Хәсән абый белән дуслар иде. Мөгаен, эшкә тәкъдим итүдә Хәсән абыйның да катнашы булгандыр, дип уйлыйм. Ул елларда Хәсән абыйның шигырьләрен алырга дип, өенә бара идем.

Поездда Мәскәүгә китеп барабыз бит әле. Ике вагон тулы үзебезнекеләр. Хәсән абый да шунда.

Бу рәсемне мин бәхетле көннәремнең онытылмас мизгелләре итеп саклыйм. Абдулла абый белән Хәсән абый ике фәрештә кебек як— ягымда торалар.

Алар икесе дә Аккош күлендә яшиләр иде. Хәзер аккош күңелле фәрештәләр булып күңелемдә яшиләр...

## Шәрифнең «усал» шаярулары

Шәриф Хөсәеновның холкын өендә үзе үстергән кактуслар белән чагыштыралар. Дөрестер. Чынында, ул бик тә нечкә җанлы булып, шул сыйфатын яшерергә тырыша иде. Ни өченме? Бу әлегә миңа сер булып кала. Шәриф язучылар арасында сирәк күренде. Җыелышларга оны-



(Сулдан): Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәриф Хөсәинов, Шәүкәт Галиев

тылганда бер килеп чыга. Әсәрләре дә сагындырып кына куела яки китап булып басыла. Илленче еллар башында Шәрифнең исеме легендага әверелде. «Медицина институты студенты язган шәп пьесаны академия театры куя икән» дигән хәбәр бөтен Казанны шаулатты. «Зөбәйдә — адәм баласы» белән тамашачыларны тагын бер кузгатты да, озак вакыт тын калып, яшьләр егылып укырлык повесть — «Мәхәббәт сагышы»н тудырды. Аннан соң инде — аны үзе исән чакта ук классиклар рәтенә куйган «Әни килде» драмасы.

Шәриф ялгызлыкны ярата, җыелышларда буш һәм күп сөйләүчеләрне сөйми. Берничә тапкыр кактуслар белән тулы өендә дә булганым бар. «Доктор Хөсәеновка килдегезме, әллә томау төштеме?» кебегрәк сүзләр белән каршылар. Шаярулары кактус кебек кырыс булыр.

Кешеләр арасында сирәк күренүче Шәрифне очратасың килсә, опера театрына бар. Мин үзем дә операга сирәк йөрим. Берсендә мине күргәч: «О! Татар язучысы операга килгән! Гадәттән тыш хәл!» — дип кулын бирде. Ул үзе бер үк операны берничәшәр тапкыр карый торган зыялы тамашачы иде шул.

Минем «Кыр казлары артыннан» пьесасын Шәриф ошатты. Үз фикерен урамда очрашкач әйтте: «Сине әле

алып китмәделәрмени?» «Ни өчен?» — мин әйтәм. «Кыр казлары артыннан» драмасындагы җырында советка каршы сүзләр әйткәнсең ич: «Хыялыма китәр идем кыр казлары артыннан»... Димәк, совет кешесе үзенең хыялына ирешә алмый?

Аның мактавы шул.

Беркөнне Шәрифне Бауманда очраттым. «Ни булды сиңа,— ди бу,— йөзең ап-ак булган, яман авыру белән чирләдеңме әллә? Мин моны сиңа табиб буларак әйтәм...»

Монысы да Шәриф шаяруы. Мин дә аны үзенчә шаяртырга уйладым. Бер көнне урамда күрдем дә: «Шәриф, ни булды сиңа, йөзең саргайган, әллә берәр начар авыру эләктердеңме?» — дим. Шәриф усал гына итеп: «Кит аннан?!» — диде дә китеп барды. Карыйм: бераз баргач, артына борылып шаркылдап көлә башлады: «Аңладым!»

Озак еллар узып, Шәриф чыннан да шул авырудан егылгач, бик үкендем шул шаяруым өчен... Бәлки, Шәриф үзе дә үкенгәндер.

Ул үз юморын кабул итүчеләрне генә, хәтере калмаучыларны гына шулай шаярта иде.

Бер шаяртуын үзе сөйләде. Башка шәһәрдә яшәүче талантлы бер язучыны Шәриф кунакка чакырган. Бишалты көн узган, кунак китәргә уйламый. Ничек моннан котылырга? Почтага барган да үз өенә телеграмма суккан: «Тиз кайт, сине көтәм. Туган апаң». Килеп төшкән телеграмма. «Китәсеңме инде?» — дип сорый Шәриф. «Мин аңардан ничек котылырга белмим, ул китмичә кайтмыйм»,— дигәч, Шәриф үз шаяруының тозагына капканын аңлаган.

Бу вакыйганы ул үзенә кунакка баргач сөйләде һәм: «Үзегез нәтиҗә ясагыз!» — дип өстәде. Әмма аның белән бер табында утыру җан рәхәте иде. Теге кунак та шуңа күрә китәргә теләмәгәндер...

## «Металл хисле Баттал»

Шагыйрьләр остаханәсенең 1994 ел сентябрендә үткән утырышына (мин аның җитәкчесе идем) без Салих Баттал аганы чакырдык. Шигъриятебезнең гаять бай биографияле остасы бик күп сорауларга кызыклы һәм тап-

кыр җаваплар бирде, иҗат тәҗрибәсе белән уртаклашты. Утырыштан соң Салих абый минем янга килде дә:

— Исеңдәме, без синең белән Кустанай өлкәсенә чирәм җирләр күтәрергә барган идек,— диде һәм шул вакытта үзе төшергән берничә фоторәсем бирде.— Аннан кайткач икебез язган мәкаләне дә алып килдем, яшьрәк кешедә саклансын, бәлки, кирәге чыгар.

Хәтерләдем... 1958 елның май ахырларында Татарстан язучылар союзы командировкасын алып Казакъстанга, Кустанай өлкәсенә барган идек. Уртак мәкаләбез шул ук елны Уфадагы «Кызыл таң» гәзитендә басылды.

Барганда Уфада тукталып, башкорт язучылары белән очраштык. Ике юмор остасы Салих абый белән Сәгыйть Агиш бигрәк тә рәхәтләнеп гәпләштеләр.

— Салих, соңгы елларда мәкаләләрдә бер дә синең исемне телгә алмыйлар, нигә? — дип сорый Агиш.

— Мине һәрбер докладта, мәкаләдә искә алмыйча калмыйлар. Гел кабатланып торган обоймадан соң һ.б. (һәм башкалар) мин бит инде: һәм Батталлар.

Кич Башкорт дәүләт академия театрына чакырдылар. Спектакльне карагач, экспромт та туды:

Мостай Кәрим театрга
Чакырды безне зурлап.
«Кыз урлау»ны Казанга да
Китәрлек булдык урлап.

Әмма Татар дәүләт академия театры бездән алда ук комедияне урлаган икән. Казан тамашачылары да аны яратып караганнар.

Поездда барганда Салих абый чирәм җирләргә чакырып үзе бармыйча калган Әхмәт Ерикәйне көлеп искә алды.

«Син бу хатны безнең укыганда,
Без бик күптән юлда булырбыз.
Чирәм җирдә күкрәп иген үсәр,
Гәүдәң килеп җитмәс, онытылыр»,—

дигән Такташча экспромт та шунда туды.

Без Кустанай өлкәсендәге Димитров исемендәге совхозда. Юл буйларында ап-ак каеннар, яңа гына төшкән яшь киленнәр кебек оялып кына дала җилендә яулыкларын җилфердәтеп утыралар. Иксез-чиксез далаларны тетрәтеп йөргән якташларыбыз безне уратып алдылар.

— Сагындырмыйммы? — дип сорыйбыз.

Бондюг районыннан килгән Анна трактор кабинасыннан сикереп төште дә шаяртып:

— Сагынырга вакыт юк монда! — диде.

Фәүзия исемлесе аңа үпкәле караш ташлады:

— Сагынмаган кая ул!

Читтәрәк торган Башкортстан егете Әхнәф тә сүзгә кушылды:

— Башкасына түзәр идем түзүен — авылыбызның чишмә суын өзелеп сагындым... Төшләремә керә.

— Казаннан артистлар килгән, сагынулар, бәлки, беразбасылыр,— дип сөенеп әйтте бер кыз.

Кунакханәдән чыксак, Казанча таныш тавыш ишеттек:

— О! Казаннан шагыйрьләр килгән!

Карасак: үзебезнең Фәйзи Йосыпов белән Рәшит Ваһапов! Кочаклашып күрештек. Автографлы фоторәсемнәрен бүләк итеп, кич концертка чакырдылар. Клуб тулы милли моңга сусаган якташларыбыз. Дымлы күзләрен сөртеп алырга уңайсызланып, моң дәрьясында тирбәләләр. Ниләр уйладылар икән алар бу мизгелләрдә? Үзләре тир түккән җирләрнең киләчәктә башка дәүләттә калачагын уйларына да китермәгәннәрдер. Күпләре әле үзебезнең җир дип шунда калып, карт көннәрендә туган илләрен сагынып саргаялардыр...

Әлегә залда — чирәм җирләрне күтәрергә ашкынып килгән яшьләр. Сәхнәдә — аларның күңелен күтәрергә килгән артистлар, шагыйрьләр.

Баттал да тирән уйда... Иртән, иртүк торып далага чыгып китте.

Җиргә нык басып, пәһлеван шикелле эре адымнар белән атлый. Башы күккә тигән кебек — югары. Аякларындагы унтыларына игътибар итсәң, ул күккә күтәрелергә әзерләнгән космонавтны хәтерләтә. Әгәр галәмгә татарларны очырсалар, иң беренче Баттал очар иде дип уйлаган чак бар иде. Ул бит, чыннан да, «Казан өстеннән очканда чүп савытына төкергән» очучы. Хәзер туган тел планетасыннан махсус төшкән сәер зат кебек. Үзенчә яшәве, уйлавы, мөстәкыйльлеге белән ул безнең беребезгә дә охшамаган. Татар теленең статусын дәүләт дәрәҗәсенә күтәрү проблемасын ул бу хакта сөйләшү тыелган чакта ук күтәрде. Партия җыелышларында җитәкчеләр аңа сүз бирүдән куркалар, әмма ул трибунага рөхсәтсез чыгып, барыбер үз сүзен әйтә. Соңрак мин



Салих Баттал һәм Илдар Юзеев чирәм җирләрдә. Казакъстан, июнь, 1958

Андрей Сахаровны Салих Батталга охшаттым. Башкалар, ягъни мәсәлән, без, эчтән генә «дөрес әйтә бит, каһәр!» дип утырабыз. Әмма аны якларга беребез дә җөрьәт итми. Ул үзенең сүзләрен дәлилләү өчен Лениннан цитаталар китерә. Һич тә тыя алмагач өлкә комитет аны партиядән чыгарырга мәҗбүр итте. Үзәк Комитетның партия контроле комитетына баргач, утырып торган Батталга: «Сез Үзәк Комитетта, аяк өсте басып тыңлагыз!» — диләр. Баттал горур җавап бирә: «Минем партия алдында гаебем юк, басмыйм!» — ди. Соңыннан аны партия сафларына кире кайтардылар.

Ул үзгәрмәде, һаман туган тел өчен каһарманнарча көрәшүен дәвам итте. Ленинны инкарь итү чорында да ул үз фикеренә тугры калды.

Сәяси хата ясаудан өркеп яшәгән, 37 нче елларны коты алынган Язучылар оешмасына Баттал гел уңайсызлыклар тудыра, шунлыктан аны «дивана», «бераз авышкан» итеп күрсәтергә тырышу сизелә иде. Ул бернәрсә өчен беркемгә үпкәләми, ачуланмый, авыр вакытларында да тыштан шат күңелле булып кала, ярдәм, шәфкать сорамый. Үзеңне кызык хәлдә дә калдыра. Басарга шигырен кerткәч, кире кагасың. Ә ул «төзәттем» дип та-

гын китерә. Басылып чыккач, рәхәтләнеп көлә: «Мин аның бер өтерен дә үзгәртмәгән идем»,— ди.

Бертуган энесе Габдулла Баттал — унбер җәлилчененң берсе. Язмыш җәлилчеләр белән очраштырса, Салих Баттал да, һичшиксез, алар белән бергә гильотинага барыр иде. Хәсән Туфан бер шигырендә аны «металл хисле Баттал» дип атый. Салих абыйны бик озак еллар буе белгәнгә күрә мин моны бөгелми-сыгылмый торган көчле рухлы, хисле шәхескә әйтелгән сүз дип уйлыйм.

Шагыйрьләр остаханәсе утырышында без аны Татарстанның халык язучысы дигән исемне бирергә тәкъдим иттек. Татар поэзиясендә дә, прозасында да беркем дә какшаталмаслык үз урыны бар иде аның. «Олы юл буйлап» исемле роман-хроникасының А.Твардовский редакцияләгән «Новый мир» журналында басылуы үзе генә дә иҗатының бөтенсоюз масштабында яңгыравын дәлилләп тора.

Язучылар союзы идарәсе безнең тәкъдимне якламады. «Әлегә лаек түгел, бераз көтик» диделәр. Салих абый моңа игътибар итмәде, аңа исем бирсәләр дә, бирмәсәләр дә барыбер иде. Аңа яшәргә бик аз калган иде инде.

Ул сөйләгән мәзәк бер вакыйга искә төште: «Дачама барсам, күрәм: ишекне ватып өйгә кергәннәр. Вак-төяк әйберләрне дә урлап киткәннәр. Ярты алып барган идем, өстәлдә шуны һәм язу калдырдым: «Карак иптәшләр, әйберләрне алсагыз алыгыз, әмма ишекне ватмагыз. Менә сезгә бер ярты. Сәлам белән С.Баттал». Икенче тапкыр барсам, өстәлдә буш шешә һәм бер язу тора: «Баттал иптәш, тагын бер ярты калдырмасаң, өеңне яндырабыз. Сәлам белән карак иптәшләрең». Караклар да шагыйрьнең шаянлыгын кабул итәләр, икенче кергәндә ярты тапмасалар да, өен яндырмыйлар.

Язмыш аңа икенче янгын әзерли: сак булырга кирәклеген онытып, ул телевизорын сүндермичә йоклап киткән һәм өй эчендәге төтен аның сулышын буган, диләр.

Миңа ул соңгы төшендә үзенең хәрби очкычына ут кабып янып җиргә төшкәнен күргәндер кебек тоела. Ә холкы белән ул егылып төшә торганнардан түгел иде. Мөгаен, нәрсәнедер нишләтергәдер онытKандыр.

Җәлилче энесе белән холыклары охшашлыгын мин Габдулла Батталның һәлакәтендә дә тоям. Оешмага яңа көчләр тартырга теләп, ул ышанып бер легионерга ачы-

ла. Ә теге сатлык җан булып чыга. Габдулланы да, башка җәлилчеләрне дә кулга алалар.

Зур шәхес турындагы нәни истәлекне Баттал аганың үз шигыре белән тәмамлыйм:

Баттал икәнемне онытсам да,
Постта икәнемне онытмам!

Салих абый үзенең Баттал икәнен мәңгегә оныткан, ә мин күкләрне күкрәтеп очкан, җирләрне тетрәтеп атлап йөргән гаҗәеп шагыйрьне онытмам...

## Югалган автограф

5 июнь, 1975 ел.

Илебез буенча пароходта сәяхәткә чыккан инглиз язучысы, халыклар арасында тынычлыкны ныгытудагы хезмәтләре өчен Ленин премиясе алган Җеймс Олдриҗ Казанга туктады. Аны каршы алырга Журналистлар союзы идарәсеннән Гарәф Шәрәфетдинов, Язучылар союзыннан мин (рәис урынбасары буларак) һәм Риза Ишморат төштек. Кунак поезддан үзенең Мәскәү тәрҗемәчесе һәм хатыны белән чыкты. Ир уртасы кеше, җиңел сөякле, хәрәкәтчән. Бөеклеге кычкырып тормый, үзен бик гади тота. Кыскасы, нәкъ безнең кебек кеше... тышкы яктан караганда. Аның белән сөйләшү бик авыр булыр кебек иде, әмма тиздән күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киттек. Без аны Казан буенча йөрттек. Җәлил һәйкәленә килеп туктадык. Җ.Олдриҗ һәйкәлгә карап озак кына тын торды. Муса Җәлилне ишетеп кенә түгел, укып та белә икән.

— Җәлил инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәнең сыйфаты канәгатьләнерлек түгел. Әмма шул тәрҗемә аша да мин Җәлилнең көчен тойдым,— диде ул.

Дөньяда исәпсез һәйкәлләр күргән язучы Сөембикә манарасы һәм аңа бәйләнгән легенда белән кызыксынды.

Университетка барганда кемдер республика китапханәсенә кереп чыгуны тәкъдим итте. Язучы килгәнне ишетмәсәләр дә, китапханәдә каушап калмадылар. Олдриҗ монда да үз булып китте. Кыюрак укучылар автограф алып калырга да өлгерделәр. Уку залының мәгарә өлеше кунакка бигрәк тә ошады. Тып-тын залда укучылар тулы иде. Директор урынбасары аларга зур кунакны тәкъдим итте. Сүзне Олдриҗга бирде.

— Мин сезнең кебек үк, китапханәләрдә утырып укыган, язган кеше. Әмма сезнең китапханәгез бернинди китапханә белән дә чагыштыргысыз...

Без аңа университетны һәм Ленин музеен да күрсәттек. Мин, уңайсызланып кына, аңа үтенечемне әйттем.

— 1976 елның февралендә Муса Җәлилгә 70 яшь тула. Без сездән Җәлил турында фикерегезне язып калдыруыгызны үтенәбез. Хәзер сезнең вакытыгыз тыгыз. Озатырга төшкәч, берничә сүз язсагыз иде...

Кичке сәгать алтыда без олы кунакны озатырга «Татарстан» поездына төштек. Мин үтенечемне искә төшердем.

Аңа Муса Җәлилнең урысча җыентыгын суздым. Олдриҗ китапның буш битен тутырып, инглизчә Җәлил турында фикерен язды. Без җылы гына саубуллаштык.

«Татарстан» зур язучыны Мәскәүгә алып китте.

Мин бик сөенеп икенче көнне үк кадерле язмалы китапны «Казан утлары» журналына алып бардым һәм җаваплы секретарь Ләбибә ханым Ихсановага мактандым. Ул, бик канәгать булып:

— Минем кызым Әлфия инглиз теленнән тәрҗемә итәр, шунда ук журналга бирербез, китабыңны калдыр,— диде.

Берничә көннән килдем редакциягә. Ләбибә апабыз ни өчендер башын түбән игән.

— Ни әйтергә дә белмим... Синең алда бик уңайсыз хәлдә калдым. Син киткәч тә берничә минутка гына чыккан идем... Китапны кемдер алып киткән. Гаеплемен...

Мин дә ни әйтергә дә белмәдем. Кадерле автографның юкка чыгуына мин бары тик үзем гаепле идем. Кемгә ни өчен кирәк булды икән бу кыйммәтле музей экспонаты? Кемнең китап шүрлегендә ята икән ул?

Шулай да мин инглиз сүзләренең татарча яңгыравына өметемне югалтмыйм әле...

## *Мин — күчмә театрдан...*

Тәнкыйтьчеләрем мине поэтик драматургия вәкиле дип саныйлар. Бу алымның татар драматургиясендә үзенең традицияләре бар. Сәхнә күзлегеннән караганда, андый авторларны авырлыклар көтә: татар театры туганда ук реалистик нигездә барлыкка килгән бит. Әмма шул



«Бәхетемнән узып барышлый» спектакле премьерасыннан соң тамашачылар алдында Р.Тумашев һәм И.Юзеев. Октябрь, 1979

чакта ук реализмның бер канаты — романтик алым да канат кага. Искә төшерик: татарның беренче артисткасы Сәхибҗамал Волжская дусты Габдулла Кариев белән иҗади бәхәскә керә, аның романтик җанлы, поэтик рухлы героинялар уйныйсы килә. Реалистик сәхнәгә генә сыеша алмаган артистка Уфага күчеп китә һәм «Нур» театрын оештыра. Шунлыктандыр инде, Башкорт дәүләт академия театрында Волжская традицияләре яшәде. Ул театр поэтик драматургиягә зур урын бирә иде, баш режиссер Рифкать Исрафилов чагында минем өч әсәремне сәхнәгә мендерделәр.

Әлбәттә, реалистик театр үзенең бөек драматургларын, режиссерларын, артистларын тудырды. Һәр театрның үз иҗат юлы булуы тамашачылар өчен бик кирәк. Шуңа күрәдер татар театрын Уфада, Уфаларны Казанда үз итеп, сагынып карыйлар. Әмма шулай да соңгы елларда Казан театрларында шагыйрьләргә онытылганда бер генә ишек ачалар. Югыйсә «Янар чәчәк» исемле беренче шигъри комедиямне Камал театрында 1968 елда Празат Исәнбәт куйган иде.

Минем драматик әсәрләремә ишекне Татар дәүләт күчмә театрының режиссеры Равил Тумашев ачты. 1957 елда Татарстан радиосыннан «Таныш моңнар» поэмасы яңгырагач, радиопостановкага көйләр иҗат иткән композитор Шакир Мәҗитов миңа шул әсәр нигезендә бергәләп комедия язарга тәкъдим итте. «Мин аны сәхнә әсәре, бигрәк тә комедия итеп күз алдына китерә алмыйм» дип, мин баш тарттым. Шакир абый берүзе «Резидәкәй» дигән пьеса язды. Ни гаҗәп, аны Татар дәүләт күчмә театрының ул чактагы режиссеры Кәшифә Тумашева сәхнәләштерде. Шулай итеп, минем киләчәктә туачак драматик алымымны иң беренче аңлаучы Кәшифә Тумашева булды дип әйтә алам. Аңа алмашка килгән улы Равил Тумашев мине театрга тартып китерде. Һәр авторның үзенчәлеген, алымын аңлаучы, һәр әсәреңне җиренә җиткергәнче эшләтүче режиссер минем алты әсәремне сәхнәгә мендерде. Ул вакытта театр чын мәгънәсендә драматургларның иҗат лабораториясенә әйләнде. Р.Тумашев әзер әсәрне сәхнәгә куючы гына түгел, репетицияләрдә артистлар өчен, пьесаны куярга әзерләгәндә драматурглар өчен тәҗрибәле педагог, иҗат кешесе. Шактый өлеше шигырь белән язылган «Бөркетләр кыяга оялый» водевилен Р.Тумашев күчмә театр шартларында да тамашачыларны рухи кыяга менәрлек итеп, поэтикасын югалтмыйча куюга ирешә.

«Улыбыз өйләнә, без — аерылышабыз» исеме белән Татар академия театрында Дамир Сираҗиев куйган спектакль, гәрчә тамашачы тарафыннан яратып каралса да, андагы бөркетләр кыядан җиргә төшкән иде, шигъри өлеше прозалашкан иде.

Аннан соң бер-бер артлы «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан», «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?», «Онытылмас бәет», «Бәхетемнән узып барышлый» дигән пьесаларымның Р.Тумашев тарафыннан куелуы — драматург буларак минем күчмә театрдан башка режиссерга күчмәү чорым. Ул пенсиягә киткәч, минем күчмә тормышым башланды...

## *Казан каласына кунак килгән...*

1 июль, 1970 ел.

Казанга килгән шагыйрь Евтушенконы Чаллы төбәгендә озатып йөрергә миңа тапшырдылар. «Свердловск» теплоходында барабыз. Ул 14 нче, мин 13 нче каютада.

Хәтере бик яхшы. 26 июньдә язучылар дачасында сабантуй үткәргән идек. Язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов Евтушенконы да алып килде. Ярышларда катнашып, чүлмәкне челпәрәмә китерде. Бәлки, астан бераз күргәндер, кунак кеше бит, аның җиңүен бик теләгән идек. Капчык тотып та сугышты. Фәрваз Миңнуллин белән көч алышты. Көрәш ике якның да җиңүе белән тәмамланды. Зур кунакны бәреп төшерүнең әйбәт түгеллеген Фәрваз аңлады, әлбәттә. Без дә канәгать калдык. Мин, сабантуйны музыкаль яктан ямьләндерергә тырышып, гармун уйнап йөргән идем. Евгений Александрович моны да онытмаган икән:

— Синең музыкаль слухың әйбәт, көйләрне матур уйныйсың. Мин татарның «Карурман» җырын яратам.

Аның белән бик тиз бер-беребезгә ияләшеп киттек. Ул юлда эшләргә теләвен белдерде.

— Мин шау-шудан, бәйрәмнәрдән туям. Ялгыз калырга тырышам. Шундый чакларда язам.

Икенче көнне иртәнге аштан соң бик озак бикләнеп эшләде. Төшке ашка керсәк — ресторан бикле. Буфеттан алып минем каютага кердек. Шунда ул минем иҗат белән кызыксынды. Уңайсызланып кына Н.Беляев тәрҗемәсендә рус телендә чыкан «Последнее испытание» поэмасын күрсәттем. Ул аны каютасына кереп укыган. Соңыннан Чаллыдан Казанга самолетта кайтканда, поэма турындагы фикерен язып, үземә бирде. Менә ул: *«Поэма Ильдара Юзеева «Последнее испытание» является интересной попыткой раскрыть образ Мусы Джалиля не с точки зрения абсолютной конкретности, которая иногда ограничивает возможность автора, пишущего на историческом материале — а с точки зрения философского осмысления полицейской тирании, диктатуры с ее ненавистью ко всему живому, светлому. Борьба полицейской диктатуры, уничтожение ею лучших людей человечества это естественная самозащита дик-*

*татуры, ибо любой революционно мыслящий человек — угроза для ее существования. Думаю, что вполне закономерно для раскрытия этой мысли введение образа Мефистофеля — образа соблазна, искушающего человеческие слабости и часто заставляющего падать слабых духом. Вместе с тем поэт избежал и излишней абстрактизации, оторванности от реального Мусы Джалиля и в данном раскрытии Муса предстает не только как герой прошлого, но и герой настоящего и будущего — ибо борьба против мракобесия, реакции бессмертна.*

*Перевод Н.Беляева добросовестен и за исключением некоторых поспешностей раскрывает мысль поэмы.*

*3 июля 1970 г.*

*Евгений Евтушенко»*

Сәгать дүрттә Чаллыга килеп төштек. Безне шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Беляев һәм журналистлар каршы алды.

Евтушенко, программада булмаса да, Алабуга шәһәрен күрәсе килүен белдерде.

Иртәнге җидедә, райком «газиг»ына утырып, паромда Каманы кичеп, Алабуга каласына киттек. Райкомның пропаганда секретаре Митрофанов көтелмәгән кунак килүгә аптырап, каушап калды. «Безгә сезнең киләсене әйтмәделәр» диде. Шулай да тиз генә экскурсовод таптылар. Тарихи собор эченә кердек. Аны дивардагы рәсемнәр кызыксындырды.

— Йомшак ягым — бөтен өйне картиналар белән тутырдым. Пикассоның үзе бүләк иткән картина да бар.

Н.Дурова һәйкәлен карадык. Хәзерге педагогия институты бинасы аңа бигрәк тә ошады. Аны купец Астахиев салган икән.

Шагыйрьне монда иң нык тартканы Марина Цветаева булып чыкты.

— Мин дүрт телдә сөйләшә беләм. Бик күп хатын-кыз шагыйрьләренең иҗатын үз телендә укып беләм. Шулар арасында иң зурысы — Марина Цветаева. Бөек шагыйрь.

— Ә Анна Ахматова?

— Ул аристократчарак, изысканныйрак шагыйрә.

Менә без соңгы көннәрендә Цветаева яшәгән йортка



Рәсемдә: РСФСР язучыларының VI съезды. Кремль. Уңнан икенче: Рәис Беляев

килеп кердек. Кечкенә генә иске йорт. Карт белән карчык. Чал чәчле әби бик аз сөйли.

— Безнең өйгә ул үләренә ун көн кала гына килде. Мин аны әллә ни белмим дә. Хәтеремдә, Марина тәмәке төрә белми иде. Мин аны тәмәке төрергә өйрәттем. Үләсе көнне кәефе юклыктан зарланды...

Карчыкның бөтен истәлеге шуннан гыйбарәт. Ишек,— алды чоланындагы матчада зур кадак. Марина әнә шул кадакка асылынган.

Маринаның каберенә алып бардылар. Төгәл урыны билгеле түгел. Бер карчык күмәргә барган икән, якынча урынын күрсәтеп калдырган. Кабер өстенә тәре кагылган, такта һәм ташлар өеп куелган. Тактага кемдер карандаш белән язып киткән: «Поэты, поставьте памятник!»

Шагыйрь, бер чәчәк өзеп алып, кабер өстенә салды.

Кайтышлый, Тарловка санаториена кереп, кымыз алып чыктык. Паромга соңга калдык, бер сәгать көтәргә туры килде. Шагыйрьне ялгыз калдырдык. Кама буендагы комлыкта кызынып, уйланып яттык.

Кайтып бераз ял иткәч, безне Кама буйлап катерда алып киттеләр. Чаллы ягында туктап коендык. Евгений

физик яктан бик таза, ыспай, үзен саклый, корсагы бүлтәеп чыгудан курка.

— Сиңа, Илдар, корсагыңны киметергә киңәш бирәм.

Колач салып йөзә. Озын. Мин аның янында бөтенләй бәләкәй буйлы булып калам. Аягы — 56 үлчәмле.

— Женя, әйт әле, ни өчен зур шагыйрьләрнең аяклары да зур була?

— Җирдә нык басып тору өчен!

Кайчак, хыялына ирек биреп, Остап Бендерча, балаларчарак, чит ил сәяхәтләре турында сөйләп китә. Аңа арттырмыйча да сөйләргә була, югыйсә егерме ике илне гизгән бит!

— Шулай Амазонка елгасы буйлап барганда...

— Мексикада танылган киноактриса белән машинада барганда миңа мылтыктан атып һөҗүм иттеләр...

Дөнья күрү, король белән дә, министр белән дә, танылган шәхесләр белән аралашу, әлбәттә, аның карашын, фикерләү офыгын киңәйткән, баеткан. Ул һәрнәрсәгә бәя биргәндә төрле илләр белән чагыштыра ала. Шуның белән бергә аның җиңелчәрәк карашлары да сизелеп кала. Хуҗалык өлкәсендәге кимчелекләрне ул тиз генә көйләмәкче...

Программа буенча чыгыш ясау каралмаган, ул шәһәр һәм төзелешләр белән танышырга тиеш иде. Шулай да комсомол җитәкчеләре аның чыгыш ясавын үтенделәр. Бүген «Чулпан» кинотеатры ачыласы көн. Кичке җидегә заманча, милли үзенчәлеккә ия булган өр-яңа кинотеатрга киттек. Залдагы яшьләр шагыйрь катнашасын белмиләр. Рәис Беляев иң беренче сүзне Евтушенкога бирде. Аның миңа әйткән теләге бар иде:

— Минем яшьләр янына кереп, алар белән шәраб эчеп рәхәтләнеп сөйләшеп утырасым килә. Ә мине начальство урап алган.

Сәхнәдә — суда йөзгән кебек. Шигырь стихиясенә бирелә. «Братская ГЭС»тан «Нюша» дигән бүлекне егерме биш минут яттан сөйләде. Элекке килүендә мин аның «Казан университеты» поэмасын күңелдән сөйләвенә сокланган идем.

— Женя, ни өчен бу бүлекне сайладың? — дип сорыйм.

— Мондагы яшьләр дә Братская ГЭСны төзегәндәге кыенлыкларны кичерәләрдер дип уйлыйм.

Сөйләүдән туктагач, мин аны котладым.

Ул:

— Сизденме, мин бүген йомшаграк сөйләдем. Ни өчен дисеңме? «Братская ГЭС»ны язып бетергәч, мин аны төзүчеләр алдында өч сәгать ярым тәнәфессез сөйләдем. Армыйча тыңладылар. Балаларга ясле дә юк дигән сүзләрне әйткәндә, берничә ана баласын өскә күтәрде. Бу юлы канәгать түгелмен...

Кул чабуларга караганда, яшьләр бик канәгать иде.

Рәис Беляев, рульгә үзе утырып, безне Түбән Камага алып китте. Кич безне кунак йортындагы иң шәп бүлмәгә урнаштырдылар. Евгений мондагы шәһәр комитетының башлыгын өнәмәде.

— Шәһәрдәге иллюминация белән мактанып тәмам теңкәгә тиде.

Иртәнге унда Түбән Кама химкомбинатына алып бардылар. Аңа кадәр автозавод һәм ГЭС төзелеше мәйданы белән таныштырганнар иде. Шунда йөргәндә, бушрак вакытын туры китереп, берничә сорау биргән идем. Кайбер фикерләрен блокнотка теркәп куйганмын.

— Хәзер минем яза алмыйчарак йөргән чагым. Бөтен илһамымны, көчемне «Казан университеты»на бирдем. Хәзер бушап калдым. Шагыйрьдә шундый кризислар була. Икешәр ел язалмыйча йөрисең. Нишләптер прозага тартылам. Тәнкыйть мәкаләләре язарга исәплим.

— Пушкин — шагыйрьләр арасында дөнья күләмендә иң бөеге. Лермонтов — лирик кына. Ә Пушкин — лирик та, сатирик та, драматург та, прозаик та...

— Роберт Рождественский соңгы вакытта йомшак шигырьләр яза башлады. Аның үзенең дә яше бара. Тормыш яңа зур проблемалар куя. Ә ул хәзер спорт шигырьләре язудан күтәрелә алмый.

Безне баскычлар буйлап баш әйләнерлек биеклеккә, корпус түбәсенә алып менделәр. Манзара — гаҗәп көчле. Кешенең кодрәтенә сокланасың.

Шагыйрь:

— Дулкынландырырлык, тәэсир итәрлек күренеш! Дөрес, мин химияне белмим. Бу — миңа Марс планетасы кебек серле!

Сәгать унбергә Чаллыга кайтып, безне аэропортка илтеп куйдылар.

# Мәңгелектән илаһи аваз

Без инде беләбез, Тукай әйткәнчә, кеше үзенең бөек икәнен үлеп кенә аңлата. Рөстәм Яхин да үзебезнең арада беркемнән аерылмыйча, бөек икәнен үзе дә белмичә тыйнак кына йөрде. Без аны сәхнәдә бик оста рояль уйнаганда да, җыелышларда дәшми генә башкалар арасында утырганда да күрә идек.

Мин аның белән якыннан аралашып яшәгән кеше түгел. Безнең иҗади мөнәсәбәтләребез берничә җыр язудан гыйбарәт. Җәлилчеләргә багышланган «Унике аккош» шигыремә ул үз теләге белән музыка язды. Ул җырны Римма Ибраһимова башкарды. «Ай сонатасы» дигәнен композиторга үзем бирдем. Ул җыр Татарстан радиосы фондында саклана, сирәк кенә башкарыла. Шулай ук ул минем шигырьгә балалар өчен «Юлга чык» исемле җыр да иҗат итте.

Татарстан радиосында сәнгать советының әгъзалары буларак, без Рөстәм Яхин белән еш очраша торган идек. Ул үзе ошатмаган көе турында да каты, усал итеп әйтмичә, кешенең хәтерен калдырмыйча кире кагу юлын таба иде.

Миңа берничә тапкыр Рөстәм Яхин белән бергә җыр конкурсларында жюри әгъзасы буларак катнашырга туры килде. Конкурсларның берсе Татарстанның юбилеена багышланган иде. Йомгаклау утырышында Сибгат Хәким һәм Мәхмүт Нигъмәтҗановларның сөйләве истә калган. Алдагы урыннарга чыккан авторларның исемнәрен белмичә бәхәсләшәбез. Мәхмүт Нигъмәтҗанов «Туган ягым» дигән җырны беренче урынга чыгару ягында:

— Бу җырның музыкасы гимн кебек, лирика да, тантана да бар.

Сибгат Хәким белән мин башкарак фикердә:

— Музыканың көчле булуына кушылабыз. Әмма сүзләре безне канәгатьләндерми, профессиональ шагыйрь язганга охшамаган,— дибез.

Тавыш биргәндә «Туган ягым» җыры җиңеп чыкты. Авторы — Рөстәм Яхин! Сүзләрен Рамазан Байтимеров язган икән. Шуннан соң без Сибгат Хәким белән җырның текстын редакцияләдек, төзәттек, строфаларның урыннарын да үзгәртергә туры килде. Җыр көйләнде шикелле.



(Сулдан уңга): Рөстәм Яхин, Венера Шәрипова, Мөхәммәт Гайнуллин, Илдар Юзеев, Эмиль Җәләлетдинов. Җаек елгасында. Июнь, 1964

Хәзер Рөстәм Яхинның шул җыры, сүзләреннән башка, гимнга әверелеп, һәр иртәдә өйләребездә яңгырый.

1964 елның июнендә, чакыруларын кабул итеп, Уральски каласына бардык. Делегация составында Рөстәм Яхин, профессор Мөхәммәт Гайнуллин, җырчылар Венера Шәрипова һәм Эмиль Җәләлетдиновлар бар иде. Кала хезмәтчәннәре белән искиткеч җылы очрашудан соң, безне Җаек (Урал) елгасы буйлап күңелле сәяхәткә алып чыктылар, хөрмәтләп кунак иттеләр. Хуҗалар берничә җыр башкаруны сорагач, Венера ханым Рөстәм Яхинның «Дулкыннар»ын шулкадәр илһамланып җырлады — без сихри дулкыннар иркендә тибрәлеп, могҗизалы мизгелләр кичердек.

Чыннан да, Рөстәм Яхин үзенең тылсымлы, затлы көйләре белән миллион күңелләрне дулкынландыра. Ул калдырган дулкыннар мәңгелектән илаһи аваз кебек!

* * *

«Илдар Юзеевның нинди шагыйрь, нинди шәхес булуын үзем аңлаганча укучыларга сөйләп бирер алдыннан иң әүвәл аның гармунчы булуына тукталып китәсем

килә. Илдар — гармунчы берәүне дә кабатламый. Баян дип тә пошмый ул, аккордеон дип тә авыз суын корытмый, аның иң яратып уйнаган гармуны — хромка. Казан фабрикаларында ясалган гадәти генә, күрер күзгә әллә ни зур да булмаган гармун Илдар кулына килеп эләктеме — үзгәрә дә китә. Илдар белән гармун бер җан, бер тән булып китәләр. Илдарның борын канатлары киерелә, башы гармун өстенә ята, ә бармаклары, озын ак бармаклары гармун телләрендә бии. Мондый чакта тирәюньдәге кешеләр дә, йортлар да, урман-сулар да, зәңгәр күлләр дә онытыла. Шундый да бирелеп, шундый да бер ихласлык белән уйный Илдар гармунны, андый сәгатьләрдә дөньяда моң гына яши, тоташ бер агынты булып агылган, җаннарны айкый торган моң гына кала...»

*«Кыядагы бөркетләр»дән,*
*Гариф Ахунов, 1982*

## Чаба гомерем көзләргә



Гариф Ахунов, Илдар Юзеев. 1984

Юнәлдек Әлмәткә таба,
Узып барабыз Зәйдән.
Табигать тә көзгә чаба —
Китәбез иркә җәйдән.
Икебез дә ямансулар,
Нигә икән, нилектән?
«Сагынганда уйна!» диеп,
Гармун алдың кибеттән.
Мин уйнадым, син җырладың
«Олы юлның тузанын».
Инде, Гариф, синсез генә
Гармуныңны сузамын.
Иң кадерле төсең итеп
Саклыйм мин бүләгеңне,
Әллә гармуның эченә
Салдыңмы йөрәгеңне?
Чаба гомерем көзләргә,
Йөрәктә — сизелерлек.
Ул да җырлый синең көйне —
Күреге өзелерлек...

## Фасил симфониясе

Туган авылына майда
Үзенең музеена,
Исән булмаса да, Фасил
Чакырды Юзине дә.
Бик күңелле чырылдашып,
Көткәндәй шуны гына,
Кошлар да килеп кундылар
Электр чыбыгына.
Якында гына болытлар
Өстән, баш очтан килеп,
Яшенләде, дөбердәде,
Симфониясе кебек.
Сөенешеп килделәр дә
Фасил укыган өйгә,
Бии башлады тамчылар
«Чабата» дигән көйгә.
Күңелле дә, ямансу да
Һәм килә сөенәсе.
Табигатьтә, җанда яши
Фасил симфониясе!

*Кукмара районы, Салтык — Ерыклы авылы*
*27 май, 2001*



Фасил Әхмәт, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев. 1989

## Фасил Әхмәт мәзәге



Фасил Әхмәт, Рәшит Имаш, Владимир Ильич. 1981

Нишләтәсең — туганда ук
Бөек булып тугачтын...
Әгәр шик булса, сорагыз
Владимир Ильичтан.
Әгәр җавап бирәлмәсә,
Сора Рәшит Имаштан,
Әгәр ул да ык-мык килсә,
Даһи Шостаковичтан.
Очраштык та бергә йөргән
Чакны искә... төшердек,
Истәлеккә өчебезне
Бер рәсемгә төшердек.
Киметмим дә, арттырмыйм да,
Чынын сөйлим, билләһи!
Фактически бу рәсемдә
Ике бөек, бер даһи!

## Ике очрашу

1998 елның кышында Татар яшьләр театрының артисты Нуриәхмәт Сафин гастрольләрдән кайткач мине эзләп тапты. «Синең «Хуш, Хәйбуш!» комедиясен Апас районында күрсәтеп йөрдек,— диде ул.— Йомралы авылындагы спектакльдән соң яныма ирле-хатынлы Рәшит һәм Рушания килеп, сиңа шушы хатны тапшыруны үтенделәр».



«Таныш моңнар» басылып чыккан вакыт. 1955

Хатта шундый сүзләр язылган иде:

*«Илдар, 1958 елның җәй айлары иде. Сез Йомралыга командировкага килгәч, без-*

*дә кунып киткән идегез. Кызыбыз Резидә туган гына, Сезнең «Таныш моңнар» поэмасы чыккан еллар иде. Шул исемне ошатып, кызыбызга да кушкан идек. Сез бишектәге кызыбызга карап торып, шигырь язган идегез.*

*Резидәкәй сеңелем,*
*Бишегеңдә*
*Берни белми көлеп ятасың.*
*Еллар узар,*
*Син дә бу тормышта*
*Резидәдәй чәчәк атарсың.*
*Менә тиздән*
*Бишегеңнән сикереп*
*Син төшәрсең, тәти Резидә.*
*Яшьлегеңнең янар балкышларын*
*Күргән кебек булдым йөзеңдә.*
*Син үсәрсең,*
*Илдар абыең язган*
*«Резидәкәй» көен көйләрсең.*
*«Мин бишектә идем,*
*Миңа шагыйрь абый*
*Шигырь язган» диеп сөйләрсең...*

*Ул кыз хәзер Мәскәүдә (Сезне бер баруыгызда күргән бугай) 4 нче управление (Кремль) больницасында рентгенолог булып эшли.*

*Сәлам белән Рәшит, Рушания.*

*14 февраль, 1998»*

Искә төште: 80 нче елларда Мәскәү татарларының Измайлов паркындагы сабан туенда шигырь сөйләгәч, минем янга бер сөйкемле кыз килгән иде. Ул үзен Резидә дип таныштырды һәм муенындагы медальоннан кәгазь алды:

«Илдар абый, мин туган елда Сез безгә кергәнсез һәм миңа багышлап шигырь язгансыз. Мин аны кадерләп һәрвакыт үземдә йөртәм. Гомерем буе шигырь яраттым. Хыялым Сезне бер күреп рәхмәт әйтү иде», — диде.

Шул көнне миндә: «Их, мине бөтенләй белмәгән кызлар да медальоннарында йөртерлек шигырь язасы иде!» — дигән теләк-уй туды...

## Бала казлар иярерме?

Быелның февраль аенда Казан театр училищесыннан педагог-режиссер Хәлил Мәхмүтов шалтыратты. Ул җитәкләгән группаның соңгы курс студентлары минем «Онытылмас бәет» драмасы буенча әзерләнгән диплом спектакле күрсәтәләр икән.

Искә төште: «Онытылмас бәет»не 1981 елда Татар дәүләт республика күчмә театрында баш режиссер Равил Тумашев куйган иде. Театрда барган спектакльләрем арасында иң үкенечлесе шул булды: Вәдүтне уйнаучы артист Фәрит Мәмәш академия театрына күчү сәбәпле, «Онытылмас бәет» сәхнәгә башка менмәде, бары тик илле тапкыр гына күрсәтелеп калды. Югыйсә спектакльне комиссия дә, тамашачылар да яратып кабул иткәннәр иде. Анда «Кыр казлары артыннан» драмасы белән зур уңыш казанган Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар уйнады бит. Мәсгут Имашев язган җыр шунда ук халыкның популяр җырына әйләнде.

Диплом спектакленә шик-борчу белән бардым: егерме ел үткәннән соң әсәр актуальлеген югалтмаганмы, бүгенге тамашачыны дулкынландырырлык көчен саклаганмы? Булачак артистларның уены да, педагоглары Хәлил абыйларының иҗаты да мине дулкынландырды, хәтта кайчак күз керфекләрем дымланып алды. Вакыйгага эченә кереп, ихлас ышанып, ышандырып уйныйлар. Комиссиянең фикерен белмим, ә тамашачылар юк. Җанда барыбер борчу калды: бүгенге тамашачы ничек кабул итәр?

Вакыйгада сельпо рәисе Вәдүт халык байлыгын урлап, булачак хатыны Хәтимәне авырлы хәлдә калдырып китеп югала. Бик озак еллардан соң, хөкем ителү вакыты узгач, туган авылына кайтып, кызына һәм оныгына бөтен байлыгын калдырачагын әйтә. Балалар мондый мирастан баш тарталар. Егерме ел элек тамашачы тулысынча балаларның мораль хаклыгын хуплады һәм рухи теләктәш булды. Ә хәзерге замандашларыбыз арасында рухи гарипләр — акча коллары күбәюен беләбез. Алар мондый мирастан баш тартыр иде микән?

Шуңа сөендем: режиссер абыйлары булачак артистларга урланган байлыктан баш тартырлык хисне сеңдергән, алар чын күңелдән, ялганламыйча уйнадылар.



Мәсгут Имашев, Исламия Мәхмүтова, Илдар Юзеев

Күз генә тия күрмәсен, Алла бирсә, бу яшьләр бернинди ялган байлык артыннан кумыйча, Мәхмүтовлар юлыннан — Исламия һәм Хәлил юлыннан китәчәкләр дип инанам. Шуны да уйладым: Исламия дә, Хәлил дә тормышта югалып кала торган шәхесләр түгел, икесенең дә зур-зур урыннарда күп акча алып эшләрлек сәләтләре, оештыру көчләре бар. Әмма алар табигать биргән талантларына хыянәт итмичә, театр сәнгатенә хезмәт итү юлын сайлаганнар. Яшьлек хыялларына тугры калган кыр казлары алар — мондый авыр юлга кузгалырга чакырмасалар да, артларыннан бала казлар да, бала кызлар да ияргән. Мәхмүтовлар гаиләсе — үзе бер театр коллективы, алар өчен генә бер сәхнә әсәре язарлык!

Ә башка бала казлар ияреp микән әти-әниләре артыннан? Училище педагогларының әйтүенә караганда, артистлыкка дип укырга килүчеләр елдан-ел азая бара икән. Бигрәк тә сәнгатькә килүче ир балаларның саны кими. Әдәбиятта бу бигрәк тә көчле сизелә. Шигырьгә килергә омтылучыларның туксан проценты — кызлар...

Алар да, кулларына ник каләм алуларына үкенеп, драматик язмышка дучар булып минем героиням Ясминә кебек, хыялларыннан аерылып җырламасылармы?

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам...
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан...

## Бутыйлар...

Мине еш кына кем беләндер бутыйлар...

Урта мәктәптә укыганда, күрше авылга Сабан туена баргач, әзмәвердәй көчле бер егет мине кыйнап кайтарды. Нил абый белән бутаган. Абыйны яратып йөргән кызга күзе төшкән икән.

Шәүкәт Галиев белән бутауларын әйтеп тә тормыйм инде. Чаллы мәктәбенә очрашуга баргач, әдәбият укытучысы безнең биографияләрне бутады. Мин Шәүкәт, ул — Илдарга әйләндек. Әмма моңа сөендек кенә: мин Андерсен премияле, дүрт балалы, биш оныклы, җитмеш яшьле Шәүкәт булдым. Ул да отты: биш яшькә яшәрде.

Тагын бер бутауга туган ягым Яңавылга кайткач дучар булдым. Тирә-якка «Илдар Юзеев үлгән...» дигән хәбәр таралган. Моны ишетеп, таныш журналист өебезгә йөгереп килде. Алдында мине күргәч, ул телсез калып, ава язды: «Син үлмәдеңмени?» — дип, чак-чак әйтә алды. Мине узган төндә хастаханәдә вафат булган туганым белән бутаганнар.

Исән булуыма ышанмаучылар әле дә бар. Бер танышым үзенең кызына «Илдар Юзеевны күрдем» дигәч: «Без бит аны программа буенча үтәбез, ул исәнмени?» — ди икән.

Бутауның иң көчлесе дәваланып ятканда булды. Хастаханәдә — карантин. Беркемне дә үткәрмәсен дип, ишеккә бик тә усал, бик тә зәһәр хатынны куйганнар. Берзаман күрәм: баш очымда Шәүкәт басып тора. «Ничек үттең? — мин әйтәм,— аннан бит чебен дә уза алмый...»

«Синең фамилияңне бөтен дөнья белә икән, малай»,— ди дустым.— «Юзигә!» — дип әйтү белән: «Пожалуйста!»

Аны озаткач, теге хатын янына төштем. «Рәхмәт инде сезгә: «Юзи» диюгә, палатага үткәргәнсез...»



Шәукәт Галиев белән Татарстан язучыларының съездында. Февраль, 1965

Йөзенә ачулы төс чыгарып, ул миңа болай диде: «Какой-такой Юзи! Знать не знаю! Мин аны УЗИга җибәрдем».

УЗИ — бөтен дөньяга танылган япон аппараты икән. Менә шулай. Мине гел бутыйлар.

Тәнкыйтьчеләр генә «әдәбиятта Юзине беркем белән дә бутау мөмкин түгел, ул үзе булып калды» дигән булалар.

Шулай була күрсен!

## Алабуга зиратында туган шигырь

1977 елда Алабуга педагогия институтына студентлар белән очрашуга баргач, язучы Эдуард Касыймов мине урыс зиратына алып килде:

— Беләсеңдер инде, Марина Цветаева сугыш вакытында Алабугада яшәгән. Бу сүз аңа бик туры да килми инде. Кая инде яшәү... Аңа беркайда да эш бирмәгәннәр. Сыра залында савыт-саба юучы булып эшләргә мәҗбүр булган. Үзе торган карт белән карчыкның өендә асылынган. Озак эзләгәннән соң без аның каберен таптык. Аны күмгәндә берничә карчык озата. Исән калучы бер


Зиратта Ә.Касыймов белән

урыс хатыны «шушы тирәдәрәк» дип, менә бу урынны күрсәтте.

Соңрак «Новый мир» журналында Сергей Липкинның Цветаевага багышланган бер шигырендә:

«Далеко, далеко Елабуга
И татарская та веревка»,— дип, шагыйрәнең үлемендә татарларны гаепләргә тырышуын укып, бик гаҗәпләнгән идем. Ул чорда фронтка китүдән бронь алып, Алабуга һәм Чистайда яшәүче урыс язучылары нигә ярдәм итмәгәннәр соң хәзер бөек дип танылган шагыйрәгә?

Шул шигырьгә җавап рәвешендә язылган «Татар бавы» дигән шигырьдән ике строфамны укып карыйк.

Авыр бер чор, сугыш гарасаты
Маринаны монда китергән.
Хәзер кемне, кемне гаепләргә?
Сорыйк әнә Чулман, Иделдән.
Кем ишсә дә, бауның милләте юк,
Сылтамагыз аны милләткә!
Һәрбер телдә бер сүз: шәфкатьсезлек
Шагыйрәне илткән әлмәккә...

## *Без — кемнәр?*

Кадерле райондашлар!

Сезне сагынып кайтсам да, аерылсам да, синдә узган бала чагымны, яшьлегемне уйласам да, күңелдә ургылып җыр туа. «Кайтам инде» җыры сезне сагыну билгесе, «Туган ягым каеннары» сездән аерылу сагышы.

Күптән инде уйланам: ни өчен Яңавыл хис һәм акыл ияләрен юмарт тудыра икән? Әллә берәр без белмәгән хикмәте, тылсымы бар микән моның? Тауларыбыз, ту-




Якташлар белән Яңавылда. 27 июнь, 1996

гайларыбыз, урманнарыбыз нинди серләрен бездән яшереп яталар икән?

Бу хикмәтнең бер серен мин Йөгәмәш тавы турында бабаларыбыз калдырган риваятьтән таптым сыман. Исегезгә төшерәм:

«Безнең якның бер сунарчысы Йөгәмәш тавындагы күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да (ә ул соңгы үрдәк булган), пешереп ашарга ниятләп, ут өстендәге казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, Серле Үрдәк казаннан күтәрелеп, зәңгәр күккә очкан. Шул көннән соң Йөгәмәш тавының күле кипкән...»

Соңгы Үрдәкне аткан сунарчы да, яралы Үрдәк тә — безнең як адәмнәре. Гасырлар дәвамында Явызлык белән Гүзәллек арасында тартыш барган. Ашау өчен генә яшәүчеләр, корсакларын канәгатьләндерергә теләп, Гүзәллек ияләрен атканнар, кисәннәр, төрмәләргә япканнар. Әмма Гүзәллек барыбер исән калган, Серле Үрдәк булып, Күккә күтәрелгән.

Менә без — кемнәр! Без — Йөгәмәш үрдәкләре! Без — шул нәселдән!

Аучы якташларым әйтерләр: «Ярый, агай, син үрдәк ашама, җырлап кына яшә, алайса!» — диярләр. Юк, баба-

ларым шикелле минем ашап та, җырлап та яшисем килә. Риваятьтә сүз гади бер кошны ату турында бармый. Аучы табигатьнең җанын, иясен — соңгы Үрдәкне аткан.

«Гашыйклар тавы»н язганда бу риваять миңа ачкыч булды.

Аучыларың да тук, Серле Үрдәгең дә исән булсын, Яңавылым!

Мин синең ачлыкта да, туклыкта да сынатмавыңны, Йөгәмәш үрдәге булып калуыңны телим!

## Ерактагы кәккүк авазы

Соңгы елларда опера жанрындагы кризисны ничек аңлатырга? Безнең менә дигән җырчыларыбыз, биючеләребез, музыкантларыбыз җыйналган, Муса Җәлил исемен йөрткән, академия дәрәҗәсенә ирешкән опера һәм балет театрыбыз бар. Шуның өстенә иң катлаулы жанрларда да иҗат итәргә сәләтле композиторларыбыз, шагыйрьләребез бар. Ә тамашачыларыбыз операга сусый... дип әйтер идем, ышанмассыз, чөнки халкыбыз күптән инде бу жанрдан читләште, суынды. Әллә кайчангы «Башмагым» музыкаль комедиясе һәм «Алтынчәч» операсы белән кычкырып туктаусыз мактана-мактана, тавышларыбыз карлыкты, горурланып суга-суга, күкрәкләребез авыртып бетте. Операның бөтен җәмәгатьчелек, дәүләт оешмалары кызыксынган, даими кайгыртткан бәхетле чоры матур бер төш кебек кенә еракта калды. Бу мөһим өлкә гомуми гамьсезлек агымында беркемгә дә кирәкмәгән, хәтта театр үзе дә суынган ятим балага әверелде. Опера кыюрак, тәвәккәлрәк иҗатчыларның активлыгына гына бәйләнгән булып калды.

Ничек терелтергә, ничекләр җан өрергә, кузгатырга сине, Габәшиләр, Мозаффаровлар, Җиһановлар, Җәлилләр, Бурнашлар нигез салган милли операбыз? Нинди юллар табып уятырга, сүнә барган учакны дөрләтеп, шуның тирәсенә җыйнарга сезне, суынган тамашачылар?

Менә шундый борчулы уйланулар мине сәнгатьнең иң авыр жанрына тартты да. Ниятнең талантлы, кыю йөрәкле композитор Рәшит Кәлимуллин белән тәңгәл килүе һәм баш режиссер Валерий Ракуның безгә теләп кушылуы нәтиҗәсендә, ниһаять, «Ерактагы кәккүк авазы» туды.



Рәшит Кәлимуллин белән. 1987

Узган чорга әйләнеп кайтып, без тамашачыларның уен бүгенге көн проблемаларына юнәлтәбез.

Бәхетле булып дөньяда
Гамьле яшәү өчен яралдык.
Хәят гел, мәңге тар булыр
Өстенлек итсә яманлык...

Кешелек тарихы яманлык белән матурлык, җимерүчеләр белән төзүчеләр тартышыннан гыйбарәт. Кемнәрдер кайчандыр тормыш корганнар, җирне, кешене гүзәл итү нияте белән төзегәннәр, иҗат иткәннәр. Ә кемнәрдер җимергәннәр, кешенең матур казанышларын хәрабәләргә әйләндергәннәр. Вакыйга Болгар чорында, безнең көннәрдә һәм, фаҗигане караганнан соң уйланмасаң, киләчәктә дә булуы ихтимал...

Җиңел эстрада музыкасына гына көйләнгән тамашачыларыбызның кайберләре операны кабул да итмәсләр, бәлки... «Татарга рок-музыка ят, нигә аны кертергә?» дип уйлаучылар да бардыр. Опера, гомумән, безнең милләтебезгә авыррак бирелә торган жанр. Рок-опера дигәч, мин үзем дә башта шүрләбрәк калган идем. Анда бит

рок алымнары, нигездә, явызлык, яманлык, җимерү күренешләрендә мул кулланыла, шуның белән аклана да... Әмма спектакльләрдә залның буш булмавы, аншлаг белән баруы һәм алкышлап каршы алынуы шик-шөбһәләрдән арындырды. Санкт-Петербургтан чакырылган милләттәшебез Альберт Әсәдуллинның һәм үзебезнең Венера Ганиеваның уеннары спектакльне күтәрде. Мәскәү тамашачылары да операны яратып карадылар. Әмма ни өчендер операны сәхнәдән алып ташладылар.

Рәшит белән ике ел иҗат иткән әсәребез чынлап та ерактагы кәккүк авазы булып калыр микәнни? Элек куелган һәр репертуардан алынган башка опералар кебек...

## «Хуш» дип әйтәлмәдем...

Соңгы елларда мине аңлаучы иҗат дустым режиссер Ленар Садриев иде. Минзәлә театрында «Безнең әти — мировой», Тинчурин театрында «Гашыйклар тавы»н сәхнәгә мендерде. Ленар дипломга ия булган югары белемле тәҗрибәле режиссер, шул ук вакытта талантлы артист та иде. Гаиләсе Казанда булса да, шәхси тормышына зыян китереп, озак еллар Әлмәт һәм Минзәлә театрларында баш режиссер хезмәтендә янып-көеп эшләде. Бөтен гомерен сәнгатькә багышлап, өлкәнәеп, ниһаять, Казанга кайтты һәм... кирәксез бер кешегә әйләнде. Иҗат дәрте сүнмәгән фидакарь Ленарга эш бирмичә газапладылар. Югыйсә режиссерлар болай да бармак белән генә санарлык бит инде. Соңгы елларда Казан татар яшьләр театрында штатта саналса да, чын иҗади эштән мәхрүм ителде, эпизодик рольләрдә йөрттеләр. Йөрәгенә ятышлы әсәр куясы килә иде аның! Минем «Хуш, Хәйбуш!» комедиясе аның иң соңгы спектакле буласын кем уйлаган! Уңышлы барса да, аны репертуардан алып ташладылар.

Үзенә урын табалмыйча йөрәге авыртканда, Ленар Казаннан ераккарак, Яшел Үзәндәге туган апасы янына китә иде. Соңгы китүендә «Хуш, Ленар!» дип тә әйтәлмәдем.

Яшел Үзән поездына барганда, аның йөрәге тибүдән туктаган.

Театр тирән бер диңгез булса, аның акулалары да, китлары да, балыклары да бар.



Ленар Садриев һәм Илдар Юзеев. «Хуш, Хәйбуш!» чоры. 1997

Ни сәбәптәндер, китлар судан чыгып, диңгез ярына ташланалар һәм шунда җан бирәләр.

Ленар Садриев та татар театрының бер киты иде...

## Үз урынына килгән драматург

Болай була. Бик тә инде драматург буласы килә Ризванның. Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи кебек. Шагыйрьләр дә, прозаиклар да күп әдәбиятта, ә драматурглар бармак белән генә санарлык. Үзенә остаз эзли Ризван. Армиядән кайтып, Казан педагогия институтында укып йөргән чак. Яңа гына язган пьесасын күтәреп, китә бу «Татарстан яшьләре» каршындагы иҗат түгәрәгенә. Әмма монда да шагыйрьләр, прозаиклар буа буарлык,— драматурглар остазы юк. Гәзиттә әдәбият бүлеген җитәкләүче Шамил Маннапов аңа Язучылар союзы консультанты драматург Әнәс Камалга барырга киңәш бирә. Галиәсгар Камалның улы аны, пьесасын уку өчен, өенә чакыра. Татар драматургиясе үзе пьесаларын язган өйгә! Башта «Шәп! Шәп!» дип утырган консультант икенче актны «Булмады бу!» дигән сүзләр белән тәмамлый.

Картның яшь авторга чыгарган хөкем карарын ишетеп торган Сәлимә апа Ризванны якларга алына: «Карама, энем, аның сүзләренә, синнән алда ачулары килеп, берике егет бүрекләрен ташлап киттеләр инде»,— ди ул. Әнәс Камал исә болай өсти: «Маташма, энекәш, болай язсаң, синнән барыбер драматург чыкмый!» Ризванга үзеннән алда килгәннәрнең батырлыгын кабатларга туры килә. «Драматург булмасам, шушы бүрегемне башыма кимим!» ди дә бу, бүреген атып бәреп, өйдән чыгып китә. Бәлки, бу музей-йортта бер экспонат арткандыр, анысы әлегә билгесез.

Әллә инде кырык пьеса язган драматургның сүзләре тәэсир иткәндер, Ризван «болай язмыйча», башкачарак маташтырырга тотына. Башына яңа бүрек сатып алырлык гонорарлар ява башлый, Аллага шөкер! Ниһаять, яшь драматурглар семинарында кырык пьеса язган Аяз Гыйләҗев үзе аның пьесаларын укыганнан соң: «Ризван тумыштан драматург!» — дип белдерә.

Остазның сүзләрен раслап, тумыштан драматургның әсәрләре бер-бер артлы театр сәхнәләрен яулый. Бүгенгесе көндә Ризван Хәмид аз да түгел, күп тә түгел — утызлап пьесаның авторы. «Синең урыныңа кайттым» драмасын Татар дәүләт академия театрында 1978 елда Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштергән. Кәрим Тинчурин исемендәге, Минзәлә, Әлмәт, Оренбург шәһәрләрендәге театрлар аның әсәрләренә бик еш мөрәҗәгать итәләр. Башкортстандагы Сибай дәүләт театры аның дүрт пьесасын тамашачыларга күрсәтте. Камал театрында уңышлы барган «Китәм инде» («Под знаком Марса») драмасы элеккеге Советлар иленең егермеләп театрында куелып, олы аренага күтәрелде. Ул пьесаны күренекле драматург, Мәскәүнең югары әдәби курсларында Ризванның семинар җитәкчесе Виктор Розов үзе тәрҗемә иткән. «Современная драматургия» журналында һәм Мәскәүнең башка басмаларында Ризванның җиде пьесасы басылган.

Шуларга драматургның киносценарий жанрындагы актив эшчәнлеген дә өстик: «Р.Мингалим белән бергә иҗат ителгән «Идегәй» исемле киносценарийның да, «Тукай» телевизион фильмының да бер авторы ул!

«Чабаталы чәүчәләк» дигән яңа комедиясе Казан дәүләт яшьләр театры репертуарында сәхнә көтә.



И.Юзеев, Р.Мингалим, Р.Хәмид, Ш.Галиев яшь язучылар семинарында. Март, 1986

Күптән түгел үткәрелгән яшь драматурглар семинарында шундый бер фактны игълан иткәннәр: татар драматургларыннан пьесалары иң күп куелган автор — Ризван Хәмид икән. Аның әсәрләрен илледән артык театр сәхнәгә мендергән.

Егерме биш елга якын иҗат чорында Ризван Хәмид театр һәм әдәбиятыбызны үзенә генә хас алымнары, яңача конфликтлары, үзенчәлекле геройлары белән баетты.

Татар әдәбияты, театры, режиссерлары, тамашачылары бөтен талантын, көчен, гомерен театр сәнгатен үстерүгә багышлаган шундый олы драматурглары булу белән горурлана алалар.

Ризван безнең — Язучылар берлегенә керергә рекомендация язган абзыйларның өметен дә аклады. Кайчандыр үзенә остазлар эзләп йөргән егет хәзер үзе остаз. Яшь талантлар җыелган семинарларга хәзер аның үзен җитәкче итеп чакыралар, иҗат тәҗрибәсен уртаклашуны үтенәләр. Әле һаман шулай: шагыйрьләр дә, прозаиклар да җитәрлек, ә драматурглар бармак белән генә санарлык. Олы драматургларга бүрекләрен ташлап китүчеләре юк та юк инде.

Шундый олпат шәхесне алтмыш яше тулган көннәрдә эш өстәле янында — драматургия тәхетендә күрү үзе

бер сөенеч. Безне әле яңа спектакльләр, яңадан-яңа ачышлар көтә.

Кышкы салкыннарда Ризванның башында яңа бүрек күрсә, Әнәс Камал да сөенеп «Тәки драматург чыкты бит бу малайдан!» дип әйтер кебек...

*2001*

## *Сулар агар, җилләр исә торыр...*

Кемнәр әйтә: эзләмәгез генә,
Барыр юллар инде өзелгән...
Ак пароход килә Агыйделдән —
Болгар бабалары эзеннән.

Академик М.Н.Тихомирнов борынгы Болгар тарихын өйрәнеп, «анда гүзәл, талантлы, кыю халык яшәгән» дигән нәтиҗәгә килгән. Аллага шөкер, бу сыйфатлар әле дә югалып бетмәгән икән дип сөенәм. Менә тугыз ел инде Уфа каласындагы «Рамазан» татар җәмгыяте Бөек Болгарга сәяхәт оештыра. Бабаларыбыз ерак Болгарга әллә ничәшәр тәүлек каекларда барганнардыр, ә аларның мирасларын онытмаучылар — Уфа татарлары — «Зайцев» теплоходын яллаганнар. Изге бу сәяхәтне оештыручы Марат Шәрипов үзе дә Алыплар нәселеннәндер: мәһабәт гәүдәле, талантлы һәм тәвәккәл шәхес. Ул — «Рамазан» җәмгыяте рәисе.



Корабта очрашу. Марат Шәрипов һәм Илдар Юзеев. 6 июль, 2001

Ак пароход эчендә — береннән-берсе гүзәл, затлы, талантлы, асыл милләттәшләребез. Анда — халкыбызның сөекле җырчысы, ак күңелле аккошы Фәридә Кудашева, анда — шагыйрьләр, композиторлар, биючеләр, укытучылар, студентлар...

Ак пароход һәр килүендә нурлы һәм дәртле Казанга туктап, сәяхәтчеләрне мең яшьлек кала белән таныштыра.

Һәр елны без ак пароходтагы саф күңелле дусларыбызны каршыларга, озатырга барабыз. Бу юлы да алар безне үзләре белән очрашырга чакырдылар. Рәдиф Гаташ белән кадерле якташларыбызга яңа шигырьләребезне сөйләдек, галимнәребез Флора Урманче, Дамир Исхаков һәм Лена Гайнанова фәндәге яңалыклар белән таныштырдылар.

Пароход кузгалып китү алдыннан күңелле дә, моңсу да биюле-җырлы саубуллашу башланды. Менә инде алар, палубаларда урнашып, безгә кул селкиләр һәм «Кайтам инде» җырын җырлыйлар. Аяк асларымда җир чайкала сыман. Без әле генә кочаклашып хушлашкан Фәридә апаның да җырга кушылуын тоям.

Кайтам инде туган-үскән ягыма,
Кырларыма, тугайларыма...

Озак-озак юлда озатып барачак Сәйдәш маршы аерылышу сагышына өметле дәрт өсти. Ак пароход еррактан Фәридә Кудашева моңына тирбәлеп-очып баручы аккошны хәтерләтә.

Борынгы юлны яңарткан тәвәккәл милләттәшләремне изге Болгардан алып кайтучы ак пароходка күздән югалганчы карап торам.

Сулар агар, җилләр исә торыр,
Узар өермәләр, бураннар...
Идел, Агыйделдән эзләп килеп,
Безне табарлармы туганнар?

## Авылдашым Равил

Минем Яңавылдан икәнне белгәч, шагыйрь Салих Баттал: «Беләм мин Яңавылны, сугышка кадәр Свердловскига очканда, ягулыгыбыз бетеп, шунда төшкән идек, ягулык салып, күккә күтәрделәр»,— дигән иде.

Чыннан да, Яңавыл бик күп балаларын, гомергә җитәрлек ягулык салып, төрле якларга очырды.

Бала чагында очучы булырга хыялланмаган кеше юктыр. Без, Ямады малайлары да, күккә күтәрелү турында хыяллана идек. Хатип Госманның уку китабында басылган «Мин күккә күтәреләм» дигән хикәясен яттан белә идек. Бердәнбер көнне авылыбыздан шак-

тый ерак урынга самолет килеп төшкәч, безнең ничек йөгергәнне белсәгез иде! Иң алдан Равил абый барып җитте. Ул очучы булу турында барыбыздан да көчлерәк хыяллана иде шул. Без барып җиткәндә, очучыларны Яңавылга киткән диделәр. Үз күзләребезгә ышанмыйча, ике канатлы очкычны кулларыбыз белән капшап карыйбыз. Көтә торгач, Яңавыл ягыннан машина күренде. Аннан очучы формасындагы ике баһадир төштеләр һәм очкычлары янында кайнаштылар. Бераздан безне, җыелган халыкны читкәрәк кудылар. Самолетның пропеллеры әйләнә башлап, очкыч кузгалды һәм Ямадыга койрыгын гына күрсәтеп, күк йөзендә зәңгәр ноктага әйләнде.

Хәзер уйлап куям: ул вакытта безгә килеп төшкән очучының берсе, бәлки, Салих Баттал булгандыр...

Шул көннән соң Равил абыйның очучы булу нияте тагы да ныгыды. Җәйге тын кичләрдә аның ачык тәрәзәсеннән ишетелгән гармун тавышын һәм җырны мин урамда тукталып тыңлый идем.

Күккә менеп, түбән карап
Сезне күрәсем килә...

Ун классны тәмамлагач, ул әле безне немец теленнән укытты. Шигырь белән җенләнгәнебезне белгәнгәдер инде, немец телендәге шигырьне татарчага тәрҗемә иттерә иде.

Ниһаять, Равил абый хыялына иреште, сөенә-куана гармунын уйнады да, хыялына ягулык биргән Ямадыны калдырып, очучылар мәктәбенә китте.

Бердәнбер көнне кайтып керде Равил абыебыз: кименнән күзләр камаша, формасы без күргән очучыларныкыннан да күркәмрәк, затлырак, фуражкасына кадәр күккә карап тора. Кызлар, сокланып, мәхәббәтле күз карашлары белән озатып калалар, бала-чага кызыгып артыннан ияреп йөри. Үзе күп сөйләшми, безнең сорауларга: «Очабыз инде, очабыз!» — дип кенә җавап бирә.

Без дә, туган ояларыбызны калдырып, Казан якларына карап очтык. Иң беренче булып — Нил абый университетка, Риф һәм мин — педагогия, Фоат — финанс, Саим — авыл хуҗалыгы институтларына барып төштек. Казанның тарту көче тора-бара Равил абыйга да тәэсир



Сулдан уңга: Риф Хәбибрахманов, Равил Муллаянов, Фоат Динов, икенче рәттә: Илдар Юзеев, Саим Гафиуллин. 1953

итте. Берничә елдан ул да Казанга килеп урнашты. Әмма ул нигәдер бик нык үзгәргән иде: башын аска иеп йөри, елмаюы да безнең күңелне күрү өчен генә. Ул күкне ташлап отставкага киткән иде. Баштарак моның сәбәбен әйтмәде, ачылмады. Соңрак, квартирында альбомын карап утырганда, бер фоторәсем килеп чыкты: уртасыннан сынган самолет янында Равил абый тора. «Чак-чак кына исән калдым... Минем беренче гомерем шуның белән тәмам»,— диде ул, моңсу гына көлемсерәп.

Икенче гомерен ул ниндидер министрлыкта чиновник булып башлады. Нигәдер безнең белән бик сирәк аралашты, ни әйтсәң дә, без — югары уку йортында укыйбыз, бергәләп күңел ачабыз, гел очрашып торабыз. Безнең менәсе күгебез әле алда, ә Равил абый инде аннан — күктән егылып төшкән кеше.

Берничә ел узгач, ул безне янә гаҗәпкә калдырды, министрлыкларда йөри-йөри ул яңадан биеккә күтәрелгән иде: авылдашыбыз Равил Муллаянов — Татарстан партия өлкә комитетының үзендә, үзәгендә, түрендә — Беренче секретарьның ярдәмчесе, лично Табеевның кабул итү

бүлмәсендә! Бу — аның икенче тапкыр биеккә күтәрелүе иде. Хәзер ул бер дә тарсынмыйча, күңелсезләнмичә, үз дәрәҗәсен белеп кенә безнең белән дә аралаша, мөмкин булган кадәр ярдәм дә итеп куя, ябык буфеттан безгә азык-төлек тә алып чыккалый. Дуслары күп, иң зур түрәләр дә аның белән «Равил Муллаянович» дип кенә сөйләшәләр, ихтирам итүләрен белдереп, кулын кысалар. Хуҗа өйдә юк чагын туры китереп, мин дә качапоса, Беренче утырган кабинетны күрү бәхетенә ирештем. Равил абый бәхетенең тәхетендә утыра, ул — икенче гомеренең күгендә иде.

Әмма бу бәхетнең гомере кыска булды. Алтмыш яше җиткәч, аны пенсиягә җибәрделәр. Тирәсендә юрга тайдай йөгереп йөрүчеләр юкка чыкты, бергә эшләгән хезмәттәшләре оныттылар, аны күккә күтәргән партия үзе дә җимерелде... Шуннан соң Равил абый бик көчле инсульт кичерде.

Бу — аның икенче тапкыр күктән егылып төшүе иде.

Әмма ул дөньядан елап китмәде.

Ир-егетләрчә ике тапкыр яшәп китте.

## Нигә без аерылдык?..

Радиодан җыр тапшыралар:

> Бер кыр казы калган аерылып
> Үзе очып килгән төркемнән...

Рәшит Гәрәй шигыре. Әнвәр Бакиров көе. Бу җырны элек тә тыңлаганым бар. Әллә ни көчле тәэсир итми иде. Хәзер бәгыремнең үзәгенә бәреп керә. Бигрәк тә әнә шул ике юлы. Көйнең иҗатчылары икесе дә юк. Илленче еллардагы тыйнак та, шаулы да шигърият яшьлегебез искә төшә. Рәшитнең Мәскәүдәге М.Горький исемендәге әдәбият институтында укып йөргән чаклары. Кайнар йөрәген, тойгыларын бушаткан ихлас хатлары әле дә саклана. Аның башкаладан кайтуын без ашкынып көтә идек, туп-туры вокзалдан Шәүкәтләргә китә идек. Алам кулга гармунны, «Әйдә, киттек, Рәшит!» дип әйтеп, китәбез авылча җырлап, тар урамнарны киңәйтеп! Гармун туктап торган арада, Рәшит яңа гына язган шигырен ритмлап-көйләп сиптерә:



Уңнан: Х.Камалов, Р.Гәрәй, И.Юзеев. 1957

Уйна әле, Илдар, Сәйдәш маршын,
Күтәрелеп китсен күңелләр,
Ни өчендер, белмим, башка көйләр
Ул кадәре дәртле түгелләр!

Аның шигъри ярсуы гармунга күчә. Үтәбез яшьлек урамнарындагы тирәкләрне Сәйдәш маршына биетеп. Авыл ярсуы Казан урамнарына сыймый.

Узды еллар, тузды юллар, тузды гармун... Яшьлегебез юлларын авыл тузаннары түгел, кала заводларының кара төсе каплады. Рәшит бездән, без Рәшиттән аерылдык. Нигә? Ни өчен? Без бит шигырьгә бер төркем булып килгән идек.

Мин моны менә хәзер Рәшитнең җырын үзе дөньядан киткәннән соң тыңлагач аңладым. Шушы ике юлга шагыйрьнең бөтен язмышы, газаплары, драматик тормышы сыйган. Әнвәр Бакиров та көе белән Рәшитнең ялгызлыкта кичергән уйларын тагын да тирәнәйткән. Мөгаен, үз гомерендә шундый хәлләрдә үзе дә калгандыр.

Рәшит кала белән сала арасында бәргәләнде. Казанда фатиры булса да, таш диварларны, андагы ясалма тормышны ят итте. Соңгы елларда туган ягын югалтмаска тырышып, Түбән Камада гомер итте. Туган авылының

исеме Малтабар булса да, ул мал табу өчен түгел, җыр табу өчен яратылган иде. Без аның Казанда тәне генә йөрүен, җанының авылда калуын күреп тордык. Торабара Рәшит Казаннан, яшьлек дуслары төркеменнән бөтенләй аерылды. Әллә без үзебез дә аннан аерылдыкмы?

Бу сорауга җавапны Рәшит җыр-шигыре белән исән чагында үзе әйтеп киткән...

Иптәшләрен куып җитәлмәсә,
Ялгыз башы кая сыеныр.
Аңа карап тирән уйга чумдым:
Туган җирсез яшәү кыендыр.

## Тукайны югалту

Үзе исән чагында тугры Тукайны яратмаучы, хәтта дошман күрүчеләрнең күп булуы һәммәбезгә мәгълүм. Хаклык хакына берниндидә килешүләргә бармыйча, шагыйрь үзенең дусларын да аямаган. Хәзер без үзебезне Тукайның рухи дуслары дип уйлыйбыз. Телебез Тукай шигырьләре белән ачылды бит. Бүгенге көндә аны яратмаган татар юктыр... дигән уйда йөргәндә, һич тә көтмәгәндә, аны дошман күргән адәм белән очраштым.

Аны бер танышымның дачасына баргач күрдем. «Сиңа бик кызык әңгәмәче булыр»,— дип, танышым күршесен чакырды. Үзен «дядя Саша» дип тәкъдим итте ул. Мин үземне балалар матбугатында эшләүче журналист дип таныштырдым. Сәламәтлек өчен берничә тост әйтешкәннән соң, урысча гына сөйләшүче абзый кызып китте:

— А я ненавижу вашего Тукая!

Әлбәттә инде, мин сәбәбен сорадым.

Һәм дядя Саша, игътибар белән тыңлаучы табылуга сөенеп, тәрҗемәи хәлен сөйләп китте.

Ул танылган артист гаиләсендә туган. Әтисе 30—40 нчы елларда академия театры сәхнәсендә күп кенә рольләрне башкарган. Әле дә хәтерли: дядя Саша биш-алты яшендә татарча гына сөйләшкән. Татар артистлары арасында буталып йөргән. Башта әнисе, аннары әтисе авырып, теге дөньяга китеп баралар. Күренекле артист булярак, әтисен Тукай белән янәшә җирлиләр. Аннан соң балалар йортларында чит шәһәрләрдә ятимлек чоры баш-



Без тукайны югалтмабыз

лана. Татар баласы үз телен оныта, «дядя Саша»га әйләнә. Еллар үткәч, инде үсеп ир-егет булгач, ул туган каласы — Казанга кайта, шунда ук Яңа бистә зиратына китә һәм Тукай яныннан әтисенең каберен эзләргә тотына. Кабер дә, һәйкәл ташы да юк. Зират сакчыларыннан сораша. Төпченә торгач, дядя Саша шуны ачыклый: әйе, булган анда кабер! Әмма аны югарыдан килгән фәрманны үтәп, алып атканнар: шагыйрь янәшәсендә беркем дә ятмаска тиеш!

Җитмеш дүрт яшьлек картның күзләре дымлана, тавышы калтырап чыга:

— Они глумились над прахом моего отца! С тех пор я ненавижу вашего Тукая!

Мин аны тынычландырырга, аның бу драмасында Тукайның гаебе юклыгын, мондый аяныч хәл чиновникларның таш бәгырьле булулары аркасында килеп чыгуын аңлатырга тырышам. Әмма юкка гына: ул фикер инде аның җанына кереп утырган.

Бер караганда, дядя Саша миңа кызганыч та: ул этисен генә түгел, исемен дә, әткә-әнкә телен дә югалткан.

Минемчә, дядя Сашаның иң авыр фаҗигасе — Тукайны югалту...

# Курку хисе

Квартира ишеген ачып чыктым да лифт төймәсенә басарга үрелдем. Карасам: алдымда — фашист тәресе — свастика. Моңа кадәр дә шәһәр диварларында бу билгене күргәнем бар. Узучылар әһәмият бирмичә генә узалар. Бала-чага шуклыгы гына дип уйлыйлар, күрәсең. Безнең Казанда әлегә бу билгенең куркыта торган күренешләре юк югын. Безнең подъезд балаларының да уены гынадыр бу.

Уйларым еракта калган бала чагыма алып китә. Сигезенче класста укыган чак. Сугыш тәмамлануга биш кенә ел. Бервакыт колактан колакка хәбәр таралды: мәктәптә гадәттән тыш хәл: директорыбыз Бакый абый Сөләйманов бөтен коллективны җыеп әйтәчәк икән. Укытучыларның йөзләре җитди, шомлы, ни булганын безгә сиздермиләр. Декабрь аеның салкын залына җыелдык. Күреп торабыз: Бакый абыйның йөзендә курку, һәммәбез шым булып, аның авызыннан сүз чыкканын көтәбез. Һәм әйтте директор: «Карагыз тәрәзәгә... күрәсезме?! Кемнең кулы ясады моны?!»

Тәрәзәгә карыйбыз: бозлы пыяланың өч өлгесенә өч хәреф — «ХФТ» дип язылган. Беләбез инде, классыбызның шук малае Хәйдәршин Фәрит Тимергазиевич үзенең исемен бозга язып мәңгеләштерергә уйлаган. Әмма без әле берни дә аңламыйбыз. Йөзләре агарган Бакый абый теш арасыннан кысып һич көтелмәгән сүзләр чыгармасынмы?

— Фашист билгесе — свастика!..

Беркем дә моны көтмәгән иде. Игътибар белән карыйбыз: «Х» хәрефе, чыннан да, свастикага охшатып уелган. Башын иеп, арабызда Фәрит үзе дә утыра.

— Мәктәбебездә дошман коткысы таратучы бар. Әйтегез, кем эше бу?!

Әмма, кем икәнен белсәк тә, без Фәритне сатмадык. Аның фашист яклы булуына беребез дә ышанмыйбыз ич. Әтисе сугыштан аяксыз кайтып керде. Авыр елларда бөтен авырлык дүрт малай җилкәсенә төште.

Минемчә, директор абыебыз моның кем язганын, явыз ниятнең ул малайның уенда булмавын үзе дә белә. Әмма әйтми. Ни өченме? Бакый абый безгә фашизмның куркыныч икәнен тагын бер тапкыр искәртергә, свастика-

ның бар дөньяга, безнең барыбызга да коточкыч бәлаләр алып килгәнен хәтергә төшерергә, бу билге белән уйнарга да ярамаганны әйтергә тели. Без моны шулай аңладык та. Фашизм — куркыныч. Аңардан курку хисе җаннарда сакланырга тиеш. Фәрит тә үзенә мәңге онытылмаслык сабак алгандыр.

Хәзерге акылым белән мин моны тирәнрәк аңлыйм. Бакый абыйда ул чакта икенче курку хисе — өч хәрефтән — КГБдан курку да көчле булгандыр. Мөгаен, ул шул елларның эзәрлекләүләре аша узгандыр. Безнең Ямады мәктәбенә ул читтән килеп төште, элек кайда эшләгәнен, нигә монда күчеп килгәнен сөйләргә яратмаган. Ул дәвер кешеләрендә курку хисе бик көчле иде шул.

1943 елда район газетасында минем «Дошман җиңелә» дигән шигырем басылып чыкты.

Яндырылды өй,
Ясле һәм мәктәп,
Утка салынды
Халыкны таптап.
Картлар, аналар
Һәм яшь балалар
Авыр эшләрдә
Газапланалар,—

дигән юлларда «газапланалар» алдыннан «анда» сүзен өстәгәннәр иде. Ул вакытта иҗек саннарын бозып чыгаруга үпкәләсәм дә, хәзер инде аңладым: редакторда КГБдан курку хисе өстенлек алган. Әгәр картлар, аналарны дошман яулап алган җирдә түгел, монда — бездә дип аңласалар?!

Шул елларда безнең мәктәптә математика укыткан Михәр Урманов бар иде. Аның чын исеме Рәхим, фамилиясе Әсадуллин, Уфада зур урында эшләүче абыйсы репрессиягә эләккәч, башка исем-фамилияле паспорт алып, безгә килгән икән дип сөйләделәр. Ничек инде аларда курку хисе булмасын?

Икенче көнне квартира ишеген ачып чыгам да лифт чакырырга дип төймәгә үреләм. Шул ук фашист тәресе. Беркем дә бозмаган. Һәм мин дә аны юк итәргә оныткынмын. Сугыш беткәнгә, Бакый абыйның «онытмагыз!» дип кисәтүенә дә күп еллар узган шул. Хәтер кыска безнең. Мәскәү урамнарында «Хайль Гитлер!» дип акырып йөрүче яшүсмерләрдән дә курыкмыйбыз, «яшьләр уены» дип кенә карыйбыз.

Уеннан уймак чыкканчы, фашизмның ни икәнен онытканнар белән, һич соңламыйча, курыкмыйча көрәшкә чыгарга вакыт түгелме?

## *Хаты гына калды...*

Көн саен радиодан ишетеп, телевизордан күреп торабыз: яшьләр армиягә барырга теләмиләр, барганнарының да кайберләре, андагы яман хәлләргә түзә алмыйча, качып китәләр. Бер ел элек кенә элекке күршебезнең улы, күз алдыбызда үскән яшь-яшь Рәшитнең үле гәүдәсе Чечнядан кайтты. Ничек инде шундый армиягә барасы килсен?!

Хәтеремдә: Ватан сугышы алдыннан, без бәләкәй чакларда, яшь егетләрнең яраткан җыры болай иде:

Ворошилов портретын
Күргән саен карыймын.
Армиягә баруымны
Зур бәхет дип саныймын.



Бу — җырда гына түгел, чыннан да шулай, яшьләр туган илне сакларга сөенә-сөенә китәләр, өйләренә матур-матур хатлар язалар иде.

Әниемнең энесе Зөфәр абый мылтыкка гашыйк. Мылтыгы белән ауга чыгып, кышларын куян, көзләрен үрдәкләр ата. Биш-алты яшьләремдә мине дә алып чыкканы истә. Атылган үрдәк сазлыктагы күлгә килеп төште, әмма абый аны эзләп табалмады. Мин үрдәкне бик кызгандым. Төнлә дә шул яралы үрдәк күз алдымнан китмәде. Бәлки, нәни үрдәкне әнисе һаман

көтәдер, аның күккә карап җан биреп ятуын белмидер кебек тоелды.

Дәү әни (аның әнисе) бик диндар остабикә, улының гармунда уйнавын бирелеп тыңласа да, гөнаһсыз җәнлек-кошларны атуын яратмый, аларның каргышы төшәр, үлемең мылтыктан булыр дип куркытып та карый. Ә ул — шул заман баласы, динчеләргә каршы сугышчан көрәш ачкан комсомол. Әнисенең «иң авыр чакларыңда бисмилла ит» дигәннәрен колагына да элми.



Зөфәр абый, ниһаять, хыялына ирешә: 1939 елны сөенә-сөенә армия сафларына китте.

Миндә аның җизнәсенә (минем эткәй) язган хаты сакланган. «Нил, Илдарга күп сәлам» әйткәннән соң ул үзе укыткан мәктәп хәлләренә күчә һәм «мәктәпнең тальян гармуны да яндымы?» дип борчылып сорый. Мин күргән беренче гармунчы Зөфәр абый булып, ул уйнаганда аның бармакларына сокланып карый, көйләрен сихерләнеп тыңлый идем. «Таныш моңнар» поэмасында гармунчы егетнең Зөфәр исемле булуы юкка гына түгелдер.

Сугышның беренче айларында ук Зөфәр абый хәбәрсез югалды. Соңыннан исән кайткан бер абзый аны атака алдыннан күреп калуын һәм шуннан кире кайтмавын хәбәр итте.

Озак еллардан соң, мин яшьлек уеннарыннан чын сугыш тәмугына барып кергән абыйның рухи халәтен күзалларга тырышам.

Менә ул, авыр яраланган хәлдә, күккә карап ята. Йөрәгенең соңгы тибешләре аның инде дөньядан китеп барышын искәртә. Томаланган зиһене әнисе өйрәткән «иң авыр чакта әйтерсең» дигән догаларны искә төше-

рергә тырыша. Аның күгәргән иреннәреннән соңгы тапкыр өзелеп-өзелеп ике генә сүз чыга: «Әни... бисмилла...» Бәлки, ут эчендә янган гармунның үзәк өзгеч тавышы да ишетелгәндер...

Дәү әни аны гомере буе көтте. Ни өчендер бигрәк тә язларын үрдәкләр кайтканда өзелеп көтә иде...

## Риза абый мәҗәралары

Аның исемен беренче тапкыр үзебезнең авыл сәхнәсендә ишеттем. Риза Ишморатның «Гөлзадә» исемле драмасын куйдылар. Биш-алты яшьтә генә булганлыктан, эчтәлеген хәтерләмимм. Укытучы Саяповның кемгәдер ни өчендер револьвердан атканы, бик курыкканым гына истә калган. Аннары сугыш башланып, Саяпов абыйлар чынлап сугышка — атышырга китеп, әйләнеп авылга кайтмадылар.

Сугыштан соң мәктәпкә килгән яшь укытучылар шул ук Риза Ишморатның «Кайту» пьесасын сәхнәдә күрсәттеләр.

Күңелгә балачактан кереп калган мәшһүр драматургны Казанга килгәч үзен күрермен, аның кебек осталар җигелеп тарткан тәртә арасына үзем дә килеп керермен дип кем уйлаган?

1950 еллардан башлап Риза абыйның тормышы минем күз алдымда узды. Әллә инде икебез дә Яңавыл районында туганга, без бик тиз бер-беребезгә үз булып киттек. Аның үз-үзен тотышында бернинди дә рәсмилек юк. Ул синең иң якын дустың кебек сөйләшә.

Табигатенә усаллык ят, хәтта ул миңа артыгы белән юаш булып күренде. Без, драматургиягә яңа гына борын төртүче яшьләр, пьесаны укырга башта Риза абыйга йөгерә идек. Аның юк кына әйберенне дә мактавы күңелне күтәрә. Шуннан соң пьесаңны секциядә сүтәләр, анда да Риза абый яклап чыга.

Гадәти тормышта, язучылар арасында юашлыгы белән танылган драматургны Ватан сугышында катнашу үзгәртә дә куя. Майор Ишморатов усал, кырыс сугышчыга әйләнә. Татар телендә чыгарылган фронт гәзитендә редактор урынбасары булып хезмәт итсә дә, аңа алгы позициядә корал



Хәсән Туфан, Риза Ишморат, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов һ.б. Лениногорскида яшь язучылар семинарында. 23 октябрь, 1966

тотып сугышырга да туры килә. Төне буе яу кырында йөреп кайтканнан соң изрәп йоклап киткән майор Ишморатовны тәмле йокысыннан уяталар. Казанга командировкага киткән хәрби корреспондент икән.

— Тор, Риза, сиңа авыр хәбәр китердем! Хатының кияүгә чыккан...

Риза абый уяна, күзләрен уа да:

— Нигә алай итте икән...— дигән бер җөмлә әйтеп, берни булмагандай, йоклавын дәвам итә.

Бу вакыйганы ишеткән кеше Риза абыйны бигрәк гамьсез икән, дип уйлавы мөмкин.

Гамьсез, юаш кеше батырларча сугышып, күкрәгенә шулкадәр орден, медаль тагаламы?

Риза абзыйның Германиядәге маҗаралары турында үзара гына тагын берничә вакыйга сөйлиләр. Монысы, мөгаен, мәзәктер, дип уйлап йөри идем.

Берлинда барган сугышларның берсендә майор Ишморатов яралана. Пуля аның нечкә җиренә тия. Госпитальдә ул авыр уйларга бирелә: «Бетте баш, хатын-кыз әйләнеп тә карамас инде...» Әмма госпитальдәге яшь-яшь шәфкать туташлары батыр сугышчының ярасын төзәтеп, яңадан сафка бастыралар.

Моны, көлә-көлә, абзыйның хәләл җефете Рәйсә ханым раслады.

Менә майор Ишморатов сафта басып тора. Гәзитәнең редакторы хәрби журналистларга медальләр тапшыра. Тантаналы рәвештә Ишморатовны да саф алдына чакыралар. Полковник-редактор, бөтен мәйдан ишетерлек итеп, медальнең ни өчен бирелүен урыс теленең бөтен көче белән әйтеп сала: «Многие из нас на войне головы положили, а майор Ишморатов ... положил за Германию!»

Моның дөреслеген, көлә-көлә, Риза абый үзе дә раслады.

## «Нәркемнең үз Мәрфугасы бар...»

Йолдызлы күк астында учак янында утырабыз. Әтиәниләр безне сыерларны саклап төн чыгарга куштылар. Безгә — хыялый малайларга шул гына кирәк! Төн үзе әкият кебек серле, ә олырак абыйлар сөйләгән кыйссалар, мәзәкләр уйларны әллә кайларга алып китәләр. Бик күп китаплар укыган Нил абый «Йөзек кашы» дигән китапта укыганнарын сөйләгәнне без бигрәк тә яратып тыңлыйбыз.

— Монысы әкият түгел, повесть дип әйтәләр моны,— ди ул.— Фатих Хөсни исемле язучы иҗат иткән.

Аннан соң мин ул язучының исемен үзебез укыган уку китабында очраттым. «Көтү кайтты, ә Фәридәләрнең сыерлары кайтмый калды»,— дип башлана иде аның хикәясе.

Нил абый Казан университетына укырга киткәч, «Йөзек кашы»ның авторын үзем күрдем» дип горурланып хат язды.

Казан дәүләт педагогия институтында укый башлагач, язучыларның Тукай исемендәге клубында Фатих Хөснинең үзен күрдем. Читлеген җимереп чыгарга ашкынган чал арыслан кебек очына-талпына күренекле бер язучының әсәрен юк итеп ташлагач, бик аптырап калган идем. Үземнең дә матбугатта шигырь, поэмалар басыла башлаган вакыт. Җыелышларда Фатих Хөсни трибунага кунакласа, «мине генә хур итмәсә ярар иде» дип шүрләп утыра идек. Кайвакытта Фатих агабыз кайбер

авторны бер генә уңышлы җөмләсе белән күккә күтәрә. Без классик санаган Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Атилла Расих кебекләрне дә чеметеп ала. Кече-олы дип тормый, һәммәсенә мактауны да, тәнкыйтьне дә мул эләктерә. «Ачуым да килмәгәе» дип әйттеме, берәрсенең китап шүрлегенә менеп төшүен көт тә тор! Кайвакыт чыгышын: «Ярый, хуш, тәмамлыйк, һәркемнең өендә үз Мәрфугасы бар, киттек өйгә!» — дип тәмамлый. Ә аның язу теле дә, сөйләү теле дә ай-һай тәэсирле! Әдәбиятта үз телен-стилен тапкан әдипләр бик аз. Фатих абый шундый сирәкләрнең берсе. Үзе дә тел остасы Ибраһим Гази бер җыелышта (бераз ачуы килгән чагы булгандыр): «Фатихның теленә шайтан төкергән!» — дип тә җибәргән иде. Мин моның белән килешмичә, «теленә фәрештәләр төкергән», дияр идем.

Ни өчендер Фатих абый үз замандашлары белән дуслашуга караганда, күбрәк безгә — яшьләргә тартыла иде. Соңыннан без аның белән бик тә якынаеп киттек. Бәлки минем гармун уйнаганны яраткандыр. Минем иҗатым турында «Уйна, уйна, моңлы сазым!» дигән мәкалә язуы юкка гына түгелдер. Бик озак бикләнеп, өендә язып утыра-утыра да бик күтәренке кәеф белән (берәр әсәренә нокта куйган чагыдыр) безгә йөгереп килә. Сизәбез инде, арган тәнен язасы, бераз селкетеп, яшәртеп аласы килә. Без дә шуны гына көтеп торабыз — тере классик синең белән рәхәтләнеп утырсын әле! Үзенең финансист дипломы йөртүен, акчага саран булуын дәлилләп, кесәсеннән акча тартып чыгарыр да: «Егетләр, миндә бер тәңкә бар!» дип әтәч булып кычкырыр. Без сөенә-сөенә аның акчасын алган булабыз да кибеткә чабабыз. Бераз кызып киткәч, Фатих абыйның кесәсеннән сикереп йөзлекләр чыга башлый, аңардан да юмартрак, баерак кеше дөньяда юк! Исермәсә дә, без аны ихтирам итеп өенә, ишек төбенә кадәр озатабыз да кыңгыравын чылтыратып, үзебез шылабыз. Мәрфуга апа күрсә, рәхим-шәфкать көтмә... Ә Фатих абзыебыз аны ярата да, шүрли дә.

Дөресен әйткәндә, аны Мәрфуга апа ычкынып китүләрдән саклый. Ә Фатих абый табигатенең йомшаклыгын белеп, ачуланган булып, аңа рәхәтләнеп буйсына.

Гомеренең соңгы елларында аларга бер-бер артлы фаҗигаләр кичерергә язган икән. Салават каласындагы кияүләре Ренат юл транспортында һәлакәткә очрап, кызла-



(Сулдан): Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Фатих Хөсни, Илдар Юзеев. 70 нче еллар

ры Фәридә ялгызы авыр хәлдә калды. Ул гына җитмәгән, Карпат якларына баргач, газ шартлап, уллары Рәшит үлде. Болар барысы да җыелып, икесенең дә сәламәтлегенә суккандыр. Фатих абыебыз тагын да зуррак драма — Мәрфуга апаның үлемен кичерде. Озак гомерләр яратып каты куллы хатынының тәрбиясендә яшәгән олы әдип язган әсәрләре белән ялгызы торып калды. Бераз вакыт ул өйдән чыкмыйча, кайгыларыннан арына алмыйча ятты. Күргән бәла-казалары бераз онытыла төшкәч, Фатих абзабыз үзен карарлык... яшь хатын эзләргә тотынды. Берничә хатын белән яшәргә омтылып караса да, Мәрфуга апа кебекне таба алмады. Бераз кызып алгач: «Нигә чыкмый миннән бу яшьлек?!» — дип ярсыса да, картлык әфәнде якасыннан алган иде инде. Мөслимдәге китапханәгә кергәч сөйләшү искә төште. Фатих абый китапханәче ханымнан сорый: «Минем китапны укыштыралармы соң?» «Кулдан кулга йөри, сезнеке тормый, Фатих ага». Фатих

абый, кызлар белән сөйләшүен онытып, сүзне шаяруга бормакчы: «Сез моны нинди мәгънәдә әйтәсез?» — дигәч, яшь ханым сорауны аңламаганга салышты, әмма кызаруын яшерә алмады.

Шулай инде, тормышта фаҗига көлке белән аралаша, драматурглар юкка гына трагикомедия жанрын уйлап тапмаганнардыр.

Фатих абыйның тормышы — үзе бер драма. Язучы беркайчан да үзенең шәхси тормышын тулысынча яза алмыйдыр, үзе кичергәннәрне инде тормышында язган кебек хис итәдер. Ул үзенә читтән торып караудан мәхрүм.

Иң авыр фаҗигасен соңгы ун-унбиш елда кичерде. Күзләре тоныкланып, укый алмаслык, язмаслык һәм урамга чыкмаслык хәлдә калды. Ярый әле Пермьдә яшәүче кызы Фәридә кайтып, атасын соңгы көннәренә кадәр карады.

Альбомымдагы рәсемнәре килеп чыкканда, Фатих абыйның, гармунына кушылып, күзләрен йома-йома җырлаганы күз алдыма килә:

Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да...

## Егетлекне сагыну

«Мин әле Әбрар аганың егет чагын беләм...» дип сүз башладым да туктап калдым. Егет булмаган чагы юктыр аның.

Безне Нил абый таныштырды. Алар икесе дә Казан дәүләт университетында бер группада укыйлар. Бик тиз дуслашып алганнар. Нәшрият чыгарган китапларга бергә рецензияләр язып, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында бастыралар. Студент чагында Әбрар университетның хәзерге Кремль урамындагы торагында яшәде. Янына барып йөрдем. Ул үзе дә без яшәгән монастырьга кызлар күзләргә килгәләп йөрде. Соңрак, укуларны тәмамлагач, китап нәшрияты яшьләре белән Займище урманына ял итәргә чыкканыбыз хәтердә. Бу рәсем — шул еллардан бер ядкәр. Аның әле миңа абый да, ага да булмаган чоры. Аны яшьтәшем кебек күргән вакыт. Ул яшьләр арасында, берни белән дә аерылмыйча, уйнап-көлеп, дусларча шаярып йөри. Мин дә, башка-

лар да бу егетнең бездән шактый өлкән икәнен, Ватан сугышының утларын-суларын кичеп, әллә ничә тапкыр яраланып, инвалид булып кайтканын, шуннан соң гына Казанга укырга килгәнен белми. Үзе дә бу хакта ләммим.

Соңрак алар Нил абый белән дуслыкларын югалтмыйча, аерым-аерым рецензияләр, гыйльми хезмәтләр чыгарырга юл тоттылар. Икесе дә фән кыйбласына китеп, үзләрен абый дип дәшәргә мәҗбүр итәрлек дәрәҗәләргә ирештеләр. Әбрар абыйның фәндәге үсеше бик авыр барды, татар китабының тарихын актарып чыгаруын партия чиновниклары хупламадылар. Шундый чакларда, диссертация яклаганда, Нил абыйның дәрәҗәле сүзе белән ярдәм итүе турында галим үзе әйтә иде. Аңа үзендәге иң асыл сыйфатлар: Тукайча тугры, принципиаль, гадел усал булуы, милләт өчен җанын бирергә дә әзер торуы ярдәм иткәндер.

1985 елның 4 июлендә без Татарстан язучылары делегациясе төркемендә Казакъстанның Семей (Семипалатински) каласына бөек казакъ шагыйре Абай Кунанбаевның 140 еллык юбилеен үткәрергә бардык. Без дигәнем: Әбрар ага Кәримуллин, Мәхмүт Хөсәен, Рәдиф Гаташ һәм мин. Рәдиф белән мин — әле яшьләр, аларның дәрәҗәсенә сыенып йөрибез. Ә Әбрар белән Мәхмүт әкәләрне күтәреп кенә йөрттеләр. Бигрәк тә Әбрар аганы олы галим, татарның ил агасы итеп хөрмәтләделәр.

Казанга карап кайтырга чыккач, Мәхмүт Хөсәен, юлдашының кем икәнен онытып, мактана башлады:

— Мине беләләр... Җырларымны җырлыйлар. Мин дә аларны онытмыйм. «Яшәсен, кияүләрем!»не беләсең бит.

Бер киявем Кустанайда,
Кил, кымыз куярбыз, ди.
Казан асып, бишбармакка
Бер сарык суярбыз, ди...

Менә шул вакыт китте кабынып Әбрар ага, Мәхмүт бу сүзне ник башлаганына үкенгәндер.

— Син бу җүнсез җырың белән татарның тамырына балта чабасың!.. Синең кызларыңнан туган балаларның берсе дә татар булмасын беләсеңме? Туктат бу җырыңны! Үзең барып әйт радиога!

Мәхмүт мескеннең маңгае җыерыла, аклана:

— Тормышта булган хәлләр бит, Әбрар, беләсең...


Уңда басып торучы Әбрар Кәримуллин. Икенче рәттә: Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева һ.б.

— Менә шундый хәлләр тормышта булмасын өчен көрәшергә тиеш шагыйрь. Бу җырны тыңлаган ата-аналар, шагыйрь акыллы сүз язгандыр дип ышанып, кызларын башка милләт кешеләренә димләячәкләр, ә кызларыбыз синең җырыңны җырлый-җырлый китәчәкләр... Син чын шагыйрь булсаң, бу хәлгә түзә алмыйча, сатирик җыр язар идең...

Без Рәдиф белән ике фронтовикның бәхәсенә катнашмыйбыз, «искә алырга кирәк» дип, мыекка чорнап торабыз.

Әнә шулай милли мәсьәләләрдә артык кискен, таләпчән иде Әбрар ага.

Ахыргы елларында өлкән яшьтәге гыйлем иясе белән хастаханәдә очрашырга туры килде. Килеп кергән көнне үк Әбрар ага палатада да, үзебез дәваланган бүлекнең телевизор салонында да ике дәүләт теле урнаштырды. Өлкән милләт вәкилләренең телевизордан татарча сөйләшүне туктатуларын белгәч, ул:

— Бүгеннән соң яңа тәртип булачак: башта — Казанны, аннары Мәскәүне карыйбыз.

Һәм шулай булды: беркем каршы сүз әйтә алмады.

Аяк сызлаулары һәм йөрәк авыртуыннан төннәр буе газапланып яткан фронтовик бер генә дә зарланмады, үзен һаман егетләрчә тотты.

# КӨЛЕП-ЕЛМАЕП ЯШӘГӘН ЕЛЛАР

## *Пешка*

70 нче елларда Актаныш районына әдәбият атналыгы үткәрергә бардык. Уңыш бәйрәменә туры килдек: районга Кызыл Байрак тапшырырга Министрлар советы рәисе урынбасары Мартынов шәхсән үзе килгән. Безгә әйләнеп карауччы да юк: һәммәсе Мартынов белән мәшгуль. Банкетка чакырдылар чакыруын, әмма түргә түгел, иң ерак бер почмакка утырттылар. Мондый мөнәсәбәттән кәефе киткән талантлы бер прозаигыбыз (исемен әйтмим инде), беркайчан да исергәне булмаган әүлиябез, үзенең нормасыннан артыграк төшерде. Тәртип бозмады, сүгенмәде, кайтты да шундук йоклап китте.

Иртән баш авыртып уяндым. Күршемдә генә Габдрахман ага Минский ята. Ә кичә йомшап төшкән егетебез берүзе күрше бүлмәдә. Тик ятасы килми бит.

— Габдрахман абый,— мин әйтәм,— әйдә, шаяртабыз тегене!..

— Мин әзер, башла!..— ди өлкән дустыбыз.

— Нишлибез, Габдрахман абый, егет безне харап итте... Мартыновның үзенә, лично үзенә әйтте бит: «Син — пешка!» — диде.

Габдрахман абый сюжетны шунда ук эләктереп алды:

— Миңа парторг буларак эләгә инде обкомнан, чакыралар инде аны да, мине дә... Барыбызга да эләгә инде моның өчен!

Тын гына көтәбез... Менә теге якның ишеге ачылды, аннан егетебезнең ялтырап торган күзләре күренде.

— Чыннан да мин аңа «Пешка!» дип әйттеммени?! — диде ул, кипкән иреннәрен чак кыймылдатып.

Габдрахман абый сикереп үк торды:

— Әйтмәгән кая... Бармагың белән борынына төртеп әйттең!

Казанга кайткач та без аның үзенә шаяруны ачмадык. Габдрахман абый, шушы сюжеттан файдаланып, «Пешка» диген хикәя язып, газетада бастырды. Үзе бик талантлы прозаик дустыбыз безнең усал шаяруыбызны

соңрак төшенгәндерме, юкмы, анысын белмим... Бәлки, ул бераз тынычлангач: «Хыялымда йөргән батырлыкны кылдым, «Пешка!» дип йөзенә бәреп әйттем! — дип, горурланып та йөргәндер...

## Көлдерүчесе булса, көлүчесе табыла

Актанышка килгәч, безне кунакханәгә урнаштырдылар. Бердәнбер клиент, яшьрәк кенә бер ир-егет каршылады.

— Сез әллә әртисләрме? — ди.

Тагын сюжет корырга туры килде.

— Әртисләр, кәнишне. Син үзең кем?

— Уполминзагта күкәй җыям. Сез нинди әртисләр соң?

— Менә монысы... (Марс Шабаевка күрсәтәм) Илһам Шакиров булыр...

Күкәй җыючыбыз илһамланып, шатлыгыннан үкереп җибәрде:

— Илһам, бу синме?! Исәнме, малай?! Исеңдәме, синең белән бер утыруда йөз күкәй ашаган иек?..

— Истә,— ди «Илһам»,— дөрес, мин аларның икесен генә ашаган ием...

— Менә монысы,— мин әйтәм, Габдрахман абыйны күрсәтеп,— халык артисты Габдрахман Хәбибуллин. Монысы — атказанган артисткабыз Гөлшат Сәйфуллина... (Гөлшат Зәйнашева башын ия). «Зәңгәр шәл»не караганың бармы?

Егетебез, түзә алмыйча, баскан урынында бии башлый:

— Габдрахман абзый, тегене күрсәтегез инде... Хәзрәтне!..

«Артистыбыз» ялындырып тормый, шундук рольгә кереп китә, Гөлшатның күкрәк тирәсенә үрелә:

— Күкрәгеңә җеннәр оялаган, Мәйсәрә, өшкерергә кирәк!..

Күкәй җыючыбыз, рәхәтләнеп, тәгәри-тәгәри көлә:

— Габдрахман абзыкаем, тагын бер генә тапкыр күрсәт инде, зинһар өчен!..

Габдрахман абзый тагын уйнап күрсәтә, тегене тагын тәгәрәтә.

Әле дә безнең шундый тамашачыларыбыз бар! Татар театрын әнә шул тәгәрәп көлә белүчеләр һәм тәгәрәтеп көлдерүчеләр, елатучылар — драматурглар тота.

## «Спасибо за компанию!»

Татарстан композиторларының бер съездында композитор Бату Мөлеков бик әйбәт нотыгын тәмамлады да, иң ахырдан: «Спасибо за компанию!»— дип очлады. «Спасибо за внимание!» дип әйтергә теләгән Батуны зал көлү, кул чабулар белән озатты.

Болай гына ярый әле. Язучы дустыбыз Шамил Рәкыйпов, китап нәшриятындагы күңелсез, әчпошыргыч профсоюз җыелышын: «Товарищи, на этом повестка дня испорчена» дип бетергән. Җыелыш халкы, йокыдан уянып, кайтып китәргә теләмичә, ярты сәгать көлгән. Кем белә, Шамил, бәлки, юри генә шулай әйткәндер. Ялгышса да, бик дөрес ялгышкан.

## Үпкәләүчеләр иде...

Теләсә кем белән шаярып булмый — үпкәлиләр. Хәтта ата юморист (тагын үпкәләр инде) Гамил Афзалның хәтерен калдырганым бар. «Нихәл, Афзал Гамильтон?» дигән идем: «Минем мулла кушкан исемем юкмыни?»— дип, җитди башын читкә борды. Дәү Советка эшкә кергәнче, Гәрәй Рәхим ни әйтсәң дә үпкәләми иде.

Гәрәй Рәхим — керәшен,
Кулларыңа тәре тотып,
Төшләремә керәсең,—

дигәч тә, сап-сары, җип-җирән сакалын дерелдәтеп, шаркылдап көлде. Үз-үзеннән каһкаһә белән көлүдә Гәрәйгә тиң юк иде. Хәзер югалды... Үпкәләтерләр, дип безнең янга килергә курка, ахры... Үпкәләми торган батыр шәхесләрне эзләп, бер тәҗрибә ясап карамакчы булдым. Тәҗрибә объекты итеп Ризван Хәмид белән Рөстәм Мингалимне сайладым. Күп кенә язучылар ял итеп, юк-бар сөйләнеп утырган бүлмәдә Тукайдан цитата алдым:

«Пушкин, Лермонтов, Тукай —
өч йолдыз ул...»
Һәм үземнән өстәдем:
«Ризван, Мингалим вә Юзи —
өч дуңгыз ул...»

Башкаларга кушылып көлгән булдылар, үпкәләмәделәр

бугай. Ә үпкәләтәсе килә... Бәлки, моны укыгач, Дуңгыз елында булса да үпкәләрләр...

Аларны да Дәү Советка алмасалар ярар иде...

## Якташка хөрмәт

60 нчы елларда Муса Җәлилнең туган якларына — Оренбург өлкәсендәге бер авылга килдек. Ялгызы гына яшәүче бер абзыйга фатирга керттеләр. Абзыйның кәефе бәйрәмчә. Бераз гына төшереп тә алган. Рафаэль Мостафинның якташ икәнен белгәч, аңа өстенлек күрсәтергә теләп, иң яхшы урынны аңа тәкъдим итте:

— Менә, энем, синең караватың... Һич тә борчылма, изге урын бу: әле берничә көн элек кенә шушында карчыгым җан тәслим кылды...

Әдәби кичәдән соң без ул өйгә кайтмадык, әлбәттә.

## Иң кыска автограф

Язучы булып өлгергән һәм нәшриятта бер-бер артлы китаплар чыгара башлаган Туфан Миңнуллинның тәкъдиме миңа ошады.

— Әйдә, иң кыска язылган автографка икебез өчен генә конкурс игълан итәбез! — диде ул.

Һәм үрнәк та күрсәтте. «Кеше бул!» исемле яңа гына чыккан китабына автограф язып бирде. Титул битендә: «Илдар, мә!» — дип язылган иде.

Минем дә китап чыкты. Мин дә аңа автограф чәпәдем: «Туфан, тот китабымны!» Озынрак килеп чыкты, кәнишне. Туфан җиңде. Мин рәхәтләнеп җиңелдем.

## «Ак бар ие...»

Язучылар союзында эшләгән чак. Минем бүлмәгә Шәүкәт Галиев керде. Шул вакыт телефон чылтырады. Трубканы алам. Ерактан булгандыр, тавышы әйбәт ишетелми. Шулай да Туфан икәнен шәйләдем: «Кибеттә ак бар ие! Сиңа кирәкме?» Шатлыгымнан үкереп җибәрдем. «Ак бар ие?! Кирәк! Бик кирәк!!!» (Ак аракыга кытлык чоры иде бу.) Шәүкәт кулымнан трубканы тартып алды: «Туфан, миңа да ал! Күпме ала аласың — шул кадәр!»

Киттек Шәүкәт белән икәүләп Туфанның өенә акны алырга. Бара-бара татлы хыялларга чумабыз: «Бер яртысын өч борынга салырбыз инде...»

Звонокка бастык. Ачты Туфан ишекне. Байларча кыяфәт белән безне түргә чакырды: «Әйдәгез, җегетләр, сөендерим әле үзегезне!»

Һәм, кулын бөеренә таянып, икенче кулы белән түр бүлмәнең ишеген ачты.

— Менә! Туфанның игелеген күрегез!

Һәм без... авызыбызны ачып, катып калдык: бүлмә тулы аквариум иде...

— Ни бу?! Кайда ак?

— Нинди «ак?» Нәрсә «ак?»

— Син бит безгә «ак бар ие» диеп әйттең...

— Нинди ак? Нәрсә ак? Мин бит сезгә АКВАРИУМ дип әйттем.

Өчебез дә хәлсезләнеп утырдык.

— Мин боларны кая куям инде? Алыгыз инде берәрсен булса да...

— Минем үземдә дә өй тулы аквариум!

— Миндә дә...

...Ул аквариумнарны соңыннан кая олактырып бетергәндер, анысын Туфан үзе генә беләдер. Бер-беребездән уңайсызланып йөреп, бу хакта беребез дә сүз башламады.

Озак еллардан соң, Туфаннан рөхсәт алып, ояла-ояла, көлә-көлә, менә шуны язарга ниятләдем.

## «Вперед, Шакир абый!»

Иң кызык кешеләрнең берсе Шакир Мәҗитов иде. Үзе артист, үзе композитор, үзе драматург. Үзе өлкән кеше булса да, мине ни өчендер якын күрде. «Шофер» дигән әзер көенә миннән сүзләр яздыртты. «Таныш моңнар» радиопостановкасына музыка язып, поэманың халыкка таралуында булышты. Бик ярлы яшәвенә карамастан, бик шаян, оптимист кеше иде.

«Резидәкәй» китабын чыгаргач, нәшрияттан шактый гына гонорар алган да моны үзенчә билгеләп үткән. Башта ресторанга кереп үзен сыйлаган. Кесәдәге акча әтәч булып кычкыра гына бит! Кергән Шакир абый хәрбиләр кибетенә. Баштанаяк генерал формасына киенгән. Шул

кыяфәттә Бауман урамы буйлап киткән. Кулларын алга таба сузып, үз-үзенә команда бирә икән:

— Вперед, Шакир абый!

Танучылар да, танымаучылар да аңа хөрмәт белән юл бирәләр икән. Бөтен урамның күңеле шат, авызлары ерык.

Соңыннан мин Шакир абыйдан бу хакта сорашып карадым.

— Әйе, булды андый хәл,— диде ул,— бала чакта генерал булырга хыяллана идем, ичмасам, бер генә көн булса да, хыялымда яшәп карадым. Генерал булырга хыялланмаган солдат юктыр ул!..

## Язучыларның хуҗасы

Язучы Абдулла Әхмәт мәзәкләр сөйләргә әвәс, юморга бик юмарт шәхес иде. Аны күргәч үк кешеләрнең авызы ерыла иде. Ул редактор булган «Пионер» («Ялкын») журналына мине җаваплы секретарь итеп эшкә алганда, иң беренче соравы шул булды:

— Көлә беләсеңме?

Ул мине көләргә, шаярырга өйрәтте. Бигрәк тә дусты Идрис Туктар белән очрашсалар, көлеп, мәзәк сүзләр әйтеп туялмыйлар иде. Ул заманда язучыларның Хуҗа Насретдины, мөгаен, Абдулла абзый булгандыр. Бервакыт союз рәисе Афзал Шамовка кергән дә:

— Афзалетдин, язучы үлгәч, күпме акча тотасыз әле? — дип сораган.

— Фәлән сум,— дигән Афзал ага.

— Син инде, Афзалетдин, үлгәч мине күмәргә акча әрәм-шәрәм итмә, үзем исән чагында, менә хәзер бир, тегендә миңа акчаның хаҗәте юк...

Гариф Гобәй, Абдулла абыйны коридорда күрү белән, тегесе берәр сүз әйтеп өлгергәнче үк, көләргә тотына иде. Аның көлүе тракторны кабызгач, мотор дерелдәвен хәтерләтә иде.

Вафатына берничә ел калгач, Абдулла абый телдән калды, хәрәкәтсез ятарга дучар булды. Шулай да юмор хисен югалтмады. Укол кадарга япь-яшь, бик чибәр шәфкать туташы килгәч, шәрә тезләренә сузылган, диләр... Бәлки, легендадыр, әмма мин моңа ышанам.

## Бу бит безобразие!

60 нчы елларда йөзәр кешелек банкетлар үткәрү гадәти хәлгә әйләнде. Ай саен, атна саен бер банкет... Мәҗлесләрне мәшһүр аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов әзерли, үзе үк тостын да әйтеп җибәрә. Заһит ага Хәбибуллин юбилей мәҗлесенә мине дә чакырды, хатта тамада итеп билгеләде. Тост артыннан тост, дус артыннан дус... Берзаман, малай, пенсионерлар кызып китте: татар ашханәсен дер селкетеп биергә тотындылар. Бии торгач, абзыйларның берсе ауды... һәм шунда ятып, җан тәслим кылды. Мәҗлес халкы тарала башлады. Заһит ага, ни әйтергә дә белмичә, тегене әрли: «Бу бит безобразие! Кешенең юбилеена килеп, шулай итәргә ярыймыни инде?!»

## Аның соңгы көе

Заһит ага Хәбибуллинны соңгы юлга озатып, берничә ай үткәннән сон, Сибгат ага Хәким миңа болай диде:

— Заһитның өстәленнән язылып беткән соңгы көен тапканнар. Синең сүзләргә язган. Бу хакта миңа Зәйнәп Хәйруллина әйтте.

Зәйнәп ханымны табып, аңардан бу көй белән кызыксынуын үтендем. Ул аны композиторның эш өстәленнән алып чыккан. Миңа тапшырды. Мин радиога илттем. Шактый вакыт узгач, Георгий Ибушев башкаруында шул җырны ишеттем: минем сүзләргә Заһит ага иҗат иткән «Ерактагы үзәннәр» көе...

## Сибгат абыйның Исмайдан «үч алуы»

Саба районында очрашудан соң мәҗлестә утырабыз. Сибгат абый белән без бокалларны күтәрмибез, сөт эчеп утырабыз. (Кайвакыт минем дә шундый чак булгалый.) Композитор Исмай ага Шәмсетдинов безне бөтен халык алдында «мыскыл итте»:

— Кыстамагыз ул молокососларны!

Ярый. Хуп. Батты кояш. Йокларга яттык. Сибгат абый белән Исмай абыйның караватлары янәшә.

Йоклап киттек дигәндә генә, Сибгат абый, мыштым гына, Исмай күршесенә дәшә:

— Нихәл, Ислемай Сасытдинов?!

## Барысын да белүче Гүзәл

1958 елны Салих ага Баттал белән чирәм җирләргә командировкага киттек. Уфада бер көнгә тукталып, кунакханәгә урнашу белән, башкорт язучысы Сәгыйт Агиш килеп керде. Биш яшьлек оныгын да иярткән.

— Сез минем Гүзәл исемле бик шәп оныгым бар икәнне белмисез инде, әлбәттә? Ә ул белә, барысын да белә. Гүзәл, син Салих Баттал бабаңның «Әбине талаганнар» дигән шигырен беләсеңме?

— Беләм! — ди Гүзәл.

— Менә күрдегезме?! — ди Сәгыйть ага.— Аның бабасы әле Илдар кустының шигырен дә белә!

Һәм җибәрде сөйләп мин үзем дә яттан белмәгән шигыремне.

— Менә, Гүзәл, боларның кемнәр икәнен беләсеңме инде?

Бер генә сүз белә торган Гүзәл бабасының сүзләрен дөреслән кенә тора:

— Беләм, беләм...

— Әле белмәсәгез, Гүзәлне киләчәктә белерсез әле,— ди мәшһүр башкорт әдибе.

Хәзер Гүзәл Агишеваны бик күпләр белә. Ул Башкортстанның танылган журналисты, «Комсомольская правда»ның корреспонденты.

## Татар әдибенең урысча юбилее

— Мин урысчаны болай яхшы беләм, акцент кына комачаулый. Калага өлкән яшьтә килүнең нәтиҗәсе инде бу,— ди торган иде әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин.

Актерлар йортында Фатих Әмирханның юбилей кичәсе. Залда бер генә дә урыс юк. Әмма докладчы Мөхәммәт ага Гайнуллинның докладчы урысча әзерләнгән, өлкә комитетында тикшерелгән. Докладчының теле телгә йокмый, сиптерә генә:

— Билики татарский писатель Фатих Әмирхан родился тычасы вәчимсот... гаду... безбереминны скончился тычасы дебәтсот...

Президиумда утыручы Мөҗәһит Вәлиев, көлүенә түзә алмыйча, битен кулы белән каплый. Залда утыручылар

да кычкырмыйча гына, эчтән генә көләләр. Һади Такташның сүзләре искә төшә:

Татарларга татар була торып,
Урысчалап доклад укыйлар...

Мөхәммәт агага өстән шулай кушылгандыр инде. Ә ул үзе әдәбият фәне өчен җанын фида кылырга әзер торган зур галим, олы җанлы, кече күңелле шәхес иде. Остазымның юбилей мәҗлесендә аңа багышлап әйтелгән тостым — чын күңелдән:

Сездә — иң асыл сыйфатлар,
Тыйнаклык, әдәп, оят...
Талантыңа баш ияләр
Тел, тарих, әдәбият,
Узган чорның үзегез ачкан
Хәзинә, мәрҗәннәре...
Сез инде татар фәненең
Мөхәммәт пәйгамбәре.
Заманча бер тост күтәрик
Пәйгамбәр хөрмәтенә,
Аны дәвам итүчеләр —
Мөхәммәт өммәтенә!

*28 сентябрь, 1983*

## Рифмачылар

Татарстан Язучылар союзында консультант булып эшләгән вакыт. Җәйге эссе көннәрнең берсендә идарә рәисе Зәки Нури минем бүлмәгә керде дә:

— Әйдә, тиз генә су коенып кайтабыз,— диде. Ленин күпере янындагы дамбага барып, чишенеп, суга керергә базмыйча басып торабыз.

Шул вакыт Зәки Нури:

— Әйдә, рифма әйтешәбез,— ди.

— Син рәис кеше, башла!

Зәки абый, башындагы чал чәченә кагылды:

— Минем башта чал бар... Тап рифма!

Мин дә озак уйлап тормадым:

— Минем күттә — чалбар!

Рәисем рифманы ошатмады, ахры, көлмичә-елмаймыйча, суга чумды.

Минем тарафтан әдәпсезлек булды инде... Тик шулай да шәп юморист Зәки Нури үзенең үпкәләвен эштә сиздермәде. Икебез да оныттык, башка рифма әйтешмәдек.

## Интернациональ бурычлар

Пьесаларымның кайбер республикаларда башка телләрдә дә куелган чагы. Борын шактый югары, кесә ягы да тамак төбе белән сөйләшерлек. Мин эшләгән Язучылар союзына галстуклы-күзлекле, бик тә интеллектуаль кыяфәтле берәү килеп керде. Үзе белән таныштырды.

— Мин — Киевтән. Франко исемендәге драма театрының әдәбият бүлеге мөдиремен. Сезнең «Бөркетләр кыяга оялый» дигән комедиягезне куйдык. Юл уңаенда сезне күреп чыгарга ниятләдем.

Кунагымның гозере дә бар икән: каяндыр кайтып килгәндә, поездда акчасын югалткан. Казанда төшеп калырга туры килгән. Әлбәттә, авторның ярдәменә ышана. Миннән башка бире дә беркемне дә белми. Кайткач ук бурычын җибәрәчәк.

Әлбәттә, шактый гына акча биреп, хәерле юл теләп, озатып калдым.

Бер атна вакыт узгач, дачадан өйгә кайткан идем, подъезд төбендә бик тә интеллектуаль кыяфәтле берәү мине көтеп тора.

— Сез Юзеев Илдар түгелме? — ди ул, акцент белән.— Мин сезне эзләп килдем. Ригадан. Яшьләр театрының әдәбият бүлеге мөдире. Сезнең пьесаны әзерлибез. Кайтканда акчамны урладылар. Кайткач ук бурычымны җибәрермен.

Әлбәттә инде, шактый гына акча биреп, хәерле юл теләп озаттым. Әлбәттә инде, алардан җилләр исте... Әлбәттә инде, мин пьесаларымның Киевтә дә, Ригада да куелмавын сиздем. Театрда эшләүләренә дә шикләндем. Авыр чакта ярдәм итү безнең канга сеңгән бит.

Хәзер берәр интеллигент кыяфәтле адәм мине эзләп килсә, котым чыгып, кесәгә тыгылам. Әмма инде кесәдә җилләр уйный. «Зав. лит»ларым гафу итәрләр...

## «Ботен доньяга танылган»

Буа районында әдәби очрашуларда йөрибез. Колхоз рәисе халыкка мине тәкъдим итә:

— Сезнең алдыгызда — үзенең брашуралары, роман-

нары, писсылары белән бөтен дөньяга танылган Юлдар Гүзиев!..

Балык Бистәсе районының бер мәктәбендә әдәбият укытучысы мине балалар белән болай таныштырды:

— Безгә кадерле кунак — Илдар абый Нил Юзеев килде!

## Хикәя язсам, ышанмаслар...

Хатыным Тәфтилә сөйли:

«50 нче елларда мәктәптә укыганда (Башкортстанның Тәтешле районы), пионер лагерена җибәрделәр. Бервакытны су коенганда, бата башладым. Вожатыебыз Әнгам абый коткармаса, су төбенә китә идем...»

...Булачак хатынымны коткаручы кеше — Башкортстанның танылган шагыйре һәм драматургы Әнгам Атнабаев, Азамат исемле малаен ияртеп, Казанга килде. Аларны Аккош күленә алып киттек. Көн бик эссе иде. Иделдә су коенабыз. Шул вакыт күрәбез: Атнабайның йөзә белми торган Азаматы юкка чыкты... Моны күреп калган Тәфтилә, күз ачып йомганчы, Азаматны су төбеннән сөйрәп чыгарды.

Хәзер бу ике вакыйганы, очрашкан саен, көлеп искә төшерәбез: чыннан да, Атнабай дус коткармаса, хатынымнан колак каккан булыр идем.

Бу хакта берничә мәртәбә хикәя язарга дип омтылып та, язмый калдым: укучылар барыбер ышанмаслар: «Ясалма, тормышта алай булмый»,— диярләр иде...

## Рәиснең соңгы шаяруы

Яшь чакларда без эштә дә, ял иткәндә дә юктан кызык табарга ярата идек. Бервакытны шулай нәшриятның ул чактагы яшь-яшь редакторы Рәис Даут белән кибеткә кердек. Рәис, шаяртырга уйлап, минем кесәгә кергән. «Мин» дигәнем бөтенләй башка кеше булып, моның кесәгә чумган кулын эләктереп алган. Рәис, ялгышканын сизеп, торараштай катып калган. «Я думал, што Вы — Илдар!..» — дигән дә кибеттән чыгып шылган. Шул вакыйгадан соң Рәис дус шаярмас булды, бик тә җитди шәхескә әверелде һәм тау-тау иҗади эшләр башкарды.

## Үземне дә эләктерделәр...

Әле быел гына үзем дә эләктем. Онытыбызны, коляскада тәгәрәтеп, урамга алып чыктык. Дәү әнисе кибеттән шырпы тартмасы кадәр генә сырок алып чыкты да коляска артындагы җәтмәгә салды. Икенче кибеткә сөт алырга киттек. Мин оныгым белән культура паркы янындагы кибетнең ишеге төбендә калдым, дәү әнисе сөткә керде. Көтәбез. Чыкмый. Оныгым: «Мәм-мәм!» — дип еларга тотынды. Дәү әнисен эзләп кибеткә юнәлдек. Колясканы тәгәрәтеп эчкә үк уздым. Дәү әни... юк. Кире чыгып барганда, мине куып җитеп, туктаттылар. Тамара исемле керәшен кызы миңа карап кычкыра:

— Ты украл сырок! Обратно!

Ни әйтергә белмичә, катып калдым. Татарча аңлатып карыйм:

— Без аны теге кибеттә сатып алдык!

— Юк, урладың!

— Үз күзләрең белән күрдеңме соң?

— Үз күзләрем белән күрдем!

Шул вакыт, шау-шу ишетеп, дәү әнисе килеп чыкты.

— Дәү әнисе?.. Без аны теге кибеттә алдык бит!

Ышандыра алмадык. Сырокны тартып алып тартмага ыргытты. Дәү әнисе янә бер сырок сатып алды. «Ул андый кеше түгел, ул татарның танылган язучысы»,— дип тә әйтеп карый, теге колагына да элми. Әллә белми, әллә белсә дә, бар дип тә белми. Гомер буе шушы кибеттә йөреп, мин аны беләм.

Әллә ничә төн йоклый алмадым. Тик торганда бер тиенлек нәрсә урлауда гаепләп яла яксыннар әле! Берничек исбатлап та булмый. Авылдан килгән татар кызы үз язучысын нинди авыр хәлдә калдырды... Такташның «тәгәрмәч урлауда гаепләнеп, үз-үзенә кул салган» саф җанлы Мокамае искә төште. Менә шундый вакыйгага юлыгып, гаепсез икәнлекләрен исбат итә алмыйча, төрмәләрдә газап чигүче никадәр бәхетсезләр бардыр әле...

## Склероз

Алтмышынчы елларда берничә язучы мехкомбинат клубына әдәби очрашуга бардык. Сүз өлкән язучыбыз Мирсәй Әмиргә бирелде. Ул ашыкмый-каба-

ланмый гына ике битле «Склероз» дигән шаян хикәясен укырга тотынды. Укыды-укыды да туктап калды.

— Гафу итегез... мин хикәямнең икенче битен өйдә онытып калдырганмын икән... Склероз шул була инде...

Тыңлаучылар, бик канәгать булып, көлә-көлә, кул чаптылар.

Бик шаян кеше иде мәрхүм. Идарә рәисе буларак, җыелышны алып барганда әйткән сүзләрен искә төшерәм:

— Без, татар язучылары, тыйнаклыгыбыз белән мактана-мактана, мокытка әйләнмәбез микән?

Җыелышларны алып барырга, йомгакларга бик оста иде. Һәрбер бәхәс тудырган әсәр турында саллы, дәлилле, катгый сүзен әйтә. Аннан соң беркем дә сүз әйтергә кыймый, һәммәсе канәгать кала. Мондый вакытларда склерозы юк, хәтере бик шәп иде...

## «Үлемемә сезне гаеплəячəкмен...»

Татарстан Язучылар берлегенең яшь авторлар белән эшләү бүлегендә карт большевиклар, биографияләрен язып, интектерәләр иде. Кулъязма тоткан берәр абзый ишектә күренсә, әле дә котым алына. «Бу әдәби әсәр түгел» дигәч, шунда ук минем өстән жалу белән өлкә комитетка йөгерәләр иде. Алардан да ярдәм алалмагач, Гыйсмәтуллин дигән берәү берьюлы өч инстанциягә телеграмма сукты: «Әгәр мин килүгә романым басылмаса, поезд астына ташланам...» Бу юлларны күргәч, укыгач, эсселе-суыклы булып киттем. Соңгы җөмләне укыгач кына тынычландым: «Үлемемә сезне гаепләячәкмен!»

Абзыебыз үләргә уйламый икән ич! Һәм, чыннан да, телеграмма артыннан: «Кая, авторский экземпляр бирегез!» дип, үзе килеп керде.

## Куктән алган...

Редакция ишегеннән бер абзый килеп керде дә:

— Минем бер генә шигырь, немедленно басыгыз! — диде.

— Башта укып карыйк,— мин әйтәм.

— Укып та тормагыз,— ди абзый,— моны басмый калу мөмкин түгел.

— Ник шулай бик ышанып әйтәсез?

— Мин күкләр белән бәйләнгән зат. Бу шигырьне миңа күктән бирделәр.

Мондый шигырьгә тиз генә бәя бирә алмавымны әйтеп, алып калдым.

Берничә көннән ул басылып чыккан шигырен сорап керде. Мин язманың басарлык булмавын аңлатырга тырыштым.

— Бу фикер белән килешә алмыйм. Мин аны күктән алдым!

— Мин үзем дә күкләр белән бәйләнгән зат. Мин дә алар белән бәйләнешкә кердем.

— Ни дип әйттеләр?

— Ул аны күктән түгел, күттән алган,— диделәр...

Карт авторым үпкәләмәде дә, елмаймады да. Күкләр бәясе белән килеште булса кирәк...

## Җимерелгән дивар

Казан император университеты студенты Володя Ульяновны кулга алган жандарм урамдагы таш диварга карап:

— Юкка маташасың, егет, синең алда стена бит! — ди.

Володяның җавабы катгый:

— Стена, ләкин черек, төртсәң — аварга тора!

...Профсоюз урамындагы шул дивар яныннан узганда, мин һәрвакыт әнә шул сөйләшү турында уйлый идем.

Бердәнбер көнне узып барсам — күрәм: таш дивар җимерелгән. Бер малай аста кала язып, чак исән калган диделәр.

Дивар ауды... төртмәсәң дә... совет власте елларында...

## Нәби абыйны сагыну

Нәби абый бервакытны әйтә миңа:

— Минем хакта бер шигырь яз әле, түлке кызык булсын. Хәзер үк! — ди.

— И дусларым, сезнең белән
Күтәрелә давление,
Ул тагын да күтәрелә
Күрсәм Нәби Дәүлине!

Язучыларның яңа бинасын яңгыратып, рәхәтләнеп көлде. Шаярып үзеннән көлсәләр дә үпкәләми иде. Без үзебездән көлсәләр, мыскыл итү дип кабул итәбез...

# Автограф

Көтмәгәндә-уйламаганда хат ташучы бандероль калдырып китте. Адресына күз төшергәч тә аңладым: Мөслимнән, Фоат Садриевтан. Калын гына төргәк. Әлбәттә, яңа китабыдыр инде. Шулай булырга тиеш тә: иҗатына карата әйбәт карашымны әйткәләп, дәртләндереп торам. Фоат та минем язганнарымны ихтирам итәдер дип уйлыйм. Ачтым төргәкне. Өр-яңа китабы: «Бәхетсезләр бәхете». «Казан утлары»нда укып, үзенә «шәп роман!» дип мактаган идем. Шуңа җавабыдыр инде. Бик табигый.

Ярар, укыйм автографны. Күз йөртеп чыгу белән төшендем, миңа олуг ихтирамын белдергән:

«Татар драматургиясен чиксез биеклекләргә күтәргән олы талант һәм берүзе йөз кешелек эш башкаручы» дип, мине күкләргә мендергән. Алай ук түгел инде түгелен, без автограф язганда бер-беребезнең күңелен күрү өчен артыгын мактап ташлыйбыз. Иң аз дигәндә, һәрберебез — классик! Алай түгеллеген дә беләбез — барыбер рәхәт! Фоат та шыттырган инде анысы, әмма ләкин мине драматург итеп таныган. Беләм, танымаучылар да бар. Афәрин, Фоат дус, ниһаять, син мине драматургиядә үз урыныма куйдың. Мин дә әйткән идем «синең урының Тукай лауреатлары сафында» дип...

Үземне шәп драматург тоеп, барлы-юклы борынымны бераз югары күтәреп йөргәндә, берчак сөенечемә күләгә төште. Туктале, нигә әле ул мине драматург буларак күтәрә? Фактка килгәндә, минем төп жанрым шигърият ич. Ә мине остазым дип тә әйткәләгән Фоат шигъри иҗатым турында ләм-мим. Әһә, аңлашыла, ул минем шигъриятттәге илле ел гомеремне юкка чыгара, танымый. Мин аны елга бер булса да искә алып, сагынып йөргән булам. Сул аягы белән — күккә, уңы белән — күткә типте!

Туктале, тагын бер укып карыйм әле кайбер кимчелекләренә күз йомып мактаган романындагы автографны...

Күзлегемне киеп, һәр хәрефне якын китереп укыйм. Анда болай язылган иде:

«Татар драматургиясен чиксез биеклекләргә күтәргән олы талант һәм берүзе йөз кешелек эш башкаручы Туфан абыйга автордан. Чын яратып, хөрмәт-ихтирам белән Фоат Садриев».

Күзлегем астындагы катаракталы күзләрем маңгайга менде: нүжәли мине Туфан Миңнуллин белән бутаган?

Бутауларның төрлесен күргәнем дә, ишеткәнем дә бар. Юныс Әминовларны гына искә төшерик. Алар икәү: берсе министр урынбасары, икенчесе — драматург. Бервакытны Язучылар идарәсенә хат килде. Мәскәүдән. Кайсы Юныс Әминовка бирергә? Икесе дә бер үк вакытта Мәскәүдә укыганнар. Җибәрәләр хатны Юныс Әминовка. Укый моны ачып... хатыны: «Оныттыңмыни, дорогой, Москвада очрашкан төннәрне? Нигә язмыйсың? Яратып, Алла» ...Ике Юныс та: «Юк, бу хат миңа түгел, теге Юныска» дип чак-чак котылалар. Алла сакласын мондый буталудан...

Нишләгән бу Фоат? Фамилиям дә Миңнуллин түгел. Роберт белән бутаса бер хәл. Мондый халәт, гадәттә, бөекләргә хас. Әллә үзен бөек дип уйласыннар өчен юри бутады микән? Әллә инде берәр комедиягә сюжет эзлиме?

Мине элегрәк тагын да бөегрәк Туфан белән бутаганнар иде инде. Хәсән Туфанның үзеннән соң чыккан «Гүзәл гамь» исемле китабында дүрт юллы шигырь кергән.

Ат карагы»н язганчыга кадәр
Шагыйрь Туфан атын урлаган.
Тик, Миңнуллин бәгърем, җан кисәгем,
Сине карак диеп хурламам.

Бәй, бу бит минем шигырь! Заманында Язучылар оешмасының Фаил Шәфигуллин мөхәррирлегендә чыгарылган менә дигән стена гәзитендә тәкъдим ителгән иде. Ничек ул Хәсән абый шигыре булып китте икән? Минемчә, бөек шагыйребез ул язманы кызык итеп күчереп алган да архивында калдырган. Ә китапны төзүчеләр Туфан шигыре дип тәкъдим иткәннәр.

Уйладым-уйладым да Фоатка да үпкәм бетте. Мине дә бөекләр арасында күрергә хыялланып, турысын әйтергә кыенсынып, махсус бутамады микән? Туфанның үзен эзләп табып, сорыйм әле: аңа автографлы китап килгәнме, юкмы? Чылтыраттым.

— Сиңа Мөслимнән берәр бандероль килмәдеме?

Туфан җавабын кыска тотты:

— Фоат сиңа дигән китабын миңа җибәргән...

## ЙӨРӘККӘ ЯЗЫЛГАН ИСЕМНӘР

(Илдар Юзеевка бүләк ителгән кайбер автографлы китаплар)

*«Такташлар, Җәлилләр менгән югарылыкка омтылучы талантлы Илдарга. Хөрмәт белән Сибгат Хәким. 30.09.69.»*
(1968 елны чыккан «Җылы сүз» китабы.)

*«Илдар дуска. Мине бик озак газаплаган бу китапны сиңа истәлек итәсем килә. Шәйхи Маннур. 29.11.68»*.
(1968 елны чыккан «Муса» романы китабы.)

*«Илдарга— дуска, чын мәгънәсендәге Кешегә, иптәшкә һәм «бөек» белән «күренекле» арасындарак тора торган замандаш һәм йөрәктәш шагыйремә. Тирән ихтирам хисе белән: Фатих Хөсни. 12.02.1969»*.
(1966 елны чыккан «Сайланма әсәрләр», I том.)

*«Илдар! Күкнең кояшлы чагын гына түгел, болытлы минутларын да күрә белүче җете күзләреңне, күреп кенә дә калмыйча, чын ихластан кичерә белүче сизгер йөрәгеңне мактап, тирән ихтирам хисе белән: Фатих Хөсни. 1.06.1977»*.
(1977 елны чыккан «Мәйдан» китабы.)

*«Җор күңелле, шат күңелле Илдарга — зур ихтирамым билгесе. Мөхәммәд Мәһдиев. 14.11.73»*.
(1973 чыккан «Фронтовиклар» китабы.)

*«Илдар! Хәзерге шигърият дөньясына караган кайбер күзәтүләрем тупланган әлеге китабымны якын туганлык билгесе итеп кабул ит. Иҗатыңда яңа үрләр, тормышыңда уңышлар һәм сәламәтлек теләп, абыең Нил Юзиев»*.
(1981 елны чыккан «Шигърият дөньясы» китабы.)

*«Якташым — туганым Илдар Юзеевка бик яратып-сөеп, ышанып, олы бәхет теләп: Гайнан Әмири. 10.06.61»*.
(1961 елны башкортча чыккан «Һайланма әсәрзәр» китабы.)

*«Илдарга, әйбәт каләмдәшкә бер истәлек итеп, Нури Арслан. Казан. 9.11.1971»*.
(1971 елны чыккан «Моңсар» китабы.)

*«Илдар дустым, Сажидә сезнең гаиләне искиткеч ярата иде. Үлмәс шагыйрәбезнең якты истәлеге булсын. Зур хөрмәт белән: Әдип Маликов. Әлмәт. 16.10.81».*

(Сажидә Сөләймpraнованың 1981 елны чыккан «Сабыр канатлары» китабы.)

*«Илдар! Сиңа дуслык, туганлык, рәхмәт тойгылары, иң изге теләкләр белән: Мостай Кәрим. 6.08.77».*

(1977 елны И.Юзеевның кереш сүзе белән Казанда чыккан «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы.)

*«Юлчы» капчыгыннан беренче бүләк сиңа, Илдар, шигъри сүзең, ихлас сүзең өчен! Тирән хөрмәт белән тапшырам. Әмирхан Еники. 2.10.79».*

(1979 елны И.Юзеев кереш сүзе белән чыккан «Юлчы» китабы.)

*«Илдар!*
*Вакыт мәңгелек тә, гомер кыска,*
*Гомерләрнең белик кадерен.*
*Әнгам Атнабай. 4.06.88. Өфө».*

(1988 елны башкортча чыккан «Һайланма әсәрзәр» китабы. I том.)

*«Илдар! Уфада беренче тапкыр татарча чыккан шигырьләр китабымны бүләк итәм синең шатлык көнеңдә. Ә.Атнабай. 14.03.94».*

(И.Юзеевның Уфада үткәрелгән иҗат кичәсендә тапшырылган «Шигырьләр, поэмалар» китабы.)

# Эчтәлек

Балалык . . . . . . . . . . 9
Малай белән бабай . . . . . . . . . . 10
Сакаллы маэмай . . . . . . . . . . 11
Гөлшат гөмбәгә барган . . . . . . . . . . 12
Каз бәбкәсе . . . . . . . . . . 13
Мөгезе булса да . . . . . . . . . . 13
Миябикә нигә боек? . . . . . . . . . . 14
Кар өстендә дөяләр . . . . . . . . . . 15
Бәби ай . . . . . . . . . . 16
Самат киреләнә . . . . . . . . . . 17
Әбием әкиятенең дәвамы . . . . . . . . . . 18
Самат хат яза . . . . . . . . . . 19
Самат белән җил . . . . . . . . . . 20
Тук-тук бабай . . . . . . . . . . 21
Уяныгыз . . . . . . . . . . 22
Гөл нигә шиңгән? . . . . . . . . . . 23
Конфет нигә качкан? . . . . . . . . . . 24
Карбыз малай . . . . . . . . . . 25
Балык малай каптыра . . . . . . . . . . 26
Их, малайлар. *Т. Вәлиев музыкасы* . . . . . . . . . . 27
Туп йоткан бегемот . . . . . . . . . . 28
Самат белән саескан . . . . . . . . . . 30
Бәбкә үлән . . . . . . . . . . 32
Язны озатучы акчарлак . . . . . . . . . . 33
Иң кызыгы . . . . . . . . . . 34
Агылый белән Тагылый . . . . . . . . . . 35
Кем җүләр? . . . . . . . . . . 36
Кем карт? . . . . . . . . . . 37
Мокыт барган кунакка . . . . . . . . . . 38
Шукбайның Йабкуш белән очрашуы . . . . . . . . . . 39
Оныкка сөйләгән әкият . . . . . . . . . . 41
Куянны кем аткан? . . . . . . . . . . 42
Карга күмелгән аю . . . . . . . . . . 43
Тутый кош . . . . . . . . . . 44
Жираф . . . . . . . . . . 45
Макай белән Акбай . . . . . . . . . . 46
Карбыз белән Фарваз . . . . . . . . . . 47
Тукта, ник качасың? . . . . . . . . . . 48
Экрандагы Әкрам . . . . . . . . . . 49
Ике хыял . . . . . . . . . . 50
Шайтан котырта . . . . . . . . . . 51
Татар аюыннан хат . . . . . . . . . . 52
Шомбай белән шоколад . . . . . . . . . . 54
Мактанчыклар . . . . . . . . . . 55
Кунакка йөрүче мәчеләр . . . . . . . . . . 56
Плюс белән минус . . . . . . . . . . 57
Көмеш балык тоттым . . . . . . . . . . 58
Шомбай Сөмбелгә хат яза . . . . . . . . . . 59

Эшләп арган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Шомбай шәп шигырь язган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Аждаһа килгән циркка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Түбәтәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Кәбестә белән кишер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Сәгыйть бара мактанып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Актүбә уенчыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Моңнар тулды йөрәгемә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Табылдык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Күзләрең нигә моңлы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Мине кем аңлар? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Унбер малай... бер бал корты . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Елады . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Соңга калган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Хатасыз ничек язарга? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Кемнәр нигә шатланган? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Рәсемнәр күргәзмәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Ни булган Вахитка? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Яз шикелле җылы абый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Упкын өстендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Бәхәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Песи тотучы тычкан турында чын әкият . . . . . . . . . 89
Бүреләр оясында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Пони малае нәни Җирәнкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Карга баласы Каркылдык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Аю сатам — кем ала? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Тукай теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110

**ИСТӘЛЕККӘ КАЛГАН ЕЛЛАР**

**Шагыйрьләр нинди була?**

Бездән соң кемнәр килер?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Гүзәл гамьгә борылыш... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Шагыйрьләр нинди була? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Көткәндә килгән кунак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Кыллары өзелсә дә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123

**Шигърият турында әңгәмәләр**

«Шигърият — үзе җыр ул» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Җырым минем һич бетәрлек түгел... . . . . . . . . . . . 132
Шагыйрь бәхетле буламы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

**Йөрәккә язылган исемнәр**

Җылы кулында — тургай чәчәге . . . . . . . . . . . . . . 141
Тулбай ае хәтерләтә аны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Ике җырчы арасында барам... . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Уфага барганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Ага сулар Болгарга... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151

**Укучы сорауларына җаваплардан**

«Гашыйклар тавы»... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
«Син каян?» дип сорасагыз... . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Әнкәй истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

Әнкәй шигырьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Мин каен булалмадым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
«Сәлам белән шагыйрь улыгыз...» . . . . . . . . . . . . 173
Яшьлек дустыма хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Рәми килгән минем әнигә . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Абыйлы еллар ядкәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Җырлар килгән монда бар дөньядан . . . . . . . . . . . 181
Остазларымны юксынганда... . . . . . . . . . . . . . . 182
Бер генә җырым калса да... . . . . . . . . . . . . . . 183
Тупчы Мәхмүт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Икебез дә Яңавылдан... . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Ул безне җырлатып яшәтте . . . . . . . . . . . . . . . 189
Атнабайлы еллар ядкәре . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Атнабай хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Сак-сок . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Үзенә үзе хөкем чыгарган... . . . . . . . . . . . . . . 198
Йөрәккә язылган яшел сүзләр . . . . . . . . . . . . . . 200
Бар иде шундый шагыйрьләр... . . . . . . . . . . . . . 202
Уятып китте... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Юбилей болай да була икән... . . . . . . . . . . . . . 205
Төнбоеклы яшьлегемә кайттым... . . . . . . . . . . . . 207
Барыбыз да шунда булмабызмы?.. . . . . . . . . . . . . 208
Труцкавецтан килгән хатлар . . . . . . . . . . . . . . 210
Наҗар абый ачкан капкадан... . . . . . . . . . . . . . 214
«Казан утлары»на кергәндә . . . . . . . . . . . . . . . 215
Халыкка туры карап... . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
Без дә патшалар сараенда йөрдек... . . . . . . . . . . 220
Мәхәббәт ничә була? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Мин дә «Чаян»да эшләдем! . . . . . . . . . . . . . . . 226
Күкләрдән эзлим... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Шәрифнең «усал» шаярулары . . . . . . . . . . . . . . 228
«Металл хисле Баттал» . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Югалган автограф . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Мин — күчмә театрдан... . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Казан каласына кунак килгән... . . . . . . . . . . . . 239
Мәңгелектән илаһи аваз . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Чаба гомерем көзләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Фасил симфониясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
Фасил Әхмәт мәзәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Ике очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Бала казлар ияреме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Бутыйлар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Алабуга зиратында туган шигырь . . . . . . . . . . . . 253
Без — кемнәр? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Ерактагы кәккүк авазы . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
«Хуш» дип әйтәлмәде... . . . . . . . . . . . . . . . . 258
Үз урынына килгән драматург . . . . . . . . . . . . . . 259
Сулар агар, җилләр исә торыр... . . . . . . . . . . . . 262
Авылдашым Равил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 263
Нигә без аерылдык?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Тукайны югалту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
Курку хисе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 270

Хаты гына калды... 272
Риза абый маҗаралары 274
«Һәркемнең үз Мәрфугасы бар...» 276
Егетлекне сагыну 279

**Көлеп-елмаеп яшәгән еллар**

Пешка 282
Көлдерүчесе булса... 283
«Спасибо за компанию!» 284
Үпкәләсеннәр иде... 284
Якташка хөрмәт 285
Иң кыска автограф 285
«Ак бар иде...» 285
«Вперед, Шакир абый!» 286
Язучыларның хуҗасы 287
Бу бит безобразие! 288
Аның соңгы көе 288
Сибгат абыйның Исмайдан «үч алуы» 288
Барысын да белүче Гүзәл 289
Татар әдибенең урысча юбилее 289
Рифмачылар 290
Интернациональ бурычлар 291
«Бөтен дөньяга танылган» 291
Хикәя язсам, ышанмаслар... 292
Рәиснең соңгы шаяруы 292
Үземне дә эләктерделәр... 293
Склероз 293
«Үлемемә сезне гаепләячәкмен...» 294
Күктән алган... 294
Җимерелгән дивар 295
Нәби абыйны сагыну 295
Автограф 296
Йөрәккә язылган исемнәр 298

Литературно-художественное издание

Ильдар Юзеев

*(Юзеев Ильдар Гафурович)*

**Избранные произведения**
**в пяти томах**

Том 2

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.11.2002. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 15,96+форз.0,21+вкл.1,68. Шартлы буяу-оттиск 17,96.
Нәшер-хисап табагы 14,48+форз.0,21+вкл.1,65.
Тиражы 3000. Заказ Б-548.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур.,2.